ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 2 (338)
ФЕВРАЛЬ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ВАТАН САКЧЫЛАРЫ – САФТА

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илшат Фәйзрахманов, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Бөек Ватан сугышы ветераны Хазим Фәхретдинов. Лилиана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-362
Басарга кул куелды: 25.02.2020
Басмадан чыкты: 28.02.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга. Гомуми тираж: 3500 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

АЛАЙ ИТСӘҢ ДӘ, БОЛАЙ ИТСӘҢ ДӘ, КЫЗЫК...

Республиканың йөзьеллыгы массакүләм мәгълүмат чараларына «тарихта казынып өчен» менә дигән форсат бирә. «Татарстан» журналы да рәхәтләнеп «казына» һәм моңа кадәр күренмәгән, колакка кермәгән тарихлар «казып чыгара». Әнә шулардан республикабызның йөзьеллык тарихы тукылган.

«Татарстан» журналының бу санын башыннан да, ахырыннан да укый башларга була: үткәннәргә кайтасыгыз киләме, бүгенге турында беләсегез киләме – шуннан тора. Хәзерге «Татарстан»* да, 70 нче еллар үрнәгендәге «Татарстан коммунисты» да йөз ел дәвамында үзенең укучыларын сөендереп торган. Бүген дә куандырыр: «Буыннар» махсус проекты – 70 нче еллардагы «торгынлык» чоры турында, гәрчә ул буын «торгынлык»ны сизмәсә дә.

«ТУГАН ИЛ, БЕРЕНЧЕ «КАМАЗ»НЫ КАБУЛ ИТЕП АЛ! » –

1976 елның 16 февралендә Яр Чаллыда төп конвейердан төшкән йөк машинасының бортына шулай дип язылган була. Бу вакыйга бөтен ил өчен истәлекле. Советлар Союзы заманча куәтле йөк машинасы һәм автогигантка ия була – дөньяда мондый заводлар комплексына тиңнәр булмый. Автогигантның беренче – 1976 елның 16 февралендә конвейердан төшкән «КАМАЗ-5320» машинасы бүгенге көнгә кадәр менә дигән итеп сакланган. Йөк машинасы озак еллар Башкортостанда эшли, соңрак завод аны музей өчен яңадан сатып ала. Хәзер «КАМАЗ» №0000001 – аеручa кыйммәтле экспонат.

* 1970 нче елларда «Татарстан» журналы «Татарстан коммунисты» дип аталган

Фото чыганагы: rostec.ru

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ

WWW.PROTATARSTAN.RU

ШИГЪРИ ЮЛ КҮРСӘТКЕЧЕ

Шаһинур Мостафинның әлеге шигъри юллары безне Мамадыш районы Арташ авылына кергәндә каршы алды. Исән чакта гел кайткалап торыйк... Бу сүзләр кайчандыр авылда туып-үсеп, бүген илебезнең төрле почмакларына таралган милләттәшләребезгә мөрәҗәгать кебек... Исән чакта нигезебезне, туган ягыбызны, телебезне, татарлыгыбызны онытмыйк, көрешеп, хәл белешеп, ярдәмләшеп яшик.

#ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

#бары тик ТАТАРСТАНДА

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Бары күләгәдән генә чыгасы!
Ни өчен пилот проекты үзен аклый

8. Аграрийлар өчен мөмкинлек
Тармакны цифралаштыру нинди үзгәрешләр китерер

10. «Демография» нәрсәдән тора
Әлки районы иҗтимагый сәламәтлекне саклау юлында

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

20.Олы нефть – олы тарих
Лениногорскидагы музей кай ягы белән кызыклы

24. Халыклар дуслыгы яшәгән авыл
Чепьяда нинди кызыклы музей бар

28. Нәкый Исәнбәткә – 120 яшь
Олуг әдипнең юбилеен каршылап...

34. Редакция кухнясы
Хикмәтле бәрәңге бөккәне

38. Замана чирләре
«Ак үлем» тырнагыннан ничек котылырга

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

43. Җиңүнең 75 еллыгына
«Исән калу – зур бәхет!»

46. Тарихи сәхифәләр
Патшабикә Екатерина II Казанда

4. 1970 нче еллар буыны
Ни өчен ТАССРда туганнар «торгынлык» эпохасында яшәгәннәрен белмәгәннәр

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

8. Бөтенебез бер илдә яшәгәндә
«Татарстан» нәрсә өчен Халыклар дуслыгы орденына лаек була

18. Туй күлмәкләре модасы
70 нче елларда кияү-кәләшләр нинди булганнар

20. Хәрби чор дипломатиясе
Табиевны ни өчен Әфганстанга илче итеп билгеләгәннәр

24. 1978 елгы зәмһәрир суыклар...
Тәтешлеләр салкында катып үлү куркынычы янаган балаларны ничек коткарганнар

28 Владимир Высоцкий рецепты
Казанда гастрольләрдә актер нинди чәй эчкән

29. 70 нче еллар афишасы
Ни өчен Алла Пугачёвага Казан туны ошамаган

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

02.02

Марат ХӨСНУЛЛИН, РФ вице-премьеры, – «Российская газета»дагы эшлекле иртәнге ашта:

– Илебез тулысынча реновация белән шөгыльләнергә әзер дип әйтә аламмы мин? Юк, бюджетлары да төрле булган кебек, төбәкләр дә төрле. Шуңа күрә һәркем бу мәсьәләгә, үз үзенчәлегенә таянып, үзенчә якын килә. Әйтик, минем туган ягым Татарстанда инде 20 ел элек үк тузган торакны юкка чыгарырга керештеләр. Фонд булдырдылар, эшли башладылар, һәм бүген республикада андый тораклар юк.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

06.02

Герман ГРЕФ, Саклык банкы идарәсе рәисе, – Казанда, «Казан-Экспо» халыкара күргәзмә үзәге мәйданчыгында:

– Соңгы 20 елда Татарстан безнең илнең икътисадый драйверына әверелде. Республика – Россиянең чимал бәйлелегеннән ничек китә алачагына үрнәк булып тора. Татарстан һәрвакыт, беренче чиратта, чимал бирүче, икенчедән, индустриаль төбәк булып торды. 90 нчы елларда монда бик зур булган оборона комплексына, индустриаль комплекска көчле зыян килде. Шуңа да карамастан, республика үзенең индустриаль куәтен саклап кала һәм үстерә алды. Татарстан акрынлап диджиталь индустрия үзәгенә әверелеп бара. Бүген Иннополис – зур тизлек белән үсүче динамик шәһәр. Монда үсеш кичергән компетенцияләр, пәйда булган яңадан-яңа компанияләр – бүгенге көн чынбарлыгы.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

08.02

Сергей КИРИЕНКО, РФ Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары, – Болгар ислам академиясенең Попечительләр советы утырышында:

– Ислам безнең илдә борынгы тамырларга гына түгел, күпгасырлык ышанычлы тарихка, мәдәниятккә, үз традицияләренә ия. Россия кебек күпмилләтле һәм күпконфессияле ил өчен бу аеруча мөһим. Россия исламының мондый махсус традицияләренең яклануы, дин әһелләренең яңа буыннарына тапшырылуы мөһим.

Фото ТР Президенты сайтыннан

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Үзмәшгульләр **НИЧЕК** күләгәдән чыга

Авыл хуҗалыгын **НИЧЕК** цифрлаштырачаклар

Әлки районында **НИНДИ** юллар белән сәламәтлек өчен көрәшәләр

БАРЫ **КҮЛӘГӘДӘН ГЕНӘ ЧЫГАСЫ**

Россиядәге эшмәкәрлек дөньясында нигездән үк башка катлам барлыкка килде – үзмәшгульләр. Бу – эксперимент, һәм Татарстан ул эшли башлаган тәүге төбәкләрнең берсе булды. Әлеге пилот проект икътисадыбызга һәм «өй осталары»ның үзләренә нәрсә бирде соң?

Автор:
Ольга Туманская

Иллюстрация ТР буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән алынды

«Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» Федераль закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керде.

– Без монда нинди дә булса өстәмә салымнар җыю максатын күз уңында тотмыйбыз, – дип раслады матбугаттагы әңгәмәләренең берсендә РФ Финанслар министры Антон Силуанов һәм шунда ук ачыклык кертте: – Без бүгенге көндә теркәлмичә, салым түләмичә, үзләренең социаль хокукларын формалаштыруда катнашмыйча эшләүче эшмәкәрләрнең гади ысул белән теркәлүен, салым түләвен һәм, асылда, гражданнарга йөкләнгән барлык бурычларны үтәвен генә телибез.

КЕРЕМЛЕМЕ? ӘЛБӘТТӘ!

Ел узды – эшләр алга бара. Экспериментның беренче унике ае йомгакларын әнә шулай бәяләргә мөмкин, дип саныйлар Татарстан Икътисад министрлыгында. Нәтиҗәдә, икенче ел башына республикада үзмәшгульләр сыйфатында 60 меңгә якын кеше теркәлергә теләк белдергән. Бу күпме, әллә азмы? Әлеге санны без әлегә үз өметниятләребез белән генә чагыштырып карый алабыз.

– Ниятләр акланды, – дип шәрехли Татарстан Икътисад министрлыгының Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү институтларын үстерү бүлеге башлыгы **Артур Гайнов.** – 2018 елда Татарстан икътисадының рәсми булмаган секторында якынча 190 мең кеше эшли иде. Бу – республиканың Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәгълүматлары. Димәк, яңа салым режимы ярдәмендә 2019 елда аларның 30 проценты күләгәдән чыкты. Икътисадны легальләштерү бара, һәм бу – бик мөһим гамәл, чөнки шул очракта гына без үзмәшгульләр һәм эшмәкәрләр арасында гадел, дөрес көндәшлек турында сөйли алабыз, монда эшмәкәрләр мәнфәгатенең дә безнең өчен бик мөһим икәнлеген искәртү урынлы.

Фото Артур Гайновның шәхси архивыннан

Тагын берничә сан. Былтыр Татарстандагы үзмәшгуль затлар һөнәри керемгә салым рәвешендә 114 миллион сум акча түләгән. Закон нигезендә әлеге керемнәрнең 63 проценты РФ субъекты бюджетына, калган 37 проценты – Мәҗбүри медицина иминияте федераль фонды бюджетына юнәлтелергә тиеш. Шулай итеп, үзмәшгульләр Татарстан казнасын 72 миллион сум чамасы акча белән тулыландырган. Һәм янә шул ук сорау: бу күпме, әллә азмы? Чагыштыру өчен: бу сан мәгариф системабызда татар, рус һәм башка телләрне, шулай ук республикадан читтә татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатында бүлеп бирелә торган чыгымнарга тиң. Яки ВИЧ һәм гепатитлы затларга медицина ярдәмен

күрсәтүне камилләштерүгә тотылган чыгымнар белән чагыштырырга мөмкин. Яисә быел умартачылыкны, атчылыкны һәм нәселле терлек үрчетү эшен үстерү программасына бүлеп бирелгән акчаларга да тиңләргә була. Һәм югарыда телгә алынган сумма – әле «өй осталары»ның өчтән бер өлеше генә түләгән акча, ягъни былтыр рәсми теркәлгән затларның салымы гына. Антон Силуанов әйтеп җиткерми – дәүләт өчен матди файдасы күренеп тора. Тик үзмәшгульләрнең үзләре өчен файдасы күзгә күренерлекме?

ТҮЛӘ ДӘ ТЫНЫЧЛАП ЙОКЛА

2018 елның язы. Гаммәви мәгълүмат чаралары ТР Президенты карамагындагы Эшкуарлык советының киңәйтелгән утырышында Мөслимә Латыйпова чыгышы турында бик тәмләп сөйли. «2017 елда мин ялган эшмәкәрлекне күзәтә башладым. Алар социаль челтәрләрдә хәттин ашкан... Бу бизнес безнең эш күләмен урлый. Бу мәсьәлә белән шөгыльләнергә кирәк», – дип зарланды «Бәхетле» генераль директоры, декрет ялында тортлар пешерүче әниләрне күздә тотып. Гаделлекне саклар өчен, Президентның җавабын искә төшерик: һәр кеше җәмгыять өчен дә, үзе өчен дә файда китерерлек итеп гамәл кылырга тиешлеген белдерде ул. «Әниләр өчен без шартлар тудырырга тиеш. Уйлашырбыз», – диде Президент ул чакта. Яңа салым режимы бик вакытлы туры килде.

Шундый «декреттагы әниләр»нең берсе һөнәре буенча юрист Лиана Пахарева иде. Аның өчен беренчел мәлдә десертлар әзерләү үз баласын тәм-томнар белән сыйлау һәм күңелсез өй мәшәкатьләреннән арынып тору мөмкинлеге дә була. Дусларын, күршеләрен сыйларга онытмый һәм менә бер көнне телефоны шалтырый...

– Миңа десерт әзерләргә заказ бирделәр – бу көтелмәгән хәл булды, ә аннары шалтыратучылар күбәйде, һәм мин мавыгуымның инде хобби гына булудан туктаганын аңладым, – дип искә ала Лиана. Юрист буларак, ул мондый эшчәнлекнең дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешлеген аңлый. Мөслимә Латыйпова кебек, ул да Эшкуарлык советында үз сорауларын бирә. Сүз уңаеннан, әлеге эшмәкәр ханымнар уртак тел таба алды һәм хәзер инде алар хезмәттәшлек турында сөйләшүләр алып бара, чөнки бүген Лиана Пахарева «Үзмәшгульләргә ярдәм үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешмасын җитәкли, «өй осталары»на закон таләпләрен һәм бизнес алып бару үзенчәлекләрен ачыклауда булыша.

– Яңа салым режимы үзмәшгульләр өчен нинди файда китерә? – дип сорыйм аннан.

– Иң мөһиме – статус. Мин үз клиентыма чек биргәндә, әле теркәлмәгән кешеләр белән чагыштырганда, бер башка өстенлегемне тоям. Чөнки минем чек – минем гарантиям дигән сүз. Бизнес шуннан башлана да инде, әнә шуннан соң физик затлар белән генә түгел, ә юридик затлар белән дә эшләү мөмкинлеге ачыла, ә монысы – бөтенләй башка керемнәр.

Сүз уңаеннан, керемнәр, төгәлрәге, аларны яшереп торасы юк икәнлеге турында искә алыйк: үзмәшгульнең рәсми статусы, таләп ителгән очракта, кирәкле белешмәне теләсә кайсы рәсми учреждениегә бирергә мөмкинлек тудыра. Кыскасы, үзмәшгульлек – ул «салым түлә һәм тыныч йокла» дигән сүз генә түгел; «чит илләргә тыныч күңел белән чык», «үз продукцияңне иркенләп рекламала», «уңайлы ысул белән кредит ал» – болар барысы да үзмәшгульлек турында.

Хәер, үзмәшгульләр өлкәсендә бөтен нәрсә шәп дип кенә белдерү дөрес булмас. «Эксперимент үткәрү турында...» законының үз кимчелек һәм җитешсезлекләре бар. Аларның берсе – әлеге дә баягы Мөслимә Латыйпова искә алган «азык-төлек мәсьәләсе». Бүген үзмәшгульләр өчен азык-төлек продукциясенә сыйфат сертификаты һәм башка кирәкле документлар алу җитди проблема булып тора, бу – юридик яктан да катлаулы, акча ягыннан да артык чыгымлы эш.

– Асылда, һәр продуктка һәм аның һәр яңа составына аерым документ кирәк, – ди Лиана Пахарева. – Ә хәзер клиент аллергия аркасында сездән десертка чикләвек салмавыгызны сорый дип күз алдына китерегез... Шул ук вакытта исә микробизнеста һәр клиентка индивидуаль якын килү норма булып санала.

Бүген «Үзмәшгульләргә ярдәм үзәге» тарафыннан азык-төлек продукциясе җитештерүчеләр өчен киңәш-тәкъдимнәр эшләнгән. Юридик яктан башта шәхси эшмәкәр сыйфатында теркәлергә, кирәкле сертификатлар алырга һәм үзмәшгульләр өчен салым режимын сайларга мөмкин – закон бу ысулны тыймый. Икенче вариант: үз продукцияңнең куркынычсызлыгына лаборатор сынаулар уздырту – кайбер сәүдә мәйданчыклары аларны кабул итә һәм шул рәвешле үзмәшгульләр белән хезмәттәшлеккә каршы түгел. Әмма болар барысы да, әлбәттә, үзара килешү, уртак тел табу нигезендә генә тормышка аша. Проблема закон дәрәҗәсендә хәл ителергә тиеш. Бәлки, өй эшмәкәрләре өчен аерым сертификатлаштыру процедурасын да кертергә кирәктер – чыгымнар ягыннан да, тикшерүләрнең гадилеге ягыннан да хәлдән килерлек булсын.

Лиана Пахарева, Үзмәшгульләргә ярдәм үзәге җитәкчесе

НӘРСӘ ЯХШЫ, НИ НАЧАР?

Аларның остаханәләре кул сузымында гына. Ирле-хатынлы Әдилә һәм Алексей Уточкиннар имәннән һәм башка агачлардан ризык турау такталары ясый торган кечкенә цехны үз өйләрендә оештырып җибәргән.

– Кайчандыр без төзелеш белән шөгыльләндек, әмма ирем пенсиягә чыкты да, күңелсезләнеп утырмас өчен, гаилә җыенында уртак эш башлау турында карар кабул иттек, – дип сөйли Әдилә. – Без һәрвакыт агачка тартылдык, табигый һәм бик җылы материал бит. Агач эше җиһазларының кайберләре бар иде инде, кайсындыр сатып алдык... Аш бүлмәләре өчен ризык турау такталары ясый башладык, ә аннары, халыктагы ихтыяҗны өйрәндек тә, ассортиментка агач тәлинкәләр һәм менажницалар өстәдек.

Гаилә бизнесында Алексей җитештерү өчен җавап бирә. Барлык оештыру мәшәкатьләрен һәм кәгазь эшләрен Әдилә үз өстенә ала. 2019 елда ул үзмәшгуль булып теркәлә.

– Әлбәттә, качып, сиздермичә генә дә эшли алган булыр идек, әмма үзмәшгульлекнең аерым өстенлекләре бар. Иң мөһиме – сату челтәрен киңәйтү. Рәсми статус булмаганда, без үз продукциябезне танышлар яки социаль челтәрләр аша гына сата алабыз. Яңа режим юридик затлар белән эшләү, шулай ук төрле сәүдә мәйданчыкларына һәм кибетләргә үтеп керү мөмкинлеге бирә.

Өстенлекләр өчен физик затларга товарлар сатудан һәм хезмәт күрсәтүләрдән кергән керемнең 4 процентын,

Фото: Александр Ефремов

Ирле-хатынлы Әдилә һәм Алексей Уточкиннар имәннән һәм башка агачлардан кисү-турау такталары ясый торган кечкенә цехны үз өйләрендә оештырып җибәргән. «Әлбәттә, качып, сездерми генә дә эшли алган булыр идек, әмма үзмәшгульлекнең аерым өстенлекләре бар. Иң мөһиме – сату челтәрен киңәйтү», – ди Әдилә.

юридик затлар белән эш иткәндә, керемнең 6 процентын салым сыйфатында түләргә кирәк.

– Кыйммәт түгелме? – дип сорыйм Әдиләдән. – Сезнең бизнеста чыгымнар аз түгел бит – чималын да, җиһазларын да сатып алырга кирәк...

– Начар түгел! Без бу сумманы алдан ук бәягә салабыз, шуңа күрә ул кесәгә сукмый. Ә дәүләткә башка берни дә түләмибез. Бәхеткә, безнең продукциягә сертификатлар яки маркировка кирәкми. Бу исә бик шәп, югыйсә рәсми үзмәшгульлекнең асылы җимерелә – барысы да бик гади, кулай булырга тиеш.

Чыннан да, бүген үзмәшгуль затка әйләнү җиңелләрдән җиңелрәк. «Минем салым» мобиль кушымтасын күчереп аласың да теркәлү төймәсенә басасың – һәм вәссәлам. Диваннан тормыйча гына, бөтен процедураны ун минутта үтеп була. Ышануы кыенмы? Күпләр өчен чыннан да шулай.

– Ә кинәт салымны арттырсалар, Пенсия фондына мәҗбүри взнослар кертсәләр, штраф сала, карталар эшен туктата башласалар... Иң башта кешеләрнең курыккан нәрсәләре бик күп иде, – дип сөйли Лиана Пахарева. – Тик былтыр, сүз уңаеннан, бездә салым тикшерүләренә мораторий булды. Ә асылда, уйлап караганда, үз бизнесыңны намус белән алып барасың икән, нинди санкцияләргә эләгергә мөмкин ди? Нәрсәдән куркырга? Тикшерүче органнар тарафыннан контроль сатып алуларданмы? Салым түләмәгән өчен штрафтанмы? Менә шулардан гына. Без республиканың барлык районнарында диярлек түгәрәк өстәлләр уздырдык, аларда әлеге куркулар турында сөйләштек, аңлаттык, чөнки күп кенә шик-шөбһәләрнең сәбәбе бик гади – алар закон белмәүдән килеп чыга. Кешеләрнең бөтен борчулары таралды дип әйтә алмыйм – бу юнәлештә эш күп әле.

Әйе, нинди дә булса вак-төяк кыенлыклар юк түгелдер, мөгаен. Яңа салым режимы эшли башлаган төбәкләрнең кайберләрендә дәүләт органнары да тиз генә җайлашып, керешеп китә алмады. Тик бездә, Татарстанда, закон гамәлгә кергән беренче көннәрдән үк үзмәшгуль кешеләргә ярдәм иң югары дәрәҗәдә булды, дип раслый Лиана.

Үзенең проектын Искәндәр Богданов SNACKBAZAR дип атый һәм аны хатынына бүләк итә. Вакытлар узу белән, SNACKBAZAR гаилә бизнесына әверелә. «Мәшәкатьләр җитәрлек, шуңа күрә кәгазь эше, язу-сызу белән бөтенләй шөгыльләнәсе килми. Ә «Минем салым» кушымтасы – электрон бухгалтерга тиң ул. Безгә иҗат итәсе генә кала бит!», – ди Искәндәр.

Фото Әдилә һәм Алексей Уточкиннарның шәхси архивыннан

Фото Искәндәр Богдановның шәхси архивыннан

– Ә куркыныч-хәтәрләр исә – иң аз дәрәҗәдә! – ди ул. – Эшләп карыйсың да, уңышлы килеп чыга икән, алга таба үсәсең. Шул ук вакытта исә, шәхси эшмәкәр булып теркәлгәндәге кебек, анык бер эш төрен сайларга кирәкми, ягъни иртән сатуга тортлар пешерә, көндез фирмага консультация бирә, кичен – чәчәк бәйләмнәре ясый аласың... Сүз уңаеннан, үзмәшгульләр арасында иң сәер эшчәнлек төре белән дә шөгыльләнүчеләрне күрергә туры килде, бу – им-томчылык. Ә инде эшең уңышлы килеп чыкмаса? Ул очракта «үзеңне хисаптан төшерергә» дигән төймәгә генә басасы һәм менә – син инде үзмәшгуль түгел.

ЗАКОН ЧИТЛӘРЕНӘ ИСКӘРМӘЛӘР

Искәндәр Богдановка гаилә бизнесы турындагы идея очраклы гына килеп иңә. Урамда җәй, җил чәчәк һәм җиләкләрнең хуш исләрен тарата. Искәндәр интернет киңлекләрендә гизү белән мәшгуль һәм көтмәгәндә ул яшелчә һәм җиләк-җимеш өчен киптеру җайланмасының рекламасына тап була. Шунда ук кайчандыр әбисе киптергән каклар турындагы җылы хатирәләрен искә төшә. Тәмле, хуш исле, файдалы... Ә бу табигый татар ризыгының рецептларын яңадан торгызып карасаң ничек булыр икән?

Үзенең проектын Искәндәр SNACKBAZAR дип атый һәм аны хатынына бүләк итә.

– Мин – дизайнер, минем өчен продуктның хәтта тышкы яктан да матур булуы бик мөһим, шуңа күрә иң әүвәл төргәкнең дизайнын ясадым, – дип елмая Искәндәр. – Шикәрсез тәм-томнар – каклар һәм төрле җиләк-җимеш чипсылары җитештерү идеясе исә бүген популяр сәламәт яшәү рәвеше концепциясенә бик урынлы туры килде.

Вакытлар узу белән, SNACKBAZAR гаилә бизнесына әверелә. Хатыны – әзерләү-пешерү, Искәндәр исә товарны рекламалау, популярлаштыру белән шөгыльләнә.

– Беләсезме, үзең нидер эшләп чыгарасың һәм кулланучылардан бәяләмә аласың икән, бу синең аңыңны үзгәртә. Кыскасы, әлеге эш безне үзенә суырып алды. Мәшәкатьләр җитәрлек, шуңа күрә кәгазь эше, язу-сызу белән бөтенләй шөгыльләнәсе килми. Ә «Минем салым» кушымтасы – электрон бухгалтерга тиң ул. Безгә иҗат итәсе генә кала бит!

Искәндәр әлеге салым режимын коммерция өлкәсендә алга таба үсеш өчен менә дигән башлангыч баскыч дип саный, чөнки кече һәм урта бизнеска фискаль басымйөкләмәләр зур, «өй осталары»на андый эшмәкәрлек башлаудан бернинди мәгънә юк. Рәсми статистика аңа тукып тора: кече һәм урта бизнес ширкәтләренең 50 проценты теркәлүдән соң беренче ел дәвамында үз эшчәнлеген туктата, һәм нибары 10 проценты гына биш яшен бәйрәм итә ала.

– 4–6 процент зурлыгындагы салым түләү бурычы – һәм барысы да бик канәгать! Дәүләт тә, без – үзмәшгульләр дә. Өстәвенә, салымчыларга ялынып-ялварып йөрмичә, безгә иске эшне әллә ни мәшәкатьләрсез генә төгәлләү һәм нинди дер яңаны башлау мөмкинлеге туды. Бу чыннан да кешечә эш йөртү. Якын киләчәктә бездә дә, Франциядәге кебек, һөнәрчелек производствосы үсеш алыр дип өметләнәм. Анда һәр почмакта кечкенә кибетләрне күрергә була, бу кибетләрдән бер генә кеше эшли, аңа улы яки кызы булышырга мөмкин... Хәзер безгә бу бер дә комачауламас иде.

Шул ук вакытта, пилот проектның җитешсезлекләре Искәндәргә дә кагыла. Беренчесе – үзенең SNACKBAZAR брендын тулысынча теркәү аңа якынча 50 мең сумга төшәчәк. Ә яңа гына эш башлаган кеше өчен бу хәлдән килерлек хак түгел. Икенчесе – азык-төлек продукциясенә сертификатлар булмау сәбәпле, кибетләр какны сатуга алмый диярлек. Өченче – үзмәшгульләр һәм юридик затлар арасында килешүләр төзегәндә, законның «пешеп җитмәгәнлеге» аркасында кыенлыклар килеп чыга.

– Танылган компания безгә клиентлары өчен бүләккә дип татар кагына заказ бирде. Өч атна инде без товара җибәрүне юридик яктан дөрес итеп уздырырга тырышабыз, нечкәлекләре бик күп, – дип сөйли Искәндәр.

Әдиләә тагын бер проблеманы телгә ала: сәүдә мәйданчыкларына керү өчен үзмәшгульләргә эквайринг ярдәмендә акчасыз түләү алу мөмкинлеге җитми.

– Без ясый торган кисү-турау такталарының бәясе еш кына мең сумнан артып китә, үзе белән һәркем дә бу кадәр акча йөртми, – дип сөйли ул. – Картадан картага күчерү шактый мәшәкатьле – кайчак сатып алучыга борылып китеп бару җайлырак... Әлбәттә, башта шәхси эшмәкәр сыйфатында теркәлергә, эквайринг куллану хокукы алырга, ә аннары үзмәшгульлеккә күчәргә мөмкин... Ләкин ник шулкадәр интектерергә соң? Бу бит үзмәшгульлек идеясенең гадилек принцибын юкка чыгара.

Гомумән, идея яхшы, әмма аны гамәлгә ашыру әлегә идеалдан ерак. Мәсәлән, әлегә үзмәшгульләргә дәүләтнең кече һәм урта бизнес өчен гамәлдә булган финанс ярдәме ачык түгел. Хәер, белүебезчә, эксперимент әле икенче ел гына бара.

НИ ӨЧЕН ҮЗМӘШГУЛЬ БУЛЫП ТЕРКӘЛҮ ҖИҢЕЛ ҺӘМ ФАЙДАЛЫ?

- Теркәлү җиңел һәм әлеге салым режимыннан чыгу гади
- Салымның түбәнәйтелгән ставкасы
- Сатып алучыга чек бирергә була, димәк, юридик затлар белән эшләргә мөмкин
- Кеременңне расларга һәм бу турыда теләсә кайсы ведомствога яисә банкка белешмә бирергә мөмкин
- Салым түләүнең барлык исәп-хисапларны мобиль кушымтада «бер төймәгә» басу аша эшләргә була
- Шәхси эшкуар сыйфатында теркәлмичә, отчетларсыз, кассасыз легаль рәвештә эшләргә мөмкин
- Пенсия һәм медицина иминияте өчен иминият кертемнәрен түләмәскә мөмкин. Бу очракта әлеге гамәлләр ихтыяри рәвештә башкарыла

– Кече һәм урта эшкуарлык корпорациясе МСП банкы һәм РФ Икътисади үсеш министрлыгы белән берлектә үзмәшгуль гражданнарга ташламалы кредит бирү тәртибен тәкъдим итте инде. Сүз банк ставкасы процентын субсидияләү турында бара. Бәлки якын арада үзмәшгульләр өчен яңа кредит тәкъдимнәре пәйда булыр, – дип яңалыклар белән уртаклаша Артур Гайнов. – Барлык проблемалы мәсьәләләр акрынлап өйрәнелер, чишелер дип уйлыйм. Быелдан пилот проектка башка төбәкләр дә кушылды, димәк, аны камилләштерү белән бәйле тәкъдимнәр тагын да күбрәк булачак.

Фото ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҮСЕШЕ ӨЧЕН ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР

Республикабызда «Татарстан Республикасы агросәнәгать тармагын комплекслы цифрлаштыру» проекты старт алды. Яңа мәгълүмати технологияләрне гамәлгә кертү берьюлы өч юнәлештә – идарә системасының үзендә, шулай ук терлекчелектә («Акыллы ферма» юнәлеше), игенчелектә һәм техника белән тәэмин итүдә («Цифрлы гектар») алып барылачак. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Азат улы Җаббаров әлеге проектның урыннарда ничек гамәлгә ашырылуы турында сөйләде.

Әңгәмәдәш:
Клавдия Безденежных

– Марат Азатович, Татарстанның агросәнәгать тармагын комплекслы цифрлаштыру нәрсәдән башланачак?

– Теләсә кайсы проектны тормышка ашыру өчен иң әүвәл ресурслар табарга кирәк. Бу проектта төп ресурс – кеше капиталы, шуңа күрә без ирешергә ниятләгән беренче баскыч – министрлыкның үзендә процесслар белән идарә итү системасын кертү. Аннары тәҗрибәне район авыл хуҗалыгы идарәләренә, аннары авыл хуҗалыгы предприятиеләренә тарату күз уңында тотыла. Исәп-хисап һәм контроль белән бәйле хезмәтләрне автоматлаштыру хисабына эш вакытын бушату әлеге эшнең нәтиҗәсе булачак, бу исә тармак үсешен тизләтү максатларында инновацияле проектларны гамәлгә ашыру өчен өстәмә ресурслар алырга мөмкинлек бирәчәк. Менә шушы этапны без беренчел, өстенлекле дип саныйбыз. Ул тормышка ашырыла инде, аны быел тәмамларга планлаштырабыз. Хәзер кулланышта булган хисап бирү тәртибен тулысынча автоматлаштыру һәм дәүләт ярдәме чараларыннан файдалануны электрон форматка күчерү, киләчәктә бюджет акчаларын куллануны контрольдә тоту системасын эшләтеп җибәрү – сүз әнә шулар хакына бара.

– Бу проектның тагын бер юнәлеше «Цифрлы гектар» дип исемләнә. Югары технологияләр кертү игенчелек тармагына нәрсә бирәчәк?

– Игенчелекне цифрлаштыру, авыл хуҗалыгы техникасын исәпләү һәм мәгълүмат тапшыру җайланмалары белән тәэмин итү – проектны тормышка ашыруның икенче баскычы. Бу очракта без нәрсәгә омтылачакбыз? Барыннан да бигрәк, сыйфатны яхшыртуга, шулай ук басу-кырларда технологик операцияләрне башкару дисциплинасына, ягулыкны һәм химик саклану чараларын янга калдыруга. Бездә бу технологияләр белән эш итә торган хуҗалыкларга мисаллар бар, һәм алар нәтиҗәлелекнең артуын раслый. Зур күләмле мәгълүматлар туплау да уңыш дәрәҗәсен төгәл фаразларга булыша. Моннан тыш, «төгәл игенчелек» технологиясендә зур потенциал күрәбез, ул басуның һәр кишәрлегендәге проблемаларны ачыкларга һәм һәр гектардан максималь табыш алырга мөмкинлек бирә. Хуҗалыкларның игенчелек күрсәткечләрен агросәнәгать комплексы геомәгълүмат системасының гамәлдәге платформасында туплыйбыз – бу безгә «цифрлы игезәк» булдырырга, ягъни оптимальләштерү һәм нәтиҗәлелекне арттыру максатында, республикадагы бөтен игенчелек тармагының цифрлы күчермәләрен төзергә ярдәм итә.

– Цифрлаштыруның терлекчелек өлкәсенә килүе планлаштырыла дип беләбез. Ул нәрсәдән башланачак?

– Бүген Татарстан сөт җитештерү буенча Россиядә – беренче урында, ә ит җитештерү буенча сигезенче урында тора. Бу – республикада терлекчелекнең шактый үсеш алган юнәлеш икәнлеген белдерә. Монда беренче чираттагы бурычыбыз – авыл хуҗалыгындагы барлык терлекләргә чип урнаштыру, аларны бердәм мәгълүмат базасына кертү. Бу барлык терлекчелек фермаларында баш саны, көтү белән идарә итү буенча программа продуктларын гамәлгә кертү өчен нигез булдырачак.

– Гаделлек өчен шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: әлеге эш зур кертемнәр таләп итә. Алар чынлыкта акланырмы?

– Терлекләрнең баш саны, көтүе белән идарә итүнең инде эшләп килгән системалары икътисадый яктан югары нәтиҗәлелекне күрсәтә – продуктлылыкны 1,5 тапкыр арттырырга һәм 20 процентка кадәр терлек азыгын янга калдырырга мөмкин. Терлекчелектә цифрлаштыру юнәлешенә кертелгән инвестицияләр җитештерү күләмен арттыру хисабына 3–6 ай эчендә үзен аклый, ә продукцияне идентификацияләү һәм сәүдәне оптимальләштерү системасы предприятиегә сатып алучылар һәм инвесторларның ышанычын яулау мөмкинлеген бирә.

– Гомумән алганда, республиканың агросәнәгать тармагын комплексы цифрлаштырудан нинди нәтиҗә алырга җыенасыз?

– Без Татарстан агросәнәгать комплексының бердәм программа платформасын булдырабыз, анда барлык цифрлы технологияләрне – гамәлдәгеләрен дә, яңадан эшләнә яисә сатып алына торганнарын да берләштерәчәкбез. Нинди нәтиҗә көтәбез, дисезме? Барыннан да элек, әлбәттә, чыгымнарны киметү һәм продукция җитештерү күләмен арттыру хисабына авыл хуҗалыгы предприятиеләренең хезмәт җитештерүчәнлеген һәм нәтиҗәлелеген үстерү турында сүз бара.

– Бу очракта нинди срокларны күздә тотасыз?

– Быел идарә процессларын оптимальләштерергә ниятлибез. Параллель рәвештә, ике ел дәвамында авыл хуҗалыгындагы һәр аерым предприятиене цифрлаштыру буенча проектларны тормышка ашырачакбыз.

– Татарстанда күләмле цифрлаштыру проектына кушылган предприятиеләр бармы инде? Алар бу юнәлештә эшләрен нәрсәдән башлады?

– Ничек кенә сәер тоелмасын, цифрлаштыру юлында корпоратив культура бик мөһим – нәкъ менә шул төрле буыннарны берләштерергә ярдәм итә. Әйе, сүз гореф-гадәтләр, кешелек кыйммәтләре, үзара мөнәсәбәтләр, үз-үзеңне тоту нормалары һәм корпоратив стиль турында бара. Хезмәткәрләр тарафыннан компаниянең үсеш траекториясенә карата гомуми күзаллауны әнә шулар билгели. Бәхеткә, безнең республикада дөрес корпоратив культура булдыруның компания өчен үсеш һәм уңышлы эшләү нигезе икәнлеген аңлаган оешмалар бар. Мәсәлән, «Август» компаниясенең инновацияләре һәм технологик идарә нәтиҗәлелеге хезмәткәрләрнең һөнәри күнекмәләрен арттыруны, тәҗрибә алмашуны, оешма белән идарә итүнең яңа ысулларын кертүне даими игътибар үзәгендә тотуга нигезләнгән.

– Эчтәлекле әңгәмәгез өчен рәхмәт.

«ДЕМОГРАФИЯ» СӘЛАМӘТЛЕК ТАЛӘП ИТӘ

Кайчакта милли проектлар ниндидер абстракт әйбер булып, кайдадыр федераль өлкәләрдә генә гамәлгә ашырыладыр кебек тоела. «Татарстан» Әлки районына баргач, шуңа инанды: күпләребез, үзебез дә сизмәстән, ул проектларда катнаша икән бит инде.

Автор:
Ксения Сёмина



– Малай на белом барсе, малай на белом барсе, кажется мне… принцем на коне! – Татарстанда популяр җырчы Лейна Базарлы Матакның Мәдәният йорты каршындагы сәхнә янына җыелган халыкны «уятырга» бик тырышса да, һәркемнең үз мәшәкате. «Ак Барс» хоккей командасы формасын кигән Лейна исә чыннан да бик күркәм күренә, тик тамашачының яртысы кәшәкәсен яңа гына кырыйга куярга өлгергән, икенче яртысы менә-менә кәшәкә тотып уйнарга чыгарга тора. Массакүләм боз ярышларыннан, төгәлрәге, гыйнвар ахырында Әлкинең район үзәге – Базарлы Матакта «Мин әнине, әтине һәм хоккейны яратам» фестивале белән «Демография» милли проектына кергән «Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» федераль проектының бер чарасы – «Сәламәтлек эстафетасы» башланып китте.

ПОДЪЕЗДЛАРДАН – БОЗГА

Район эстафетага мөмкин кадәр күбрәк катнашучыларны җәлеп итү максатын куйган. Хоккей фестивале исә бу концепциягә бик яхшы туры килә. Ул көнне Базарлы Матакта кубок һәм төрле бүләкләр өчен 37 команда көч сынашты. Ярышлар алты дивизионда үткәрелде: малайлар һәм кызлар өчен икешәр (бәләкәйләр һәм зурлар), шулай ук гаиләләр өчен – «Ике олы кеше һәм бала», «Бер олы кеше һәм ике бала». Уеннар һәвәскәр булса да, боз өсте кызган табага тиң иде. Спортчылар да, җанатарлар да чын күңелдән катнаштылар.

Без дә гомуми күтәренкелекне үзебездә тоясыбыз килеп, «сәхнә артына» үттек. Менә эскәмиядә бер гаилә – әтисе, әнисе һәм улы бозга чыгарга әзерләнә.

– Без барыбыз да спорт белән шөгыльләнәбез, – дип сөйләде гаилә башлыгы Рафас Билалов, тимераякларын кия-кия. Ул физкультура һәм тормыш

Фото: Александр Ефремов

Эстафетада катнашучыларны Әлки районы башлыгы Александр Никошин, Әлки якташлык җәмгыятенең җитәкчесе, Казан кооператив институты ректоры Алсу Нәбиева, Сәламәт туклану институты директоры Марат Кәлимуллин һәм Татарстан Хоккей федерациясенең башкарма директоры ярдәмчесе Виктор Калачик сәламли.

иминлеге нигезләре укытучысы, ә аның хатыны Алсу – Әлки районының финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары. Алсу үзе волейболны күбрәк яратам, ди, ире – футбол һәм хоккей, уллары Разил футбол белән «җенләнә».

– Боларның барысы белән шөгыльләнергә шартлар бармы соң?

– Менә «Алина»да барысын да уйнарга була, – ди Рафас һәм спорт комплексы әлкилеләрнең якташы Алинә Кабаева исемен йөртүен дә искәртеп куя.

– Татарстанның хоккей федерациясе мондый фестивальләрне ел саен оештыра – республиканың төрле районнарында елына өчәр чара. Әлкидән соң, Чүпрәле белән Әтнә районнарында булачак. Урын сайлаганда, без инфраструктураның әзерлегенә һәм потенциаль катнашучыларның санына карыйбыз, – ди федерациянең башкарма директоры ярдәмчесе Виктор Калачик. – Фестивальнең төп максаты – кызыксындыру, кешеләрне диваннарыннан кузгатырлык, подъездларыннан чыгарырлык яңа эмоцияләр бирү һәм спортка җәлеп итү.

Ул арада фестивальнең дә, эстафетаның да ачылу тантанасы башлана. Бозга, дөрес, тимераяксыз гына Әлки районының башлыгы Александр Никошин, Әлки якташлык җәмгыятенең җитәкчесе, Казан кооператив институты ректоры Алсу Нәбиева, Сәламәт туклану институты директоры Марат Кәлимуллин һәм Виктор Калачик чыга. Спикерлар Татарстанда «Демография» милли проектына керә торган биш федераль проектның икесе – «Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» һәм «Спорт – тормыш нормасы» проектлары, асылда, бүген һәм биредә башлана, дип ассызыкладылар. Вакыйга шуның белән дә истәлекле. Гамәлдә бу нәрсәне аңлата соң?

– Безнең районда спорт өчен кирәкле бөтен инфраструктура да бар – «Алина» комплексы, «Ләйсән» бассейны, хоккей тартмалары, баскетбол өчен мәйданнар һ.б. Барлык объектларның да эш режимы уңайлы итеп көйләнгән. Безнең профессиональ спорт командалары федераль дәрәҗәдә уңай нәтиҗәләр күрсәтә. Ләкин шул ук вакытта спорт белән даими рәвештә халыкның 52 проценты гына шөгыльләнә, – дип сөйләде башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ленар Әһлиуллин. – Ә «Демография»дә куелган максат шундый: спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр (29 яшькә кадәр) саны 2024 елга 86 проценттан ким булмаска тиеш. Яшьләрне һәм үсмерләрне спортзалга китер дә – шул җитәр кебек. Әмма ул яшьләрне залда калдырыр өчен мотивация кирәк. Бүгенге кебек акцияләр ярдәмендә (район буенча тулаем алганда, 50 спорт чарасы үтте) без аны булдырырга, балаларны гына түгел, олыларны да спортка тартырга телибез. Спорт бит ул – өлкән буыннан яшьләргә тапшырыла торган традиция.

«БАЛАФУД» ФАСТФУДКА КАРШЫ!

Ул арада хоккей тамашасы янәшәсендә үк кулинарлар ярышы башланып китә. Мәдәният йорты фойесында «БАЛАFOOD» («Балафуд») балалар һәм үсмерләр өчен республика кулинарлар фестивалендә катнашучылар үзләренең шедеврларын тезеп куя. Аның нигезендә организм өчен файдалы һәм дөрес туклану идеясе ята. Балалар, биш төрле категориянең («Салкын эчемлекләр», «Чәйләр», «Салатлар», «Икенче ашамлыклар», «Камыр ризыклары») берсендә ризык әзерләп, аны тәкъдим итәргә тиеш булды. Татар, чуваш, рус кухнялары традицияләрен истә тотып, әлбәттә. Бал ширбәте, парда пешкән кәтлит, балык, үлән чәйләре, яңа сыккан яшелчә соклары, кабак һәм борчак оннарыннан пироглар,


Билаловлар гаиләсе боз өстенә чыгарга әзерләнә.

бүрттерелгән карабадой, фасоль кузагы, көнбагыштан салатлар – күргәзмә өстәлләре ашамлыклардан сыгылып тора иде. Ә менә Юхмачы мәктәбеннән Шамил Әхмәтшин… чипсы ясаган.

– Барыбызга да мәгълүм: бүген яшьләр чипсы ярата. Әмма безнең организм аның кадәр тоз, тәмләткеч, майларны кабул итә алмый, – дип аңлата Шамил үзенең эшен. – Мин аңа альтернатива тәкъдим итәм: яшелчәләрдән һәм җиләк-җимештән ясалган чипсы.

Бу юнәлештә тәҗрибәләр белән үсмер күптән түгел генә мавыга башлаган. Әти-әнисе аның бу мавыгуын хуплап, махсус киптергеч алып биргәннәр. Үзе гади, үзе уңайлы.

– Мин теләсә кайсы яшелчә, җиләк-җимештән чипсы ясыйм. Банан, әфлисун, хөрмә – иң яратканнарым, – ди Шамил. Озакламый конкурсның икенче этабына Казанга барырга җыена, үзенең технологиясен башкала аудиториясе белән бүлешәчәк.

– Фестиваль балаларга адресланган, чөнки алиментар, ягъни ризык составы бозылу белән бәйле авыруларның нәкъ менә балалар арасында киң таралган. Бигрәк тә төрле җитештерүләр һәм транспорт бергә тупланган шәһәрләрдә нык сизелә ул, – ди Марат Кәлимуллин. – Фестиваль ярдәмендә без мәктәп балаларын сәламәт туклану төшенчәсе, организм өчен чыннан да кирәкле һәм файдалы ризыклар рецептлары белән таныштырабыз, фастфудны еш кулланудан сәламәтлеккә килгән зыянны капларга өйрәтәбез һәм, ниһаять, файдалы ризыклардан торган рационның икътисадый ягын да аңлатабыз.

Чынлыкта «БАЛАFOOD» – «Җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» федераль проектын тормышка ашыруда бер адым гына ул. Проектның максаты – шул исәптән симерү белән авыру-

чыларның, үлүчеләрнең санын киметү, алкоголь куллану һәм тәмәке тартуны киметү, сәламәт яшәү рәвеше турында мәгълүматка ихтыяҗны арттыру.

– Федераль проект быел ук төбәкләрдә сәламәт туклану мәсьәләләре буенча методик материаллар эшләүне һәм таратуны күздә тота. Алар фәнни мәгълүматларга һәм Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының киңәшләренә таянырга тиеш булачак. Безнең Сәламәт туклану институты КФУ ярдәме белән әлеге өлкәдә тикшеренүләр алып бара. Шуңа да без Әлки районында башланып киткән «Сәламәтлек эстафетасы»на актив рәвештә кушылып киттек. Өстәвенә, әлеге проект буенча бергә эшләгән коллегаларыбыз – КФУның беренче проректоры Рияз Минзарипов һәм КФУның хуҗалык эшләре буенча проректоры Ленар Сафиуллин Әлки җирендә туып-үскән. Аларның туган яклары белән кызыксынуы, аның иминлеге турында кайгыртучы инструмент булдырырга омтылуы да илһамландыра, – ди Марат Кәлимуллин.



Дөрес итеп әзерләнгән ризыклардан авыз итеп, без «Алексеевскдорстрой» кубогына «Алина» спорткомплексында бара торган минифутбол чемпионатының финалын карарга юл тоттык. Вакытлы килеп җиткәнбез икән: матчлардан соңгы пенальти сериясендә әлкиләр, Алексеевск районыннан килгән коллегаларыннан өстен чыгып, чемпион булдылар. Үз өеңдә сәламәтлек эстафетасы да ярдәм итә.

P.S. Шушы көнне әлкиләр эстафетаны Нурлат районына тапшырды. Сәламәт яшәү рәвеше хәрәкәтенә Аксубай, Чирмешән районнары кушылды. Ә сез кушылырга әзерме? ■

ВАЛЕРИЙ ПОБЕЖИМОВ:
«АЛГА ҺӘМ ЮГАРЫГА! ЮЛГА ШУННАН ДА АРТЫК ТАГЫН НИНДИ ТЕЛӘКЛӘР ТЕЛӘРГӘ БУЛА?»

Исеме бөтен дөньяга мәгълүм булган теләсә кайсы компаниянең уңыш сере – һөнәр осталарын бергә туплап, һәркайсы бер максатка хезмәт итү юлында үз бурычларын башкарган кешеләр тарихы ул. Кайчагында андый команданы туплау өчен бик күп вакыт уза, бик күп акча туза. «Эникс» АҖндә бу процесс камил дәрәҗәгә җиткерелгән.

Побежимовлар (сулдан уңга): Гобәева Э. Р., Насыйров А. Р., Побежимов Е. В., Побежимов В. Н., Побежимова Э. М., Побежимов С. В., Сөбханкулов Р. Р., Варсегов В. Л., Варсегова Е. В.

Бүген предприятие коллективында җиде династия вәкиле эшли. Аларның кайберләре компаниянең чишмә башында ук торган. 1980 еллар башында әлеге белгечләр Валерий Побежимов белән «Сокол» конструкторлык бюросының перспективалы эшләнмәләр бүлегендә бергә эшләгәннәр. 1988 елда Побежимов җитәкчелегендә тикшеренү үзәге барлыкка килгән. 2003 елда ул «Эникс» ябык акционерлык җәмгыятенә әверелгән. Бүген Казанда урнашкан әлеге компания – серияле тәэмин итүләр өлкәсендә, төрле билгеләнештәге пилотсыз авиация комплекслары җитештерү буенча лидер.

– Без барыбыз да энтузиастлар – эш белән янып йөрүчеләр, безнең барыбызның да бөтенләй яңа әйберләр ясап карыйсы килә иде. Менә шушы омтылыш бүген дә безне һәм балаларыбызны уңыш юлыннан алып бара. Безгә хезмәткәрләребезнең балалары һәм оныклары эшкә килә икән, моның үзенең уңай яклары күп, – ди Валерий Побежимов. – Беренче чиратта, бу – яшь буынга алмаздай кырланган күнекмәләрне тапшыру. Әти-әнисе эзеннән барган балалар хаталар ясау баскычы аша сикереп үтеп, шунда ук һөнәри дәрәҗәдәге баскычка күтәрелә. Алар инде бу күнекмәләрне ничек кулланырга икәнен яхшы белә, бу исә файдалы эш коэффициентын да арттыра. «Алга һәм югарыга!» – менә нәрсә дип әйтер идем мин аларга.

ҖИҢҮ МОДЕЛЕ

Бүген «Эникс»ны югарыга, башлангыч чорындагы кебек, пилотсыз комплекслар гына түгел, авиамодельләр дә күтәрә. Предприятие инженерлары модельләрне үз идеяләре белән баета, яңаларын сынап карый.

– Абый да, мин дә авиамодельләштерү белән балачактан шөгыльләнәбез. «Эникс»ка мин 1983 елда модельче булып килдем, бүген ябыштыру бригадасын җитәклим. Минем белән абыем, аның ике улы, безнең икетуган һәм өченче буын туганнарыбыз, энекәшләр эшли. Барыбыз бергә бер гаиләдән 13 кеше, – дип сөйли Зөфәр Ваккасов.

Аның олы абыйсы Фәнис Ваккасов Авиатөзелеш районы мәктәптән тыш уку үзәгенең көймәләр модельләштерү түгәрәгендә укытуын дәвам итә. Түгәрәк җитәкчесе – аның улы.

– Модельләштерү һәм авиация төзелеше – үзара тыгыз бәйләнештәге өлкәләр. Мин үзем дә шушы һөнәри мохиттә үстем – башта авиамодельләштерү спорты белән шөгыльләндем, соңрак Казан моторлар җитештерү берләшмәсендә заводтагы түгәрәкне җитәкләдем, – дип сөйли Фәнис Ваккасов. – Без ярышларга йөри идек, ил күләмендә урыннар алганыбыз булды, гәрчә берсе дә җиңел генә бирелмәде. Аннан соң Валерий Побежимов «Эникс»ка модельләштерүчеләр чакыра башлады. Без, энем, мин һәм гаиләбезнең яшьләре, шулай итеп, бирелә эшли башладык. Яшь буын да минем түгәрәккә йөрде. Без бирелә – 13 кеше. Күптән түгел минем иң зур оныгым килеп китте, ул да модельләштерү белән шөгыльләнә, ошатты кебек. Безгә эшкә киләм, ди.

АВИАЦИЯ ҖИҢЕЛ ӨЛКӘ ТҮГЕЛ

Бүген пилотсыз авиация югарыга таба күтәрелә, дип әйтә алабызмы? Күчерелмә мәгънәдә, бәлки. Ләкин аның иртәгәсе көненең траекториясе – яшьләр кулында.

– Кызым Евгения «Эникс»ның перспективалы эшләнмәләр бүлегендә инженер-программист булып эшли. Миңа калса, аның кебек югары һөнәри техник белемле яшьләр өчен финанслар гына түгел, ә эшнең кызыклы булуы да мөһим. Безнеке кебек предприятиеләрдә, кагыйдә буларак, авиацияне яраткан кешеләр эшли. Бирелә олы җаваплылык һәм югары квалификация кирәк, – ди әйдәп баручы конструктор Владислав Варсегов. – Бүгенге шартларда авиация өлкәсендә эшләү өчен белем алу җиңел түгел: укуы авыр, стипендиясе бәләкәй,

Реклама

Фото: Александр Ефремов

Якуповлар (сулдан уңга): Якупов М. И., Якупов И. Р., Якупов Җ. И.

Саттаровлар (сулдан уңга): Саттаров А. С., Самигуллина И. С., Саттаров С. А.

перспективалары – томан эчендә. Болар илһамландыра, дип әйтеп булмый. Шуңа да әлеге һөнәрне сайлап, нинди дер уңышка ирешим дисәң, бу эш белән кызыксынырга, максатлар куеп, аңа омтылырга кирәк. Әлбәттә, безнең тармакта яшь белгечләр күбрәк булсын иде, дип телисе килә. Әмма бу алга таба эш урыннары тагын да күбрәк булдырылганда гына мөмкин.

– Эшләнмәләр ике-өч ел эчендә искерә. Даими рәвештә яңаларын эшләп торырга кирәк. Яңа технологияләр барлыкка килә, яңа бурычлар куела. Яшьләр өчен менә дигән мөмкинлекләр ачыла, – ди юнәлеш буенча баш конструктор Илдар Якупов. Биредә ул компаниянең беренче көненнән үк эшли. Илдар Рәис улының ике улы – Марат белән Җәннәт тә менә ун ел инде шушында җитештерүдә эшли.

– Предприятиегә мин үзем чакырдым аларны. Биредә алар чын мәгънәсендә канат астындагы кебек. Һәрвакытта да эш буенча нәрсәдер әйтеп җибәреп була. Икенче яктан, биредә эш дип янып яшәүче ышанычлы хезмәткәрләргә ихтыяҗ зур, – ди Илдар Якупов.

АЛАР – ДӘВАМЧЫЛАР

Компаниянең югары казанышлары – шул исәптән Валерий Побежимов һәм аның хезмәттәшләренең кадрлар сәясәтендәге дөрес методикасы да ул. Алар, белгечләрне мәктәптән үк үстерергә кирәк, дигән фикердә.

– Без хатыным белән «Эникс»та беренче көннән үк эшлибез дияргә дә була. Балаларны да үз куллары белән тотып эшләргә өйрәттек. Мәктәптә югары сыйныфларда укыганда, кызларыбыз да, улыбыз да эретеп ябыштыру, детальләр монтажлау, төрле җиһазлар җыю белән шөгыльләнде. Хобби иде ул. Аннан соң техник белгечлекләр алдылар. 2000 нче елларда андый белгечлек белән эш табу кыен иде. Шулай итеп, балалар монда эшкә килде, – дип сөйли юнәлеш буенча баш конструктор урынбасары Сөләйман Саттаров. Бүген «Эникс»та аның улы Айрат һәм кызы Илсөя эшли. Икесе дә – инженер-конструктор.

– Бездә династияләр күп. Әти-әниләр балаларын үз яннарыннан җибәрәсе килмәгәнгә түгел, алар үзләре кызыксынып бирегә килә. Күптән инде ияләшеп, мавыгып эшлиләр. Алар безнең эшне дәвам иттерер, дип ышанам. Илебез өчен кирәкле эш бит, – дип ышана Сөләйман Саттаров.

– Техника белән кызыксынуым нәселдән килә, дияргә дә була. Өлкән классларда укыганда, мин инде нинди һөнәр сайлаячагымны белә идем. Кайчандыр әтием кебек үк мин дә КМТТУ-КАИ тәмамладым. «Эникс»та 14 ел инде инженер-конструктор, куәт җайланмалары һәм реактив двигательләр буенча белгеч булып эшлим. Минем үз эшләнмәләрем дә бар, алар турында сөйли алмыйм, чөнки сер итеп саклана торган җитештерү өлкәсенә карыйлар, – дип аңлата Евгений Побежимов. Үзе белән бергә эшли торган кешеләрне ул балачактан ук белә, шуңа да предприятиедә үзен өендәге кебек хис итә. Бу – бик зур өстенлек, ди ул.

– Мин яшьләрне җитәкләп, һөнәр сайлату яклы түгел. Һәркем күңеленә ята торган һөнәрне үзе, мөстәкыйль рәвештә сайларга тиеш. Шул ук вакытта балаларым мин башлаган эшне дәвам итсә иде, дип тә телим, – дип сүзен йомгаклый Евгений.

Буыннар арасындагы бәйләнеш, дәвамчанлык, остазлык, яшь белгечләрне теоретик яктан гына түгел, аларны гамәлдә дә эшкә әзерләү – бүген илебез предприятиеләрендә әлеге традицияләр югалып бара диярлек. «Эникс» тәҗрибәсе шуны күрсәтә: ул традицияләрне кайтарып була, шулай кирәк тә. Нәкъ шушы юл уңышка алып бара да. ■

Ваккасовлар: Сафин М. И., Зверев С. А., Ваккасов Ф. К., Ваккасов М. Ф., Ваккасов Э. Ф., Сафин А. И., Ваккасов З. К., Сафин З. Р., Зверев А. С., Зверева Н. В., Сафин Р. Р., Зиннәтуллин А. А.

2003 елда КПАТП-1 АЖ базасында А. Н. Туполев исемендәге Казан милли-тикшеренү техник университеты – Казан авиация институты составында «Автомобильләр һәм автомобильләр хуҗалыгы» кафедрасы булдырыла. Кафедрага 17 ел инде техник фәннәр докторы, профессор Леонид Григорьевич Наумов мөдирлек итә. Компания базасында Казанда Татарстан Республикасының автотранспорт предприятиеләре өчен белгечләр әзерләнә.

Фото: Александр Ефремов

ПРЕДПРИЯТИЕНЕҢ АЛТЫН ФОНДЫ

Ир-егет өчен үз һөнәре буенча эшләүдән дә мөһимрәк тагын нәрсә була ала? «1 нче Казан пассажирлар автотранспорт предприятиесе» (КПАТП-1) Акционерлык җәмгыяте генераль директорының үсеш буенча киңәшчесе Леонид Наумов белән очрашканнан соң, балаларны үзеңнең һөнәри тормышыңа җәлеп итүнең тагын да кыйммәтрәк икәнен аңлый башлыйсың.

– Безнең предприятие шактый тотрыклы дияргә була. Күп кенә хезмәткәрләр дистәләрчә еллар эшли, – ди Леонид Григорьевич. – Алай гына да түгел, балаларын, җәмәгатьләрен, туганнарын да алып киләләр. Пенсия яшенә кадәр эшләгән машина йөртүчеләр бар. Алар арасында – Владимир Отряскин, Петр Ключников, Александр Школьников. Алар – безнең алтын фондыбыз. Алар хезмәт итеп кенә калмый, белемнәрен, тәҗрибәләрен яшьләр белән дә уртаклаша. Предприятие династияләргә бай. Әтиләре дә, балалары да эшләүчеләр бар. Петуховлар, Бәйрәмовлар, Лазаревлар, Нурисламовлар, мәсәлән, гаиләләре белән эшли...

Шулай килеп чыга: компаниядә Леонид Григорьевичның үзенең дә бертуган сеңлесе – Надежда Багоршина һәм ике кызы – Анна белән Елена эшли. Наумовлар династиясенә нигезне гаилә башлыгы 1975 елда – карьерасын Кама Тамагында эшләгәндә сала. Нибары ике ел үтүгә 26 яшьлек белгеч авыл хуҗалыгы техникасы идарәсендә Советлар Союзы буенча иң яшь җитәкче була. 1990 елдан ул КПАТП-1 белән җитәкчелек итә башлый. Утыз елга якын, олы кызы аны алыштырганчыга кадәр. Әйтергә кирәк, Наумов моның үз закончалыгын күрә. Нон-стоп режимында янып эшләүче әтисен күреп үскән кызның башка һөнәр сайлавы мөмкин дә түгел. Өстәвенә, Анна Леонидовна КФУның ике – икътисад һәм юридик факультетларын тәмамлаган, дәүләт хезмәтендә эшләү тәҗрибәсе дә бар. Аның акылы, энергиясе һәм холкы, әтисе әйтүенчә, өлкән Наумовка предприятиенең һәм анда эшләүче йөзләрчә хезмәткәрнең киләчәге өчен тыныч булу мөмкинлегe бирә.

Кече кызы Елена Казан дәүләт архитектура һәм төзелеш университетын тәмамлаган, ул да үзен нәкъ менә биредә – дизайн һәм маркетинг бүлеге башлыгы вазыйфасында тапкан. Соңгы елларда предприятие актив рәвештә җитештерү мәйданнарын яңарта, кунакханә комплексын реконструкцияли. Болар барысы да дизайнда яңа сүз таләп итә. Предприятиенең автобуслар паркы куркынычсызлык таләпләренә генә җавап биреп калмый, алар уңайлы да. Чехоллар, баш кую өчен җайланмалар, пәрдәләр – дизайнер өчен күз йомып кала торган бер генә нәрсә дә юк. Боларның барысы өчен дә бүген предприятиедә Елена Леонидовна җавап бирә.

Леонид Григорьевичның сеңлесе – Надежда Григорьевна Багоршина предприятиедә 16 ел эшли. Ул – кадрлар бүлеге башлыгы:

– Эшкә урнашырга теләүченең документларына карап кына, аңа кешеләр гомерен ышанып тапшырырга буламы-юкмы икәнен аңлау кыен. Шуңа да азаккы нәтиҗәне күзгә-күз карап сөйләшүдән соң гына ясыйбыз. Бәяләүнең төп критерийлары, билгеле ки, һөнәри осталык, җаваплылык, әдәплелек һәм итагатьлелек. Безнең ялгышырга хакыбыз юк, безнең машина йөртүчеләрнең күбесе шактый ерак рейсларга йөри, кайчак аларга корычтай сабырлык күрсәтергә туры килә.

Наумовлар династиясенең транспорт тармагында гомуми стажы – 87 ел. Леонид Григорьевич саннар белән горурланмый:

– Кайбер гаиләләрдә балалар башка шәһәрләргә, хәтта башка илләргә үк китә. Ә менә без бергә эшлибез һәм бер-беребез белән даими рәвештә аралашып торабыз. Менә инде оныгыбыз да балалар бакчасыннан соң безнең янга эшкә килеп китә...

2003 елда Наумовлар туган авылларында – республиканың Алексеевск районының Кыркул авылында өр-яңадан Изге Троица гыйбадәтханәсен төзи. Берничә ел элек паркбакча утырта, анда утыртылган алмагачлар инде уңыш биреп, аны ветераннар йортына җибәргәннәр. Предприятие балалар бакчаларына, мәктәпләргә, предприятиенең пенсионерларына, сугыш ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә ярдәм итеп тора.

Пассажир йөртүче оешмалар саны көннәнкөн артып тора. Казан транспортчылары алдына куелган бурыч та җиңелләрдән түгел – мөмкин кадәр күбрәк пассажирлар җәлеп итү. Моңа ничек ирешергә?

– Беренче чиратта, бу хезмәт күрсәтү культурасын, куркынычсызлык, җаваплылык һәм уңайлылык дәрәҗәсен күтәрү, – дип ышана Леонид Григорьевич. – Җәмәгать транспорты югары дәрәҗәдә оештырылса, без халыкны шәхси автомобиль дигән «баш авыртуыннан» һәм аның җаваплылыгыннан азат итәр идек. ■

Реклама



ЕВРОПАДА 500 нче TOTAL ROC СТАНЦИЯСЕ ЯР ЧАЛЛЫДА АЧЫЛДЫ

Чаллылар европача сыйфат белән тәэмин ителә башлады – бүген монда TOTAL QUARTZ халыкара энергетика концернының яңа инновацион станциясе ачылды. Станция машиналы кешеләрнең автомобильләрен хезмәтләндерү буенча эшне шактый җиңеләйтәчәк. Аның уңай яклары арасында – комплекслы хезмәтләндерү, бердәм сыйфат стандарты, профессиональ җиһазлар һәм хезмәткәрләрне укыту программасы.

Rapid Oil Change (ROC) экспресс рәвештә май алыштыру станциясе Яр Чаллыда декабрьдә эшли башлаган. Ул бик күп машина йөртүчеләргә вакытларын янга калдыру мөмкинлеге бирә. Компаниянең автокала белән кызыксынуы очраклы түгел, шәһәр Россиядә иң эре индустриаль үзәкләрнең берсе һәм үтә дә әһәмиятле транспорт юллары кисешкән урын булып тора, шуңа да бирелдә компания җитештерә торган продукциягә ихтыяҗ зур. Мондый станцияләр майлау материалларын алыштыру, техник ярдәм күрсәтү һәм вак-төяк ремонтлау эшләре буенча комплекслы хезмәтләндерү белән шөгыльләнә. Һәр станция бөтен челтәр өчен бердәм булган стандартларга ярашлы итеп җиһазландырылган. Сервисның тагын бер өстенлеге – станциядә эшләүчеләр өчен укыту программасының булуы, ул исә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын контрольдә тоту өлкәсендәге күнекмәләрне даими камилләштереп торырга, сервис станцияләре белән идарә итү юлларын киңәйтергә, челтәр буенча хезмәт күрсәтүне җәелдерү өчен цифралы ысуллардан файдаланырга ярдәм итә.

БЕЛЕШМӘ

ROCның Россиядәге беренче станциясе 2015 елда Барнаулда АвтоХИТ дистрибьюторы белән хезмәттәшлектә ачыла. Бүген РФндә TOTALның экспресс рәвештә май алыштыру буенча 35 сервис станциясе эшли. Хәзерге вакытта ROC станцияләре 16 илдә гамәлдә, алар арасында Россия, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Украина, Төркия, Болгария, Румыния, Италия, Венгрия, Испания, Португалия, Хорватия, Сербия, Словения һәм Греция бар.

Чаллы машина йөртүчеләре бөтенләй яңа дәрәҗәдәге сервис һәм уңайлылыкка, бер урында барлык проблемаларны хәл итү мөмкинлегенә ия. Хәзерге вакытта компания клиентларга хезмәт күрсәтүнең яңа һәм бик уңайлы One Stop Shop форматын эшләтеп җибәрде, бу берүк вакытта майны алыштырырга, автомобильнең нинди торышта булуын белгеләргә, компаниянең инновацияле тәкъдимнәреннән файдаланырга мөмкинлек бирә. Хәзерге вакытта компания станцияләрне эрерәк узел пунктлары итеп үзгәртү буенча актив эш алып бара. Алар тизлекне тәэмин итәчәк һәм транспорт чараларына хезмәт күрсәтәчәк.

Концерн өчен хезмәт күрсәтү буенча югары сыйфат дәрәҗәсенә ирешүдә төп принциплар – клиентка юнәлгәнлек һәм ышанычлылык. Шуңа да TOTAL ROCның теләсә кайсы станциясе – һәрвакытта да менә дигән хезмәт күрсәтү үрнәге, югары сыйфатлы продукт, хезмәтләндерүнең үтә күренмәле системасы һәм һәр клиентка шәхси якын килүне күз уңында тоткан уңайлы станцияләр.

Фотолар Rapid Oil Change (ROC) тарафыннан бирелде

Реклама

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Лениногорскида **КАЙДА** «җанлы тарих» яши

Халыклар дуслыгы музее **КАЙДА** урнашкан

Нәкый Исәнбәт юбилеен **НИЧЕК** каршылыйбыз

Аноним наркоманнар **НИЧЕК** яшиләр

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ

Яшәлгән һәр көн тарихка әйләнә. Ул фотосурәтләрдә, хатларда, әйберләрдә, җырларда, китапларда, мәктәп көндәлекләрендә, документларда кала... Соңрак, үткәннәрдәге әйберләргә карап, без кайчандыр, әле агачлар бик биек булган чакта, кичергән хисләрне, төсләрне, авазларны искә төшерәбез...

Татарстан Республикасы һәм аның адашы «Татарстан» журналының 100 ел яшәү дәверендә җөмһүриятебез халкында истәлекле әйберләр шактый тупланган. Гаилә тарихлары гаилә архивларында саклана, зур тарихны исә музейлар күз карасыдай саклый. Алар хәзер һаман саен күбрәк популярлаша һәм төрләнә, чөнки тамырларыбыз, бабаларыбыз, гореф-гадәтләребез белән кызыксыну сүнми, бәхеткә, арта бара.

Республикабыз кебек үк 1920 елда туган «Татарстан» журналы үзенең 100 яшьлек юбилеена музейлар марафоны үткәрергә – җөмһүриятебезнең гадәти булмаган 100 музеенда булырга карар кылды.

Бүген сезнең игътибарыгызга шундый берничә музейны тәкъдим итәбез.

ИҢ ШӘХСИ.
ЛЕНИНОГОРСКИДАГЫ НЕФТЬ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ ХАЛЫКЧАН.
ЧЕПЬЯДА ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ ШӘХСИ. НЕФТЬ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

Көзгеле лабиринтта адым саен – оптик иллюзияләр. Күп очракта каршыда кем басып торганын да аңлап булмый: үзеңме бу, башка кешеме? Алда – чиксезлекме яки тупикмы? Чираттагы борылышта нәрсә көтә – билгесез.

Автор:
Алсу Троицкая

Җиде яшьлек малай, ихластан елмаеп һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә әллә ни игътибар бирмичә, көзгеле дивардагы фотога бармагы белән төртә: «Бу бит минем апам!» – ди ул. Аклы-каралы фоторәсемдә ак халатлы лаборант хатын-кыз күпсанлы колбалар белән сәер манипуляцияләр ясый…

– «Җанлы тарих» дип аталган әлеге зал балаларга тылсымлы тәэсир итә, – дип аңлата Нефть музее экскурсоводы **Әлфия Гайфетдинова**. – Шатлыклары эчләренә сыймый, хәтта йөгерешә башлыйлар… Зал стеналары бездә булган күптөрле документларны, фотосурәтләрне сыйдырып бетерә алмый, шуңа күрә аларны интерактивка урнаштырдык. Мультимедиа чаралары ярдәмендә Лениногорск шәһәренең тарихи вакыйгалары эчендә кайный башлыйсың, аның мактаулы кешеләре турында беләсең, видеоархив белән дә танышырга мөмкин. Күпләр фотосурәтләрдә һәм видеоязмаларда туганнарын, күршеләрен, үзләрен таный. Бу – җанлы тарих.

Фото: Александр Ефремов

СССРдагы беренче Нефть музее Лениногорскида 1968 елның 1 октябрендә ачыла. Башта ул гадәти экспонатлардан оештырылган гади генә музей була. Бүген ул – яңа концепция, алдынгы технологияләр кулланылган, интерактивлар һәм мультимедиа чаралары, аудиовизуаль мөмкинлекләре булган һәм «Уңайлы мохит» программасы тормышка ашырылган музей. Анда ветераннар белән очрашулар, студентлар һәм мәктәп укучылары өчен экскурсияләр уза, музей республиканың көньяк-көнчыгышы туристлары һәм кунаклары өчен визит карточкасы булып тора.

ЧИШМӘ БАШЫ

«Җанлы тарих» залының көзгеле лабиринты чынлыкта музейның Лениногорск нефтьчеләренә багышланган өченче катында урнашкан. Татарстан нефте буенча экскурсия бина фойесына куелган экспонаттан башлана. Бу – бораy моделе. Нәкъ менә шушындый бораy, токымны кисеп, катламга үтеп керә, аннан безгә җир асты хәзиналәрен алып бирә инде. Ә без музейның беренче залына күтәреләбез һәм безнең чорга кадәр берничә мең ел элек булган вакыйгалар турында ишетәбелә алабыз.

Нефть җир өслегенә төрле сәбәпләр аркасында чыгарга мөмкин. Эчке фактор – аны тышкы якка тектоник активлык этеп чыгара. Тышкы сәбәп – токымнар юылу, шуның нәтиҗәсендә нефть кечкенә елгалар, сулыклар өслегендә май табы кебек тарала. Кешеләр аны борынгы чорлардан ук кулланган. Бөек Кытай дивары һәм Вавилон манарасын төзегәндә нефть файдаланылган. Мисырлылар аны фараоннарны бальзамлау өчен май составына кушкан. Барлык гасырларда да «җир мае», «тау мае»на ия булу мәмләкәтләрнең хәрби куәтен күрсәткән.

– Византия армиясе һәм флоты тарафыннан диңгез сугышларында һәм ныгытмаларны яулаганда кулланылган грек уты составына да нефть кергән, – дип сөйли безгә Әлфия Гайфетдинова. – Барысының да әлеге үлем утын ясау серен беләсе килгән, ләкин аны яшереп саклаганнар. Билгеле булганча, әлеге утның бер элементы – нефть.

«КАРА АЛТЫН» НИНДИ ТӨСТӘ?

«Тау токымы» сүзен ишеткәч, күз алдына нәрсә килә? Килешәсездер, нindидер каты матдә – мәрмәр, известь, гранит… Хәер, тау токымнары сыек һәм газсыман да була. Нефть – шундыйлар рәтеннән. Стендларның берсендә – төрле төстәге сыеклыклар булган биш колба. Ышанырлык та түгел, әмма болар барысы да нефть! Чия-кызыл төстәге нефтьне Бакуда, яшелне – Иранда, Көнбатыш Себердә, Самара һәм Ульяновск өлкәләрендә чыгаралар. Сүз уңаеннан, Татарстанда да бер тапкыр яшел нефть табылган – 1915 елда Сөйки таулары районында. Ком төсендәге нефть Кавказда табыла, су кебек төссезе – Иркутск өлкәсендә. Татарстан нефте исә чын «кара алтын» төсендә. Бер сүз белән генә әйткәндә, әлеге тау токымының төсе нәрсәләргә бәйле икәнен сезгә Нефть музеенда сөйләрләр.

БАРЛЫК СЫРХАУЛАРДАН ДА ДАРУ

1773 елда Россия империясе буйлап сәяхәт иткәндә, немец галиме, энциклопедист **Петр Симон Паллас**, халыкның җирдән чыккан нефтьне үз арбалары өчен яхшы майлау һәм дару чарасы буларак куллануларына игътибар итә: «Янәшә яшәүче чувашлар һәм татарлар әлеге сумаласыман суны авыз бозылганда һәм тамак авыртканда чайкау һәм эчү өчен генә файдаланып калмыйлар, ә аны җыеп, төрле очракларда дару итеп кулланыр өчен өйдә саклыйлар. Аны яңа яраларга сылыйлар, шулай иткәндә, яра, имеш, тиз төзәлә… Нефтьне эчү аеруча игътибарга лаек, бер кашык нефтьне алып, сөттә кайнаталар, ул куе каймакка әйләнә. Шуны җылы килеш эч авыртудан эчәләр».

БЕРЕНЧЕ ШӘХЕС. ЭШЛЕКЛЕ

Нефтьне мондый сәер куллануда тәэсирләнеп, Петр Iнең тау иреге принциплары турындагы боерыгыннан өзекләр укыйбыз. Документ буенча, теләсә кайсы кеше, дәрәҗәсенә, кайсы катлауга керүенә карамастан, үзенең җирендә файдалы казылмалар чыгара ала. Бары тик салым түләргә һәм бу хакта, һичшиксез, хакимияткә хәбәр итәргә кирәк. Бу шартлар үтәлмәгән очракта, җавап тотарга туры киләчәк, хәтта үлем җәзасы белән дә яныйлар.

Россия һәрвакыт булдыклы кешеләргә бай булган. Шуларның берсе – ватандашыбыз **Надыйр Уразмәтов**. Ул үз кишәрлекләрендә нефть чыгарырга, аны эшкәртергә һәм сатарга рөхсәт сорап берг-коллегиягә мөрәҗәгать итә. 1754 елда аңа рөхсәт бирелә. Тиздән эшмәкәр авырудан үлеп китә, ә улы һәм оныгы аның эшен дәвам итәргә теләми. Әмма Уразмәтов тарихка беренче татар нефть сәнәгатьчесе буларак кереп кала.

ИКЕНЧЕ ШӘХЕС. АВАНТЮРИСТ

Соңрак, нефть чыгару мәсьәләсе белән Император Фәннәр академиясе кызыксына башлап, безнең якларга галимнәрне җибәргәч, нефтьне бораулау ысулы белән чыгару буенча беренче омтылыш ясала. Әмма табыш булмаганлыктан, эш туктатыла. Чираттагы тарихи сәхифә чыгышы белән венгр булган Америка эшмәкәре **Ласло Шандор** исеме белән бәйле. Аның нефть табуга бәйле гаять зур планнары тормышка ашмый кала. Венгр бөлгенлеккә төшә.

– Җир-анабызның чит ватан баласына үз хәзинәләрен ачасы килмәгән, – дип, кыска һәм төгәл итеп йомгаклап куйды сүзен безнең гид…

ӨЧЕНЧЕ ШӘХЕС. ҮЗГӘРЕШЛӘР ЧОРЫ

Татарстанның көньяк-көнчыгышында нефть эзләү өч гасырдан артык дәвам итә. Хәлиткеч вакыт Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Музейдагы слайд-шоуда Татарстан территориясендә урнашкан беренче скважинаны бораулап, нефтькә кадәр төшеп җитүчеләрнең йөзләрен күрергә мөмкин. **Нурсинә Сөләйманова** – хәзер инде ул тарихи вакыйгаларда катнашучылар арасында исән калган бердәнбер кеше, ноябрьдә аңа 101 яшь тулды.

Сугыш елларында хатын-кызлар бораулау эшләрендә дә фронтка киткән ир-атларны алыштыра. Бригаданың верховой эшчесе булган Нурсинә сменага чыга һәм... йокымсырап китә. Күзләрен ачып җибәрсә, бораулау урынында нефть күренә. Ул бораулау остасы Гариф Хәмидуллин землянкасына йөгерә. «Нефть чыкты!», – дип хәбәр сала кыз. Соңыннан исенә төшерә: төшендә скважинадан чыгып баручы сарык көтүен күргән була ул. Мондый төш – табышка һәм муллыкка, диләр.

Нефть музеенда Нурсинәнең шәхси әйберләре арасында әбисеннән калган Коръән саклана: «Ул авыр вакытларда безгә догалар гына ярдәм итте. Сменадан соң, салкында берничә километр урман аша өйгә кайтканда, кызлар белән кычкырып догалар укый идек, безнең тавыштан бүреләр дә куркып качкалады...»

Нефть – әйләнә-тирәбездәге күпчелек көнкүреш әйберләренең нигезен тәшкил итә. Хәтта шпротларны консервлаганда да нефть эшкәртү продуктлары өстәлә...

ДҮРТЕНЧЕ ШӘХЕС. ХЫЯЛЛАРНЫ ЧЫНГА АШЫРУЧЫ

Музейдагы картада вакыйгаларның хронологиясе күрсәтелгән. Менә Баулы ятмалары табылган вакыт – ул 1900 метр тирәнлектәге девон катламнарында нефть булуын раслый. Ә менә тагын бер мөһим вакыйга – Ромашкино нефть ятмасы барлыгы ачыклана... Шулай итеп Татарстан үзен бай нефть төбәге итеп таныта.

Зур нефть залы. Монда барысы да кызыклы! БУ-75 бораулау җайланмасы макеты һәм 60–80 нче елларда алыштыргысыз булган вертолет макеты, заманында аның ярдәмендә Татарстан нефтьчеләре Көнбатыш Себер ятмаларын үзләштерә. Роторлы һәм аңа алмашка килгән турбиналы бораулау үзенчәлекләрен күрсәтүче макетлар. Киселештә күрсәтелгән нефть катламнары, төрле конструкция беркеткечләре...

Тагын бер кызыклы экспонат – катламның контур эчен тутыру ысулы күрсәтелгән макет.

– Әлеге ысул нәкъ менә Ромашкино ятмасында уйлап табылган, шуңа күрә мин бу турыда һәрвакыт теләп сөйлим, – ди Әлфия. – Бу ысул өчен безнең галимнәргә һәм белгечләргә Ленин премиясе бирелде. Аның ярдәмендә республика нефтьчеләре йөзләрчә миллион сум акчаны янга калдыра алды, эш темплары артты. 1970 елда 100 миллион тонна нефть чыгарылды, бер елдан соң ук беренче миллиард тонна нефть табу күрсәткеченә ирешелде, 1981 елда – икенче миллиард тонна, 2007 елда – өченче миллиард тонна...

Бу музей–нефть турында, әмма, беренче чиратта, ул нефтьчеләргә багышланган. Тармакка нигез салучылар, белгечләр, чын хезмәт геройлары турында сөйли ул. Аларның гаять авыр һәм искиткеч тормышы турында. Шуңа күрә бирегә килгән һәр кеше өчен Нефть музее үзенчә якын, үзенчә кадерле...

НӘРСӘ:
Татарстанның
Нефть тарихы музее

КАЙДА:
Лениногорск шәһәре,
Ленин ур., 3 йорт

КАЙЧАН:
Көн саен 8:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр. Шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

ИҢ ХАЛЫКЧАН.
ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

Чепьяда Халыклар дуслыгы музее бар дигәч, әллә ни гаҗәпләнмәдем. Авыл күпмилләтле, һәм биредә шундый исемдәге музей булу табигый кебек тоелды. Ләкин аны бу дәрәҗәдә зур дип уйламаган идем. Зурлыгы гына түгел, экспонатларының күплеге, темаларының төрлелеге белән дә шаккатырды ул.

Автор:
Руфия Фазылова

93 ЯШЬТӘ – ДИРЕКТОР

Сүзне музейның иң уникаль экспонаты, әй, нәрсә язам инде, җитәкчесеннән башлыйсым килә. «Уникаль» дигәндә ялгышмадым үзе. Музейны беренче көннән үк җитәкләгән, һәр экспонатын бөртекләп җыйган кеше – СССРның халык мәгарифе отличнигы, икенче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены иясе Гарифҗан Галиев. Илле өч ел дәвамында әлеге музейны җитәкли ул! Бүген аңа 93 яшь. Сүз уңаеннан, күптән түгел генә музейга Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов килеп китте һәм ветеранга Җиңүнең 75 еллыгына багышланган беренче медальне тапшырды.

– «Татарстан» журналының бер санын да калдырмыйча укып барам, – дип каршы алды безне Гарифҗан ага. – Аеруча талантлы татар егет-кызлары, ил күләмендә танылган милләттәшләребез турындагы язмаларыгыз ошый. Мин һәр татарның уңышына сөенәм, уңышсызлыгына көенәм...

Ул да түгел, музей директоры аталарча сорап куя:

Фотолар авторныкы

– Юллар ничек булды, ардырмадымы?

«Юк», дигән җавап ишеткәч, үзе артыннан барырга ишарәләп, күрше залга чакырды.

Гади бер авылда мондый масштабтагы музей булу, тыйнак кына әйткәндә, гаҗәп. Казанның да кайбер музейларын Чепьяныкы белән чагыштырып булмый хәтта. Әлеге фикеремне Гарифҗан агага да әйттем:

– Әйе, музеебыз бик шәп. Узган ел капиталь ремонт ясалды. Бик кирәк иде ул безгә, – диде.

Биредә барлыгы ун зал. Беренче катта – төрле халыкларның көнкүреш кирәк-яраклары, Чепья җирлегендә яшәгән халыкларның милли киемнәре. Һәр халыкның тормышын яктырткан аерым почмаклар да булдырганнар. Шәхсән миңа чулпы таккан татар кызы белән мари кызы ошады. Икесе дә үргән чәчләр белән ясалган, ә чулпылары төсе, зурлыгы буенча нык аерыла! Шушы милли курчакларга сокланып тора идем, Гарифҗан абый кисәтү ясады:

– Миңа кара әле. Кешедә маңгай күзе, күңел күзе була. Син шуның икенчесе белән күр, – диде.

Елмаеп куйдым. (Әңгәмәдәшем укытучы да бит. Ә алар укучының игътибар белән тыңлыймы, юкмы икәнен тиз абайлыйлар). Тарихчы борынгы картага төртеп күрсәтте.

– Бу – борынгы Чепья авылы. Революциядән соң биредә атаклы базар булган. Әллә ничә чакрымнардан килеп сәүдә иткәннәр…

Гарифҗан аганы дикъкать белән тыңлаганнан соң, музейның барлыкка килү тарихы белән кызыксындым:

– Җиңүнең 20 еллыгы якынлашкан вакытта барлык мәктәпләргә юбилей датасына багышланган почмак булдырырга куштылар, – диде әңгәмәдәшем. – Ул вакытта мәктәптә 5 тарих укытучысы эшли идек. Алар арасында иң яше булганга, күрәсең, музей почмагы ясауны миңа йөкләделәр. Өемдә фронттан кайткан 133 төрле предмет бар иде. Музей почмагы өчен шулар беренче экспонатлар булды.

Менә шулай итеп мөгаллим җирле тарих белән кызыксына башлый. Авыл буйлап балалар белән фронт хатларын, документларны җыеп йөргәндә, бер фикергә килә: эшне болай гына туктатырга ярамый. Халыкта әнә никадәр кызыклы ядкарьләр бар икән. Аларны бергә тупларга кирәк!

– Экспонатлар эзләп йөргәндә, балаларның күзендә якты нур балкып торды, шундый зур кызыксыну туды ки, туган як тарихын өйрәнү буенча тарихи түгәрәк булдырдым, – дип сүзен дәвам итте Гарифҗан ага. – Җир өстеннән генә түгел, тарихи әйберләрне җир астыннан да эзли башладык. Укучылар белән археологик эзләнүләр башлап җибәрдек. Бүген музей фондында тупланган әйберләрнең 97 проценты – Чепья урта мәктәбендә белем алган малай, кызларының хезмәте ул. 50 ел эчендә без 22 меңнән артык экспонат җыйдык.

СУГЫШ ЭЗЕ...

Бу якларда булган кешеләр хәбәрдар – Чепья күпмилләтле авыл. Удмурт, татар, мари, рус, чуваш милләтеннән булган кешеләр үзара дус, тату яши. Һәм бу буыннан-буынга шулай күчеп килгән. Музейны «Халыклар дуслыгы» йорты дип атау да нәкъ менә шуның белән бәйле. Чепья мәктәбендә укыган кем белән сөйләшсәң дә: «Ул музейга минем дә өлеш керде», – дип искә ала. Хәтта Гарифҗан ага бер кызык хәлне сөйләп көлдерде:

– Башка милләтләрнең кул беләзеге бар, татарныкы гына юк, – дип музейга килгәч мәктәп укучыларына сөйләп торган идем. Икенче көнне ни күрим: бер укучым калын көмеш беләзек алып килде.

– Әнинең кулыннан салдырып алдым, – диде. Аптырап киттем. Ул малайның әнисен очраткач: «Беләзегегезне үзегез бирдегезме?» – дип сорадым.

– Үзем, – диде. – Менә шулай, сеңлем, музей дип, ата-аналар да җан атып торды.

Сөйләшә-сөйләшә, җитәкче белән икенче катка күтәрелдек.

– Мин инде – «карт бүре», бер нәрсәдән дә курыкмыйм, – диде Гарифҗан ага. – Казанга җыелышларга барсам, торып басып, сүземне туп-туры әйтәм.

Музейга бер ел элек булган ремонтны күздә тотып шулай ди җитәкче. Бездә бит еламаган балага имезлек каптырмыйлар...

Гарифҗан Галиевнең тормышы сугыш белән бәйле дип язган идем. Язмышы белән кызыксынгач, музей җитәкчесе менә нәрсәләр сөйләде:

– Арбор авылында туганмын мин. 1927 елны Арборның егермедән артык гаиләсе, карурманны чистартып, йортлар салган. Яңа авылга Каенсар дип исем биргәннәр. Әти-әни яңа нигезгә күченгәндә, миңа җиде ай була. Авыл зур булмаса да, бик матур иде. Башлангыч классларны Субаш мәктәбендә укыдым, аннан 7 классны Түнтәр мәктәбендә тәмамладым. Иң яраткан фәнем тарих иде. Шул юнәлештә укырга керәсем килде. Тик укый алмыйча калдым – сугыш башланды. Колхоз эшендә эшләдем, урман кистем. Унҗиде яшем тулганда хәрби училищега алдылар. Бер елдан инде һава флотында Ил-2, Ил-10 маркалы самолетларда радист-укчы булып хезмәт иттем. Аларны халык телендә «оча торган танклар» дип йөртәләр. 6,5 тонналы бронялы бу авыр техника күперләр, дзотларны юкка чыгару өчен, танкларга каршы сугышта кулланыла.

Гарифҗан агага төрлесен күрергә насыйп була: бер операция вакытында каты яраланып, тугыз ай госпитальдә ята. Туган ягына 1948 елда гына әйләнеп кайтырга насыйп була. Фронттан кайткан егетне Пыжмара мәктәбенә военрук итеп эшкә билгелиләр. Шул елларда ул читтән торып югары белем алырга да өлгерә. Әле биш ел Пыжмара авылында колхоз рәисе дә булырга туры килә үзенә.

ПУЛЕМЕТНЫ АВТОБУСКА ТӨЯП – АВЫЛГА!

Бөек Ватан сугышына багышланган залда безне тәлинкәле радиодан яңгыраган Левитан тавышы каршылады. Көн дәвамында ул шулай сөйләп тора икән. Бәгырьләргә үтә торган бу тавышны моңарчы әллә никадәр ишетсәм, тыңласам да, яңадан тораташ булып каттым. Ә әлегә кадәр егетләрчә гайрәтле әңгәмәдәшем кинәт кенә моңсуланды.

– Сугыш башланганда миңа 14 яшь иде, – дип, нечкәреп китте ул. – Шул елны мин әнисез калдым. Һич онытасым юк: басуга эшкә киткәнемне әни, болдырга басып, бик озак карап калды. Мин дә кат-кат борылып карадым. Бүтән көнне алай итми идем. Басуга барып озак та эшли алмадым, бер бала йөгереп килде. «Әниең үлә...», – диде. Әнигә инсульт булган. Ул вакытта «паралич суккан» дияләр иде. 14 яшемдә әнинең ләхетен үзем алдым...

Музейның әлеге залы берничәгә бүленгән. Сугыш коралларына багышланган ягы бар. Анда шактый тарихи, үзенчәлекле экспозицияләрне күрергә була. Мисал өчен, Емельян Пугачев явы заманнарындагы металл кистән, 1840 елда Тулада җитештерелгән зиннәтле рус кылычы, XIX гасыр урталарындагы француз шпагасы... Шулай ук Америка, Бельгия, Төркия, Германиядә эшләнгән наганнар, маузерлар, винтовкалар, Австрия флягасы белән дә танышырга мөмкин.

Һәркайсының музейга килеп эләгүенең үз тарихы бар. Гражданнар сугышы залындагы 1908 елгы «Максим» пулеметының тарихы исә аеруча гаҗәп тоелды. Эш менә нәрсәдә: бу якларда Гражданнар сугышы бәрелешләре күп булган. Кызылгвардиячеләр Колчак армиясенең алга баруын

Нократ ярында туктата алган. Ул урын Балтач авылына 17 чакрым тирәсе ераклыкта урнашкан. Гарифҗан ага әлеге тарихи вакыйганы ныклап өйрәнә. Ун ел буе ул укучылары белән шушы урыннарда казу эшләре алып бара. Тырышлык бушка китми – сугыш кораллары табыла, берничә «Максим» пулеметы патроннары, гильзалары да килеп чыга. Тик тынгысыз укытучы моның белән генә тукталмый – пулеметның үзен эзли башлый. 1989 елда ул Татарстан хәрби комиссариатына хат яза, әмма аның үтенечен кире кагалар. Шуннан соң да музей директоры бирешми, хатны кулына тотып, Казанга китә. Баш комиссар ишеген шакый. Ә ул исә ветеранны кире борган хезмәткәрне чакыра да:

– Аңа формаль җавап түгел, «Максим» бирергә кирәк! – ди.

Нәтиҗәдә, пулеметны Пенза өлкәсендәге бер хәрби частьтагы складтан табалар. Гарифҗан ага алар белән элемтәгә керә.

– Килеп алыгыз, ләкин юлга машинада чыгыгыз, янгыгызда озата баручы да булсын, – диләр.

Машиналарны бармак белән генә саный торган чорда музей директоры техниканы кемнән сорасын инде? Гарифҗан ага, тәвәккәлләп, ялгызы юлга кузгала. Хәрби частьта кырт кисәләр:

– Пулеметны машинада гына йөртергә ярый, – диләр.

Озак сөйләшү-аңлашулардан соң ветеранга «Максим»ны бирәләр. Әле вокзалга кадәр илтеп тә куялар. Бу хәлгә куанып бетә алмаган музей директоры гаять дулкынлана, машинада пулеметның чехолын да онытып калдырганлыгы ачыклана. 62 килограммлы пулемет күтәргән агайны, аңлашыла инде, поездга кертмиләр. Гарифҗан абый югалып калмый: коралны сүтеп, өч кисәккә аера да вагонга кереп утыра. Гөнаһ шомлыгына каршы, билет тикшерүче ревизорның аягы «Максим»га тиеп китә. Тарихчыга тагын музейга экспонат алып кайтуын озаклап аңлатырга туры килә. Казанга кайткач, шушы пулеметы белән шәһәр буйлап атлый. Кешеләр, бу тамашага аптырап, борылып-борылып карый...

Озын сүзнең кыскасы, Гарифҗан ага маршрут автобусында пулеметны музейга алып кайтып җиткерә. (Күпме кул күтәреп торса да, юлда бер генә җиңел машина да туктамый.) Музейның яңа экспонаты өчен иң сөенгән кешеләр мәктәп балалары була. Бигрәк тә малайлар!

ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫНДА...

Музейның тагын бер залына аяк баскач, аптырап китәсең. Монда сине кошлар сайравы каршы ала. Башта агачтагы нәни кошчыклар сайрый, дип уйлыйсың. Аннан соң ул агачның – ясалма, ә кошларның бары сөкәтләр (чучело) икәнен аңлыйсың. Шулай ук биредә аю, бүре, башка дистәләгән җанварларның сөкәтләрен күрергә була. Барысы да чыпчын кебек.

– Бу җанварларның барысы да сезнең якларда яшиме? – дим Гарифҗан агага.

– Бөтенесе дә түгел инде. Шулай да аратирә күрергә була. Мәсәлән, тайга урманнарыннан безгә аюлар килгәне бар, күрүчеләр дә булды. Бу зал балалар өчен дип эшләнде. Тарих белән бергә табигатьне дә белсеннәр дип.

Әлеге сөкәтләр музейга шактый еллар элек кайтарылган. Берсе-берсе генә дә 60–70 мең сум тирәсе тора икән. Аларны махсус препаратлар белән эшкәртеп, тузаннан арындырып торалар.

– Минем кызлар бик әйбәт бит, – диде җитәкче. – Музейда эшләүчеләр – үз укучыларым. Алар килгән кешеләргә экскурсия дә үткәрә, барлык экспонатларны да менә шулай тәртиптә тота. Тормыш иптәшем вафат булганга егерме ел инде. Алар мине әтиләре урынына карый. Зур рәхмәт үзләренә!

Экскурсиягә килгән кешеләрнең яратып фотога төшә торган урыны әлеге зал икән. Тагын кечкенә балалар да озак итеп биредә йөри, диде907ләр.

Музейдагы палеонтологик, археологик экспозицияләр дә кызыклы тоелды. Мисал өчен, шушы җирлектән табылган мамонтның 2 метр озынлыктагы казналыгы гына да ни тора. Аның авырлыгы 137 килограмм икән.

...Менә шундый ул Халыклар дуслыгы музее. Әлбәттә, бөтен экспонат турында сөйләп бетереп булмый. Шуның өчен аны барып күрергә кирәк. Биредә эшләүче кызлар сезгә алар турында бик яратып сөйләр. Бер уңайдан Балтачның легендар шәхесе – Гарифҗан Галиев белән дә танышырсыз. Иртәнге сигездән кичке алтыга кадәр һәр көн шунда ул.

НӘРСӘ:
Халыклар дуслыгы музее

КАЙДА:
ТР, Балтач районы, Чепья авылы

КАЙЧАН:
Көн саен 8:00 сәгатьтән 18:00 сәгатькә кадәр.

ИСӘНБӘТ –
ҮЗЕ БЕР ДӘҮЛӘТ

Шагыйрь, драматург, публицист, үткен телле тәнкыйтьче, тәрҗемәче, текстолог һәм фольклорчы галим Нәкый Исәнбәтнең тууына 120 ел тулды. 92 ел гомеренең 80 елы дәвамында халкына хезмәт иткән тирән фикерле әдип һәм галимнең иҗаты, шәхси тормышы гаять үзенчәлекле. Әдәбият йә фән мәйданында аның кебек киң колач җәеп, җигелеп эшләгән башка берәүне замандашлары арасыннан атавы да кыен. Ил, милләт өчен катлаулы елларда да ул үз кыйбласын саклап кала алган шәхес. Төрле яктан кысу, эзәрлекләү, гаепләү-мәсхәрәләргә дучар ителгән булса да, татар халкына бай мәдәни мирас калдыра алган Нәкый Исәнбәт.

Автор: Мөршидә Кыямова

«ЗУР ШАГЫЙРЬЛӘРДӘН ТУКАЕВ БУЛСА ХӘЛФӘ, МИН – ШӘКЕРТ!»

Аның автобиографик язмасында мондый юллар бар: «...Хәтеремдә: безнең өйдә хатын-кызлар мәҗлесе бара иде. Габдрахман абый: «Алар җыен юк-бар сүз сөйләшеп утыралар, бар әле, «Шүрәле»не кереп укы әле шуларга!» – ди. Ә минем өчен шигырь укудан да рәхәт эш юк. Кердем дә, укый да башладым. Апалар, җиңгиләр тәмам аптырап утыралар, китап тыңлагандай тыңлыйлар. Мин аның саен дәртләнебрәк укыйм. Җиңгиләр чынаякларын да оныттылар хәтта. Онытылмаслыкмыни: үзебезнең телдә бит! Мин укып бетергәч, беравык таң калып тын гына утырдылар. Шуннан берсе торды да:

– Мә, шәкерт, дога кылып ал! – дип, миңа унбиш тиенлек көмеш бирде. Беләсегез килсә, әнә шул булды минем беренче гонорарым!»

Исәнбәт иҗат белән иртә кызыксына башлый. Унбер-уникe яшьләрендә инде ул мәдрәсәдәге иптәшләре арасында шигырьләре белән таныла, ә унбиш яшеннән матбугатта басыла башлый: 1914 елда Казанда чыга торган «Ак юл» исемле балалар журналында аның беренче шигырьләре дөнья күрә. Тәүге әсәрләренә ул «Н.И.», «Кара сакал», «Мәргән», «Аллаяр», «Дәрвиш», «Кабил», «Мәлгун» һ.б. тәхәллүсләр куя.

Нәкый Исәнбәт хатыны Гөлсем белән.

«Нәкый – табигате белән бик шат, уенчак кеше. Сахраларга чыкканда яшел үлән өсләрендә балалар кебек тәкмәч атына, ауный, бөтен яланны яңгыратып иһаһайлап кычкыра, табигатьнең эчендә табигатьнең нәкъ үзе белән бер булып тоташа. Тормышта бер вакытта да төшенкелеккә бирелми. Кешеләрне дә шулай булырга өйрәтә. Әмма эшкә утырса, бу вакыт бик җитди була. Исенә төшермәсәң, ашап-эчеп алырга кирәклекне дә белми. Урын сайлап тормый, һәркайда эшли, яза, урын булмаса, тезенә куеп булса да яза бирә. Эшеннән кузгатканны, яки турыдан-туры әдәбият-сәнгатькә катнашы булмаган җыелышларга йөрүне бер дә яратмый» **(Гөлсем Исәнбәт).**

«Зур шагыйрьләр дөньясына күзне салганда туры,
Анда оҗмах төсле татлы көн күрүләр ялтырый.
Мин дә кермәкче буламын шул иҗат дөньясына,
Гомерың, Байроннарың йөзгән шигырь дөньясына.
Тик җыен көндәш белән тулган минем арт-алларым,
Шул теләгемнән көлә барча минем дошманнарым.
Барча азгын, барча дошман булса ни дә торса – чурт!
Зур шагыйрьләрдән Тукаев булса хәлфә, мин – шәкерт!»

(«Тукай остаз» шигыре)

Нәкый – шәкерт. 1916 ел.

Тора-бара Нәкый иптәшләре арасында «шигырь чыгаручы», дигән мактаулы исем ала. Милли-мәдәни алгарыш рухын күңеленә сеңдерә барган малайны иҗат эше тулысынча үзенә бөтереп ала.

ИНСТИТУТКА ТИҢ ХЕЗМӘТНЕ БЕРҮЗЕ БАШКАРГАН ГАЛИМ

Кырык меңгә якын берәмлекне үз эченә алган өч томлы «Татар халык мәкальләре» (1968 елда Г. Тукай премиясенә лаек була), илле мең берәмлектән гыйбарәт ике томлы «Татар теленең фразеологик сүзлеге», һәркайсы бишәр-алтышар йөз битле «Татар халык табышмаклары», «Балалар фольклоры» китаплары, мәшһүр «Идегәй» дастанының халыктан үзе язып алып бастырган варианты – болар үзләре генә дә тулы бер гыйльми институтның күпьеллык тырыш хезмәтенә торырлык. Китапларга кергән мәкальләр-табышмаклар, фразеологик берәмлекләр теоретик яктан тикшереп анализланган, тәртипкә салынган, тарихи чыгыш-үзгәрешләренә караган оригиналь фикерләр бирелгән. Бу басмалар татар телен, халык авыз иҗатын өйрәнү юлында фән ирешкән фундаменталь һәм уникаль хезмәтләр булып санала.

«Әсәрләрен кат-кат эшли. Эшләгәндә, башына ял бирү өчен, яза торган әсәрен туктатып, арага фольклор, сүзлек, әдәбият тарихы, борынгы әдәбият буенча ни дә булса кертеп эшләп ала. Шуңа күрә аның өстәле яки тирә-ягы бик күп төрле китаплар белән капланып беткәнлектән, ул өстәлнең бер җирендә генә сыярлык калган урында яза. Куйган китапларны, язмаларын берәр ничек тәртипкә китерергә, кузгатырга һич рөхсәт итми. Нәкый яшьтән үк дөнья әдәбиятындагы язучылар, философларны укып танышып барган. Кулына төшкән китапларны чайкап кына эчми иде. Һәрбер хәрефен сыгып үзенә кирәк фикерне ала, үзенең карашын чагылдырып аркылыга-буйга сыза, төрле билгеләр куя», – дип язып калдырган истәлекләрендә хатыны Гөлсем Исәнбәт.

МОҢ БЕЛӘН СУГАРЫЛГАН ИҖАТ

Нәкый Исәнбәтнең «Уракчы кыз», «Бормалы су», «Гармунчы егет», «Син сазыңны уйнадың» һ.б. шигырьләренә иҗат ителгән җырлар бүген дә җырчылар тарафыннан яратып башкарыла, зәвыклы замана тыңлаучысы аларны әле дә җылы кабул итә. Татар моңы-сагышы белән сугарылган әсәрләрдә тулы бер милләтнең тарихы чагылыш таба. Әйтик, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең визит карточкасы саналган һәм Җир шарының төрле кыйтгаларында яңгыраган «Гармун, гармун» әсәре бүген дә Нәкый Исәнбәтнең данын еракларга танытуны дәвам итә.

Нәкый Исәнбәт драматургиянең төрле жанрларында үзен остаз итеп таны-

Фотолар Исәнбәтләрнең гаилә архивыннан алынды



Нәкый Исәнбәт Мәскәүдә. 1922 ел.

Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы Нәкый Исәнбәт яңа стиль белән 1900 елның 10 гыйнварында Башкортостан Республикасы Салават районының Малаяз авылында Сираҗетдин хәзрәт белән Таибә абыстай гаиләсендә туа. Бәдән ягыннан зәгыйфьрәк булса да, зиһенле бала 3–4 яшеннән хәреф таный башлый. Өйдә әтисеннән беренче сабаклар ала. Бер ел авылда әтисе ачкан җәдит мәктәбендә башлангычны укый, ә инде тугыз яшендә аны Уфа шәһәрендәге «Хәсәния» мәдрәсәсенә җибәрәләр.

Аннан соң Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә укый. Февраль революциясеннән соң, кыска сроклы педагогия курсларын тәмамлагач, 1917–1920 елларда туган төбәге авыллары (Атау, Тазтүбә, Үрге Кыйгы) мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1920–1922 елларда, укытучылык хезмәтеннән аерылмыйча, Уфа Халык мәгарифе институтында һәм Харьков университетының халык мәгарифе факультетында белем ала. Мәсәгут педагогия курсларында, Уфадагы урта белем бирү һәм совет-партия мәктәпләрендә, театр училищесында тел-әдәбият укыта.

1929 елның ахырларында Нәкый Исәнбәт Татарстанга күчеп килә. Казандагы сәнгать, кооперация техникумнарында, химия-технология институтында укыта, «Спартак» аяк киемнәре фабрикасында – эшче (1930–1932), Әтнә районында мәктәпләр буенча методик кабинет мөдире булып эшли. 1940 елдан Нәкый Исәнбәт – язучы-профессионал сыйфатында әдәби һәм гыйльми иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

та. Аның 30 дан артык драма әсәре бар. «Исәнбәт мәктәбе» дисталәгән яшь артистка югары күтәрелү өчен канат бирде. Аның әсәрләре хәзер дә татар театрлары репертуарын баетып тора. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында гына да төрле елларда аның «Хуҗа Насретдин», «Миркәй белән Айсылу», «Һиҗрәт», «Зифа», «Рәйхан», «Портфель», «Мулланур Вахитов», «Муса Җәлил», «Гөлҗамал» һ.б әсәрләре сәхнәләштерелгән.

Улы – танылган режиссер Празат Исәнбәт. Театр сәнгатендә дан казанган шәхес, замандашлары сөйләвенчә, әтисе кебек үк зыялы, эрудицияле һәм киң кырлы иҗатчы. Аның гаҗәеп оста рәссам булганлыгы да мәгълүм.

Быел Нәкый Исәнбәтнең тууына 120 ел уңаеннан Казанда Г. Тукайның әдәби музее «Мин – Тукайның замандашы» дигән очрашу оештырды. Очрашуда әдипнең кызы – күренекле музыка белгече, әдипнең архивын кадерләп саклаучы Йолдыз Исәнбәт, оныклары, туганнары, галимнәр, язучылар һәм артистлар катнашты. Исәнбәтнең сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Драма әсәрләреннән өзекләр һәм гыйбрәтле истәлекләр белән үрелеп барган искә алу кичәсендә чыгыш ясаган һәр кеше аның татар мәдәниятенә керткән олы хезмәтләрен атады, катлаулы иҗат юлы хакында бәян итте.

Татарстанның халык язучысы Роберт Батулла болай дип искә алды: «Нәкый Исәнбәт белән безнең беренче очрашу 1956 елның 27 августында Г. Камал театрында булды. Мәскәүгә артистлыкка укырга китүче яшьләрне шагыйрь, галим, драматург Нәкый Исәнбәт белән күрештерү кемнең акыллы башына килгәндер, әмма бу тарихи очрашу, шәп һәм бик тә кирәкле очрашу иде! Нәкый ага яшь күңелләргә үрчемле орлык салып калдырган. Без кыска гына шушы дәрестә татар халкының данлы һәм фаҗигале узганы турында, аның күренекле шәхесләре турында ишетеп белдек. Хәйләкәр Нәкый ага шушы ачык авызларга, сыерчык сары авызлы балаларына жим каптырган кеби, кыйммәтле мәгълүматны ташлый торды. Егерме өч үсмернең, ичмасам, бер-икесендә бу кыйммәтле орлыклар шытып чыгар, һәм бу егетләр, кызлар татар сәнгатенә хезмәт итәр, дип өметләнгәндер остазыбыз. Бу дәрес мең дәрескә тора иде».

Галимә Миләүшә Хәбетдинова соңгы вакытларда галимнең иҗатын, тор-







1913 елда кечкенә Нәкый чыгарган юмористик журнал –«Күсәк»нең тышлыгы. Анда ул мөхәррир дә, рәссам да, шагыйрь дә.



Эш өстәле янында.

«Минем әти – Сиражетдин. Шәҗәрәм: Әхмәт Нәкый – Сиражетдин – Мөхәммәт Закир – Әһлулла – Рәхим Кол – Мөхәммәт Рәхим – Исәнбәт. Безнең авылда Мөхәммәт Закир нәселе үз фамилияләрен Закировлар дип йөртәләр. Мин дә 1909–1910 нчы еллар, үземнең башлап язып чыгарган шигырь дәфтәрләремдә, исем фамилиямне – Нәкый Закири дип язып йөрткәнмен.

Бара торгач, миңа бу фамилиям ошамый башлады. Мин дә Габдулла Тукай кебек үземнең татарча фамилиям булуын кирәксенәм, бабаларым арасында шундый юкмы дип, әтидән сорашам. Ул минем җиденче бабама кадәр әнә шул шәҗәрәне язып бирә. Нәкъ җиденчесе – Исәнбәт. Бу – миңа ошый. Мин аның турында сорашам һәм үземнең шагыйрьлек фамилиям итеп тә, паспорт фамилиям итеп тә шушы сайлап алам. 1911–1912 нче еллардан бирле язмаларымда мин инде Нәкый Исәнбәт булып йөрим».
(Нәкый Исәнбәтнең «Бәби чак» повестеннан)

мыш юлын тирәнтен өйрәнә башлады. Моның сәбәбе – татар тарихында титаник хезмәтләре белән мәгълүм шәхеснең намусына тап төшерергә теләүчеләрне авызлыклау. «Күренекле галим берничә фәнни-тикшеренү институты хезмәткәрләре эшен берүзе башкарган «соңгы энциклопедист». Ул мөгаллим, методист, дәреслекләр төзүче». Нәкый Исәнбәтнең фәнни хезмәтен мактап, зурлап, 1971 елда Central Asiatic журналында мәкалә басылып чыккан. Әлеге мәкаләнең авторы – күренекле тюрколог, алтай телләре белгече, Вашингтон университеты профессоры Николай Поппе. Ул «Табышмаклар» китабына рецензия язганда аның зурлыгына сокланып кына калмый, ә галим Нәкый Исәнбәтне бердәнбер теория төзегән кеше дип атый. Шушы теория нигезендә башка халыклар да үзенең табышмакларын өйрәнсен, дигән фикерен җиткерә. Бу хакта беркем дә моңарчы белмәгән, чөнки Нәкый ага бу хакта беркемгә дә әйтмәгән. Ул беркайчан да дан артыннан кумаган. Әлеге бәяләмә Нәкый Исәнбәткә генә түгел, ул тулаем татар фольклористикасына зур бәя булган бит! Бай иҗат мирасы калдыру өчен, таланттан тыш, чын мәгънәсендә батыр һәм эш аты да булырга кирәк икән. Галим татар халкының мирасын барлап, чын мәгънәсендә татарларга һәйкәл салган. Исәнбәт – үзе бер дәүләт. Ул милли тәрбия мәсьәләләре турында уйланган һәм аның концепциясен эшләп калдырган», – ди галимә.

ИГЪТИБАР ҖИТМИ...

Нәкый Исәнбәтнең халык авыз иҗаты тупланган китаплары узган гасырда зур томлыклар булып дөнья күрде. Бүген китап кибете киштәләрендә балалар өчен иҗат иткән берничә әкиятен санамаганда, «халык академигы»ның әсәрләрен табам, димә. Һәр татар гаиләсендә булырга тиешле әлеге хезмәтләр бүген юк. Галимнең безгә таныш булмаган кызыклы хезмәтләре дә бардыр, алар да, тузан җыеп ятмыйча, милләтебезгә хезмәт итәргә тиеш.

Телгә нисбәтле хезмәтләре аерым игътибарга лаек. Текстолог буларак сүзнең тәмен, аһәңен тоеп иҗат иткән язучының балаларга атап язылган әкиятләре, фольклор үрнәкләре шулай ук бүгенге көн битарафлыгы шаукымында югалып калырга тиеш түгел. Илле мең берәмлекне үз эченә алган «Татар теленең фразеологик сүзлеге» исә тел белән эш итүченең өстәл китабы булсын иде.

«Татар-болгар мәдәнияте мең ел буена шәрык белән тыгыз мөнәсәбәттә булып, аның мәдәнияте йогынтысы астында да яшәп килде. Мәктәп-мәдрәсәләрдә уку гомуми һәм фарыз булганлыктан, телебездә дә күп кенә гарәби, төрки китаби әйтемнәр һәм махсус мәдрәсә фольклоры да барлыкка килгән. Боларның байтагы халыклашып, хәтта кайберләренең мәгънәсе беленмәсә дә, хәзер дә телдә актив кулланылышта. Мәсәлән, лаякыл исерек (гарәпчә «ләйәкыл» – гакылсыз булганчы, акылын җуйганчы), гуҗ тамак (гуҗ – мәшһүр, зур гәүдәле мифик кеше) һ.б. Бу гарәби яки иске төрки, китаби әйтемнәр элек бездә күп булса да, телебезнең әйтемнәр составы соңгы бер йөз ел эчендә нык кына үзгәреш һәм алмашынышка очрады, күпләре кулланудан төшеп калды. Шул рәвешле, моннан сиксән яки йөз ел элекке фразеология нык кимеде, пассивлашты. Алар урынына үз телебездән ясалды һәм рус яки европачыл әйтемнәр алынды. Мәгәр бу үзгәреш кинәт һәм кисәктән булганга, моннан 60–70 ел элекке классик әдәбиятыбызны укуда яшьләребезнең кыенлыкларга очравы күренде», – дип яза Н.Исәнбәт «Татар теленең фразеологик сүзлеге»н әзерләгәндә.

Хезмәтләрен Нәкый Исәнбәт гарәп имләсында язган. Кызы Йолдыз ханым белдергәнчә, Нәкый ага соңгы елларда гарәп имләсын танучы машинисткалар булмавына зарлана торган булган. Беренче хатыны Гөлсем апа, ә аның вафатыннан соң икенче җәмәгате Нәҗибә ханым әдипнең секретаре вазыйфасын да үтәгән. Заманында Г.Ибраһимов исемендәге институтка эшкә алуларын сорап баргач, аны «Махсус югары белемең юк», – дип кире боралар, ә инде күпмедер вакыттан соң, үзенә референт сорап килгәч тә, гозерен үтәмиләр... Кеше факторы дими ни әйтәсең?.. Эштән юаныч таба белгән титаник шәхес өчен бу түбәнлек, максатына баруда киртә була алмаган, әлбәттә.

«Нәкый Исәнбәт минем әни белән кушылганда мин егерме җиде яшьтә идем. Аның зыялылыгы әле дә күз алдымда. Әни аны бик карады, тәрбияләде, чөнки Нәкый абый астма авыруыннан интегә иде. Әни аны төрле шифаханәләргә йөртте. «Мин аның гомерен татар милләте хакына озайтырга тиеш!» – дигән сүзләре ул вакытта минем өчен бик пафослы яңгыраса да, әнинең аның идеаллары белән яшәгәнен хәзер аңлыйм. Нәкый абый яшьләрне ярата, аларның тормышы белән кызыксына иде. Мин әниләргә килгәндә, ул гел өстәл янында эшләп утыра, олы яшьтә булуына да карамастан, физик яктан нык булды, соңгы елларына кадәр йога белән шөгыльләнде. Якты дөньядан да ул бик тыныч кына китеп барды...»
(**Биллүр Низаметдинова**, галимнең икенче хатыны – Нәҗибә ханымның кызы)

Нәкый Исәнбәт якташлары – студент кызлар Зидә һәм Лена Гайнановалар белән. 1960 ел.

Нәкый Исәнбәт – классикларның классигы, дип еш телгә алына. Ул төрки әдәбият белән танышып барган, дөнья классикларының әсәрләрен татарчага күчергән. А.Пушкинның «Бакчасарай фонтаны», «Полтава» поэмаларын, «Таш кунак» трагедиясен, Мольерның «Тартюф»ын, Шекспирның «Гамлет»ы белән «Лир патша»сын, А.Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедиясен татар теленә тәрҗемә итә. Шекспирны тәрҗемә итү өчен ул хәтта инглиз телен махсус өйрәнгән икән.

«Нәкый Исәнбәт иҗаты турында бик күп язарга, сөйләргә мөмкин булыр иде. Казахларның бөек шагыйре Абай Кунанбаев иҗатын өйрәнү белән аерым бер фәнни-тикшеренү институты шөгыльләнә. Афәрин казахларга! Нәкый Исәнбәтнең иҗаты һәм гыйльми мирасы Абайныкына караганда күпкә артык. Әмма бездә бу олы шәхес иҗатына багышлап хәтта диссертацияләр язу да юк дәрәҗәсендә генә... Абайга Алма-Атыда мәһабәт һәйкәл куелган. Туган җирендә дә, башка шәһәрләрдә дә аны олылыйлар. Абай исемендәге урамнар, авыллар, шәһәрләр бар. Берничә музей эшли. Ә бездә әгәр моны Нәкый Исәнбәткә күчерсәк, боларның берсе дә юк. Шуннан соң без кем булабыз инде?!» – дип яза филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов.

Төрки халыклар арасында үз мәкальләрен, әйтем, табышмакларын җыеп тулы томлыклар әзерләп чы-

Малаязда Сабан туе. 1980 ел, 8 июнь. Уңнан икенче – Нәкый Исәнбәт, өченче – хатыны Нәҗибә.

Казан дәүләт университеты мөгаллимнәре коллективы. 1976 ел, 13 гыйнвар.

гарган башка бер милләт тә юк. Татар бу яктан беренче, диярргә мөмкин.

Фундаменталь фәнни хезмәтләр авторы, күпләргә иҗат юлы ачкан Нәкый Исәнбәткә тиешенчә игътибар күрсәтелә, дип әйтеп булмый. Гасырны гасыр белән тоташтырып, мирас күпере булдырган, гомер буе милләт өчен янган әдипкә юбилей елында булса да, ихтирам белдерергә кирәктер. Гомумтөрки «Идегәй» дастанын мөкәммәл шигъри формага китергән, халыкның үзенә һәйкәл салган әдипнең үзенә дә игътибар күрсәтер вакыт җиткәндер... Мәсәлән, кино, театр фестивальләре, фәнни конференцияләр үткәрергә. Хезмәтләре уңаеннан, аның үзе турында фәнни-популяр, әдәби әсәрләр язарга. Боларның барысын да, бәлкем, иң беренче чиратта үзебезнең йөз аклыгы өчен башкарыргадыр?..

Нәкый Исәнбәт 1992 елда ук инде бакыйлыкка күчте. Аның горур исемен йөртүче урам, башкалага нур өстәүче һәйкәл ник куелмый? Галимнәр раславынча, 30 томлык академик басмасын әзерләүгә тотынучылар нигә юк?..

Әлеге язманы әзерләгәндә галимнең варислары – кызы Йолдыз, оныгы Илдар Исәнбәтләр белән аралашырга туры килде. Иң куандырганы шул: алар туган телләре – татар телендә иркен сөйләшә. Димәк, Нәкый Исәнбәт галим яки олуг язучы, милләтнең чын улы булуыннан тыш, асыл ир, дәрәҗәле ата да була белгән! Үз үрнәгендә балаларын гына түгел, оныкларын да тәрбияли алган.

Г.Камал театрында атаклы драматургның байтак әсәрен куйган режиссер Марсель Сәлимҗановның «халык академигы»на карата әйткән сүзе иң гадел һәм төгәл бәя булыр кебек: «Аның исеме Кол Гали, Тукайлар исеме белән янәшә торырга тиеш. Ул – гасырга бер туа торган талант. Аның татар әдәбиятына керткән өлеше тиңдәшсез!»

P.S. Әлеге мәкаләбезне әзерләгәндә Нәкый Исәнбәтнең 120 еллыгына нәрсәләр эшләнүен белү максаты белән без ТР Мәдәният министрлыгына, ТР Язучылар берлегенә, Татарстан китап нәшриятына рәсми хат белән мөрәҗәгать иттек. Ни кызганыч, санызбызны типографиягә тапшыру вакытына кадәр алардан җаваплар ала алмадык.

Габдулла Шамуков,
СССРның халык артисты, язучы:

– Нәкый Исәнбәтнең драматург буларак осталыгы нәрсәдә соң? Беренчедән, ул тормышта һәркемгә таныш булган иң характерлы нәрсәне эләктереп алып, күз алдына ачык итеп китереп бастыра. Аның әсәрләрендә художество ягыннан формалашмаган идеяләр юк. Авторның әйтергә теләгән төп фикере, әсәрдә күрсәтелгән вакыйгалардан, характер бәрелешеннән үсеп чыга. Икенчедән, Исәнбәт яңадан-яңа психологик үзенчәлекле, индивидуальләштергән характерлар тудыра белә. Ул иҗат иткән образлар исемнәрен алмаштырып бер әсәрдән икенче әсәргә күчеп йөрмиләр, һәрбер образ үзенчә сөйли, үзенчә хәрәкәт итә. Һәм ул бер күргәннән соң онытыла торган төссез, тоныкбулмыйча, хәтердә озак саклана торган образ булып яши бирә. Н.Исәнбәт – таләпчән художник. Үз таләпләренә җавап бирерлек хәлгә килмичә, әсәрен беркемгә дә күрсәтми. Әсәр җентекләп эшләнгәч, төрле кешеләр тарафыннан әйтелгән төрле сүзләр аны чыгырыннан чыгара алмыйлар инде, һәм үзе дә Сергей Михалков мәсәлендәге «фил-художник» хәленә калмый. Әйтелгән киңәшләр арасыннан ярдәм итә торганнарын гына сайлап алып, әсәрен тагын да бер мәртәбә карап чыга, тагын да үстерә, көчәйтә.

Миркасыйм Госманов,
академик, язучы:

– Әңгәмәләр вакытында Нәкый ага үзен борчый торган мәсьәләләргә дә кагыла иде. Шундый темаларның берсе тарихыбызны Россия тарихындагы әһәмиятсез бер кушымтага әверелдереп, аны өстән-өстән генә яктыртуга карата ризасызлыктан гыйбарәт иде. Аңа бигрәк тә безнең тормыштагы һәрбер уңай күренешне, яңалыкны гел читләр йогынтысында барлыкка килгән дип аңлатырга тырышу ошамый иде: «Ә руслар тәэсирендә күпме уңай, затлы сыйфатларыбыз, яхшы гадәтләребез онытылды?.. Моның хакта ник бер сүз әйтмиләр?!» – дип гарьләнә иде. «Татар-монгол, татар-монгол», – дип чәйнәп, безне килмешәк итеп күрсәтергә тырышалар. Юк, без – 1552 елда руслар килгәнче дә шушында әллә ничә гасыр ике-өч дәүләт корып яшәгән, эшләп, тир түгеп, үз-үзебезне туендырган, хәтта ачлык елларында урысларга да ярдәм итеп гомер кичергән мөстәкыйль тарихлы халык!.. Шулкадәр боздык, пычраттык үз тарихыбызны... Әгәр дә Россия, руслар дигән бер тарихи арба булса, татарлар шул арбага тагылган дегет чиләге сыман сурәтләнә!»

Аяз Гыйләҗев,
Татарстанның халык язучысы:

– Нәкый ага, юлында нинди киртәләр очраса да, аларны Тукай кебек җимереп барды. Бер чакта да үзенең мәсләгенә хыянәт итмәде. Ул үзе утырткан эш агачына гел су сибеп торды һәм аның агачы төрләдән-төрле җимеш бирде. Нәкый ага безнең буынны тәрбияләде. Тиңдәшсез кыюлыгы, милләтне яратуы белән алдагы буыннарны да тәрбияләр.

PRESSA

ХИКМӘТЛЕ БӘРӘҢГЕ БӨККӘНЕ

Балан орлыгын киптереп он ясаганыгыз бармы? Ә тары ярмасыннан? Өлкән буын, әле ясамаса да, ишеткәне бардыр. Ә яшьләргә килгәндә, юктыр дип беләм. Һәрхәлдә, минем ишеткәнем дә юк иде... Шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе – Эльмира Шәрифуллина онытыла барган ризыклар турында сөйләде. Шагыйрәнең аш-су бүлмәсендә бәрәңге бөккәне пешердек.

«КАМЫРГА БАШ КАЛДЫРАМ»

Шигърият сөючеләргә Эльмира Шәрифуллина исеме яхшы таныш. Аның шигырьләре әдәп-әхлак, тирән мәгънә белән сугарылган.

Эльмира апа фатирында безне якты йөз белән каршы алды. Бирегә ике кызы, кияүләре һәм оныклары да еш була икән.

– Атнага бер мәртәбә булса да, камыр ашлары пешерәм. Ул көнне балаларны кунакка чакырмыйча калмыйм, – диде хуҗабикә.

– Күп хатын-кызлардан: «Олыгайган саен камыр ризыгын пешерәсе дә, ашыйсы да килми», – дип ишеткәнем бар. Сез менә һаман да әзерлисез икән, – дим.

– Камыр ризыгы пешерү – безнең милләтнең канында бит ул, сеңлем, – ди Эльмира апа, елмаеп. – Аны пешергәндә гаҗәеп бер рәхәтлек хисе кичерәм. Өйгә таралган хуш исе генә дә ни тора! Үзеннән-үзе әниле, әбекәйле балачагым күз алдыма килә. Бай яшәмәсәк тә, әни ризыкны гел төрләндереп хәстәрләде. Шул исәптән, камыр ризыкларын да. Андый көн өйдә бәйрәм була иде. Бүген мин дә, атнага бер булса да, балалар өчен бәйрәм ясарга тырышам...

Хуҗабикә без килгәнче камырны әзерләп куйган иде, чөнки бу күп вакытны ала икән. Камырны ул элеккечә «баш» калдырып ясый.

– Шактый еллар инде камырга чүпрә салмыйм, – диде шагыйрә. – Яшь барган саен сәламәтлеккә ныграк игътибар итәсең. Чүпрәсез дә камыр кабара, әле ничек кенә! Камыр пешергәндә, һәрвакыт бер йомарлам камыр алып калам. Кышын аны – балконда, җәен туңдыргычта (морозильникта) саклыйм. Безнең әбиәниләр дә шулай камыр «башы» алып калалар иде. Дөрес, ул чакта туңдыргычлар юк, әмма кар базлары бар иде.

Оеткы камырын кичтән җылы урынга алып куям. Иртән торгач, йөз грамм тирәсе су салып, аны сыеклыйм. Бер-ике сәгатькә шулай калдырам. Аннан соң, сөт, йомырка, каймак, кукуруз мае салып, камыр басам.

– Ә ни өчен кукуруз мае? Көнбагышныкы ярамыйммы? – дим.

– Ярый, әлбәттә. Тик хәзер камырга бары кукуруз мае салам. Киңәш итеп караганнар иде. Пешереп карадым һәм ошаттым. Камырны йомшаграк итә димме. Үзенә бер төрле хуш исе дә бар. Менә пешереп кара әле, бәлки син дә яратырсың...

Басылган камыр җылы урында өч сәгатьләп кабара икән. Күбекләнеп, сапсары булып тулышкан нәкъ шундый камыр безне көтә дә иде.

– Бәрәңгене турамыйча тордым, югыйсә каралып китә ул, – диде хуҗабикә. – Мин аның кабыгын әрчемичә пешерәм, күзләрен генә алам да.

– Сезнең якларда бәрәңге бөккәнен шулай пешерәләрме әллә? – дим.

– Төрлечә инде. Әниләр элек бәрәңгенең кабыгын әрчеп, укроп орлыгын салып әзерли иде. Әни аны бик еш пешерде, чөнки ул әтинең бик яраткан ризыгы булды. Ә хәзер мин бәрәңгенең

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНАДАН БӘРӘҢГЕ БӨККӘНЕ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак (уртача зурлыктагы 6 бөккән өчен):

1. Бәрәңге – 4 данә
2. Кабак – 200 г
3. Кориандр орлыгы – ярты бал кашыгы
4. Сыер мае – 70 г
5. Тоз – чама белән

Камыр өчен:

1. Оеткы – 200 г
2. Йомырка – 1 данә
3. Кукуруз мае – 100 г
4. Каймак – 1 аш кашыгы
5. Сөт – 150 г
6. Су – 150 г
7. Шикәр комы – чама белән

Фото: Лилиана Вәлитова

1. Түгәрәклибез!

2. Җаябез!

3. Турыйбыз!

4. Ваклыйбыз!

5. Кушабыз!

6. Өстибез!

7. Кисәкләп куябыз!

8. Салабыз!

9. Камырны бөрәбез!

10. Тезәбез!

11. Майлыйбыз!

12. Куябыз!

13. Кисәбез!

14. Майлыйбыз!

кабыгын әрчемим. Әлеге дә баягы, дөрес туклану белән дә бәйле – бәрәңгенең кабыгы бик файдалы бит. Аннары, камырга бәрәңге кабыгының бер тәмле тәме дә керә.

Эльмира апаның тагын бер яңалыгы – бәрәңге бөккәненә кабак турап сала. Шагыйрә монысына да иҗади якын килгән!

– Кабак бәлеше пешергәндә гел кориандр орлыгы салам, – диде хуҗабикә. – Кабакка бик килешә ул.

Шагыйрә ханым тиз генә бәрәңге, кабакны турады. (Куна тактасына куеп тормаса да, яшелчәләр бертигез зурлыкта булды). Тоз, кориандр орлыгын салып, барсын бергә болгатты. Санаулы минут эчендә эчлек әзер булды.

Ул да түгел, хуҗабикә электр мичен кабызды. Камырдан түгәрәкләр ясап җәйде. Аларның өстенә бер кисәк сыер мае куеп чыкты. Һәм эчлекне салды.

– Бөккәнне бик кечкенә итмим, – диде Эльмира апа. – Аннары мин нәрсә пешерсәм дә камырны һәрвакыт нечкә, эчлекне мул итеп салып ясыйм. Алай туклыклы да, тәмле дә була кебек.

Түгәрәкләрне озынча формада ясап, хуҗабикә аларны майлы табага тезде.

– Аз гына кабарсын да, мичкә куярбыз, – диде.

«ӘБЕКӘЙЛЕ БАЛАЧАК...»

Берничә тапкыр игътибар иттем: Эльмира апа сүз арасында гел әти-әнисен, әби-бабайларын телгә алды. Бер сүзе аеруча күңелдә калды – «әбекәй». Ике әби белән үскән бәхетле кыз ул.

– Кайта-кайта шуңа инанам, – диде Эльмира апа. – Нинди генә авыр заманда яшәсәк тә, безнең балачак әбекәйләр белән бәхетле булган. Алардан никадәр матур тәрбия алганбыз. Зурректыр дип инде, әни мине урманга үлән җыярга алып йөри иде. Җиде чакрым араны икәү сөйләшеп барабыз, сөйләшеп кайтабыз. Әни күп шигырьләрне яттан белә иде. Иң хикмәтлесе – урманда үскән һәр үләнне таный, аларның нәрсә өчен файдалы икәнен чамалый иде. Урманнан бәйләм итеп алып кайткан үләннәрне, өйгә кайткач, әбекәйгә тапшырабыз. Ул аларны җайлап чормага киптерергә менгереп куя. Аннан безне ел әйләнәсе шифалы үлән чәе белән сыйлый.

Шагыйрә бүген дә чәйгә төрле үләннәр салып эчә. Безне дә тәмле үлән чәе белән сыйлады.

– Безнең әби-бабайлар үзләре табиб та булган, – диде әңгәмәдәшем. – Кан басымын көйли, йөткергәндә булыша, җәрәхәтне төзәтә торган үлән – һәр авыруга үз дәвалау ысулы. Шуңа күрә алар хәзерге кешеләр кебек авырып интекмәгән дә...

Эльмира апада әбекәйләре белән бәйле истәлекләр шактый күп, шуларның бер-икесе аеруча кызык тоелды. Балан орлыгыннан, тары ярмасыннан он ясау турында инде әйтеп узган идем. Аны менә ничек ясаганнар:

– Ике әбекәй дә безнең белән гомер кичерде. Болай бергә яшәү, минемчә, әти-әнигә җиңеллек китергән. Беренчедән, балаларга күзколак булалар, икенчедән, аш-су ягын карарга өйдә һәрвакыт кеше бар. Әбекәйнең тагын бер тәмле гадәте бар иде – балан катыгы ясау. Башта баланны казанга салып пешерә дә, юкә иләккә салып сыга. Сыек масса катык була, ә иләктә калган төшләрне киптереп, шуны көйләдә төя. Авылда көйле бер бездә генә иде. Бөтен авыл кешесе, чират торып, он ясаганын хәтерлим. Хәзер дөрес туклану буенча журналлар күп бит. Менә шунда балан онын мактап, витаминнарга бик бай дип язалар. Һәм балан оны бик кыйммәт тора икән. Ә безнең әбекәй шуны моннан 70 ел элек үк ясый иде.

– Ә ул балан онын ничек ашый идегез? – дим.

– Балан бәлеше пешергәндә аны аскы өлешенә сибәләр. Ул эчлек камырны тишеп чыкмасын өчен әйбәт. Һәм, әлбәттә, файдалы.

Балан оны белән пирог пешерсәләр, тары ярмасын он итеп ваклап, тәбикмәк әзерләгәннәр.

– Аны әнкәй пешерә иде, – дип дәвам итте Эльмира апа. – Тары ярмасын башта төясең, аннан илисең, эре кисәкләрен тагын төясең... Кибетләрдә тары ярмасы оны сатыла, балачак хатирәсе итеп алганым бар. Ләкин авылдагыча тәбикмәк килеп чыкмады. Ни өчен дигәндә, төйгәндә, тары ярмасының эрерәк кисәкләре кала иде. Менә шул кисәкләр тәбикмәкне ашаганда авызда да кала. Аның тәмлелеге... Андый тәбикмәккә май күп кирәк. Әнкәй: «Тары майны күп эчә», – дип әйтә торган иде.

«КОРЫ ЭСКӘТЕРДӘ АШЫЙ АЛМЫЙМ»

Әнисе белән әбекәйләре турында гына түгел, әтисе, бабакае турында да Эльмира Шәрифуллина хәтерендә җылы истәлекләр саклана. Әлбәттә, һәркемнең күңел сандыгында андый рәхәт ха-

тирәләр бар. Ә шагыйрә аларны аеруча җылы, тәмле итеп сөйли белә:

– Әткәй белән әнкәй Актаныш районы Зөбәер авылында таныша. Әткәйне Зөбәергә мәктәп директоры итеп җибәрәләр. Ә үзе ул – Мөслимнеке. Әни дә яшь мөгаллимә була. Озакламый алар гаилә кора. Тик яшь парга бергә яшәү озак насыйп булмый – 1941 елның июлендә әтине сугышка алалар. Әнкәй авырлы булып кала. Ике арада сагыну тулы хатлар гына йөри. Нәни уллары туганын да әткәй хат аша гына белә. Аның иң зур теләге – исән-сау кайтып, улын күрү була. Алланың рәхмәте, әткәйнең хыялы тормышка аша. Сугышны башыннан азагына кадәр үтеп, исән-имин туган ягына әйләнеп кайта ул. Аннан соң аны Мөслим районының Симәк авылына мәктәп директоры итеп куялар. Мин шунда туган. Тик яшәү шартлары начар булганлыктан, кире Зөбәергә кайталар. Әнкәйнең әти-әнисе хәлле саналган. Баштарак алар янына сыеналар. Соңрак әткәйнең әнисен дә Зөбәергә алып киләләр. Әйткәнемчә, тату, бердәм булып яшәдек...

Язу сәләте Эльмира апага әти-әнисеннән күчкән. Өйдә китап, газета-журналлар уку, аерым әсәрләрне яттан сөйләү, язмаларны бер-береңә уку – болар барысы да гаиләдә гадәти хәл була.

– Әтинең мәкаләләре «Кызыл Татарстан» газетасында да чыккан, – диде әңгәмәдәшем. – Әткәй язып кына калмый, бик матур сөйли дә иде. Бик көчле агитатор булды. Аның тавышы матур, аһәңле иде. Хәер, әткәйдән әнкәй дә калышмады. Ул заманда бит укытучылар гел халык алдында чыгыш ясады. Әнкәй сәхнәдән яттан шигырьләр дә сөйли иде.

Әткәйнең сәламәтлеге нык булган. Алланың рәхмәте, тугыз дистәне тутырганчы яшәде ул. Соңгы елларны миндә торды.

Эльмира апа мичне ачып карады. Бөккәннәр инде кызарып килә. Ул да түгел, хуҗабикә чәй өстәле әзерләргә кереште. Эскәтер өстенә кәгазь салфеткалар куйды. Матур чынаякларын чыгарды.

– Коры эскәтердә ашый алмыйм, – диде шагыйрә ханым. – Кечкенәдән калган гадәт. Әнкәй, әбекәйләр шулай өйрәтте. Бабакай, картайгач та, колхозда каравыл торды. Без аңа чиратлап ашарга илтә идек. Әбекәй яки әнкәй кайнар ашны банкага тутырып ашъяулыкка төреп бирә дә: «Баргач, ризыкны как өстәлгә куймагыз, – дип кат-кат әйтә. – Өстәлгә шушы ашъяулыкны җәеп җибәрегез, бабагыз шуның өстендә ашасын». Амбар өе бик чиста булмый бит, эшчеләр бияләй, бишмәтләрен дә шунда куялар...

Кызык тормыш юлы узган Эльмира апа. Мәктәптә балалар да укыткан. Мәхәббәтен очратып (язучы Фаил

Шәфигуллин), ике кыз үстергән. Редакцияләрдә дә эшләгән. Бүген тыныч кына, рәхәт үз дөньясы белән яшәп ята.

– Ана телебез өчен борчылам, – диде шагыйрә. – Бигрәк тә соңгы бер-ике елда. Кайвакыт төннәрен дә уйланып ятам. Яшь вакытта күрмәгән әйберләрне, олыгайгач, башка төрле аңлый башлыйсың икән.

Аш бүлмәсенә тәмле камыр исе таралды. Хуҗабикә электр мичен барып ачты. «Яшь кызлар кебек кызарган» йөзле бөккәннәрне өстәлгә алып куйды.

– Кайнар көенчә урталай бүлеп, сары май белән майларга кирәк, – диде Эльмира апа. – Аннары инде табынга бирергә дә була.

Өстәл янына утырыштык. Иң беренче күзем кечкенә савыттагы балга төште. Балда кечкенә генә төшләр бар.

– Сездә бөтен ризык та хикмәтлеме әллә? – дим.

– Әй, төрлечә тәҗрибә ясап карыйм инде. Быел алма күп булды бит. Алма тураганда төшләрен җыеп бардым. Аннан юдым да киптердем. «Көн саен дүрт-биш алма орлыгы ашасаң, көнлек йод нормасы була», – диләр бит. Менә шулай үземә «йод нормасы» ясадым әле быел.

...Бәрәңге белән кабакны бергә ашаган юк иде әле. Авыз итәбез... Бу ризыкны нәрсә белән дә чагыштыра алмыйм. Кабыклы бәрәңге тәме дә бар, шул ук вакытта кабагы да сизелә. Миңа калса, бу «дуэтны» кориандр орлыгы шулай тәмле, үзенчәлекле иткән. Кыскасы, үзенчәлекле яңа, ят ризык әзерлисегез килсә, пешереп карагыз. Күңелегезгә хуш киләчәк дип уйлыйм.

ЭЛЬМИРА ШӘРИФУЛЛИНА

ТОРМЫШ ЯМЕ

Бисмилламны әйтеп, токмач кисәм,
Ак яулыгым ябып башыма.
Тел өстендә генә тотарлык ул,
Туганнарым килсен ашыма.

Билләремдә чиккән ак алъяпкыч,
Кош телләре кисәм, кыйгачлап.
Күпереп пешсен сары майда йөзеп,
Күзегез кызсын, үзегез туйгач та.

Бәлеш салам, белгәнемне укып,
Каз итеннән – кайнар, шулпалы.
Чөкердәшеп чәйләп утырыйк соң,
Күршеләрем дәшим, туктале.

Бер сөйләрлек булсын:
Аш-суының
Тел төбендә калды тәме, дип.
Кардәш-ыру,
Дус-иш белән яшәү –
Дөньябызның яме, гаме бит.

ИПИ ПЕШӘ

Кичке авыл мичләрендә,
Утын яна эчләрендә:
Дөрли генә яркалары,
Сикерә ут алкалары,
Очып-очып китә шартлап,
Бабам тора мичне мактап,
Сырхау әбием терелә,
Йөзкәеннән нур түгелә.
Кинәндереп һәр күңелне,
(Мәшәкате дә күңелле),
Бар кайнарлыкны сеңдереп,
Ипи пешә бөтерелеп.

«Көннәрдән бер көнне наркоман әфьюн куллануданн туктый. Кайберләре моңа исән чагында ук ирешә».

«Аноним Наркоманнар» берләшмәсе

ӨМЕТ УТЫН КАБЫЗ!

Минем кулымда – буклет. Аны миңа «Аноним Наркоманнар» төркеменең ачык җыелышында биргәннәр иде. Әлеге җыелышка теләгән һәркем килә ала. Укыйм: «Теләсә кайсы наркоман әфьюн куллануданн туктый, аны куллану теләген җуя һәм тормышында яңа юл таба ала». Үз көчләренә чамадан тыш ышаналар, дисезме? Һич юк. «Аноним Наркоманнар» берләшмәсенең бөтен дөнья буенча 60 еллык эш тәҗрибәсе моңа дәлил булып тора.

Автор:
Ольга Туманская

Мин соңгы рәттә утырам һәм залның әкренләп тулуын күзәтәм. Халык шактый күп. Бик яшь егет-кызлар да, бераз олыраклар да, инде шактый өлкән яшьтәгеләр дә күренә... Кемдер салкын урамнан атылып килеп керә дә, чишенеп тә тормастан танышлары кочагына ташлана; кемдер тыныч, уйчан кыяфәттә әкрен генә килеп керә дә, бүлмәгә аптырап күз ташлый. Менә барысы да җыелып бетә, алып баручы җыелышны башлый: «Без бу афәттән һәлак булучыларны, бәйлелектән берничек тә котыла алмаучыларны, безгә юл эзләүчеләрне искә алабыз...» Бер минут тынлык.

Аноним Наркоманнар – наркотикларның барлык төрләрен һәм исерткеч эчемлекләрне тулысынча инкарь итә торган берләшмә. Анда теләгән һәркем килә ала. Шарты бер генә – наркотик яки исерткеч куллануданн туктау теләге. Биредә тәҗрибә уртаклашалар, бер-берсенә куәт өстиләр, өмет уяталар.

Алып баручы сөйләргә теләүчеләргә сүз биргән саен, мин уңайсыз тынлык урнашуын көтеп тынсыз калам. Әмма берниндн пауза да юк. «Сәлам. Минем исемем Вадим, һәм мин наркотик кулланам», – биредә һәр чыгыш шулай башлана. Чөнки үзеңнең әлеге чиргә караганда көчсезрәк булуыңны тану – димәк, сихәтләнүгә таба тәүге адым ясау ул.

– Бүген бик үзенчәлекле көн һәм мин бу хәлләргә ышанып та бетмим әле, чынлап! – дип дәвам итә аксыл чәчле, күләргә яратучан Вадим. – Барысы да искиткеч шәп килеп чыга бит! Күп тапкырлар уңайсыз хәлдә калдырган кешеләр миңа инде кул селтәгән, сабырлары төкәнгән, дип то-

рам. Ә алар миңа ярдәм кулын сузарга әзер икән! Наркотиклар аркасында институттан куылдым бит мин, биредә очраткан кешеләр исә миңа укуымны кабат дәвам итәргә булышачак. Һәм тагын бер нәрсә... Минем башымда һәрвакыт ике мин бәхәсләшә. Берсе бәйлелектән котылмаска котырта, икенчесе исә сәламәтләнергә һәм нормаль тормышта яшәргә тели. Һәм, беләсезме, икенче перспектива бик шәп – хәзер мин моны аңлый башладым инде.

Менә сезгә беренче өмет тә: могҗиза була икән. Хәер, могҗиза түгел, закончалык бу.

БӘЙСЕЗЛӘР

– Бүген кемнең юбилее?– дип сорый алып баручы.

– Минеке! – дип кулын күтәрә ять-яшь бер кыз. – Туксан көн чиста.

Алкышлар. Биредә җыелучылар яхшы белә – бу кыз аларга бик лаек. Юбиляр өчен медаль җыелыш буена кулдан-кулга тапшырыла, ул «90 көн чиста» дип атала да. Биредә утыручы һәркем аңа уңай энергиясен «бирергә» тырыша. «Нык бул, кызыкай! Тормышыңда уңай үзгәрешләр генә булсын! – дип уйлыйм мин һәм бу пластик талисманны янәшәмдәге егеткә тапшырам...

Алар партияләргә керми, акцияләрдә катнашмый, беркем ягына да чыкмый һәм финанслау таләп итми. Алар – бәйсез. Әмма Аноним Наркоманнар омтылган иң мөһим нәрсә – наркотиклардан бәйсез булу.

Дөньяның 65 телендә атнасына 60 меңнән артыграк җыелыш – берләшмәнең статистикасы шундыйрак. Әмма мондый гаять зур система нинди принцип буенча эшли соң? Аны кем оештыра? «Аноним Наркоманнар» берләшмәсендә үзләре теләп һәм бушка аноним наркоманнар хезмәт итә. Алар белән исә... традицияләр идарә итә, биредә аларны катгый сакларга һәм беркайчан да бозмаска тырышалар.

– Хезмәт итү – безнең «12 адым» программасының бер өлеше ул, – ди Игорь. Ул үзе җәмгатьчелек белән бәйләнешләр өчен җаваплы ярдәмче оешмада хезмәт итә. Әмма хезмәт итү өчен теләк кенә җитми – берләшмә әгъзалары моңа үз ризалыгын бирергә тиеш. Биредәге үзоешма менә шундыйрак.

– Чынлыкта, безнең җыелышларга мөмкин кадәр күбрәк кеше «китертү» яки филиаллар булдыру бурычы юк, – дип аңлата ул. – Без эшкә урнаштыру яки социаль мәсьәләләр белән шөгыльләнмибез, квалификацияле психологик ярдәм күрсәтмибез һәм диагнозлар куймыйбыз. Без бары тик үзебез турында хәбәр таратабыз.

Үзләре хакында хәбәрне алар бөтен җиргә – наркодиспансер бүлекләренә дә, ябык төзәтү оешмаларына да – ягъни, әле һаман интегүчеләргә тарата. Күптән түгел Буага һәм Лаешка барганнар, анда әле берләшмәләр юк, шуңа үзләре турында табибларга сөйләгәннәр. АН кирәк, чөнки реабилитациядән соң наркоманнарның барыр җире булмаса, алар кабат әфьюн ятьмәсенә эләгә. Төркем ачар өчен инициативалы кеше булуы зарур. Һәм, кагыйдә буларак, ул табыла да. Гәрчә башта җыелышларда андый кеше... япа-ялгыз утыра.

– Шул рәвешле ел буе утырган бер аноним наркоманны беләм, – ди Игорь. – Ә күптән түгел инде икенче бер егет берләшмә төркеменә видео җибәрде. Мин әле тагын менә нәрсәне яхшы беләм – беренче кешегә һичшиксез башкалар да килеп кушылачак. Минем туган шәһәремдә нибары 100 мең кеше яши. Әле күптән түгел генә анда АН юк иде, хәзер исә җыелышлар атнасына дүрт тапкыр үтә, һәм катнашучылар артканнан-арта бара.

НИЧЕК ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНЕРГӘ

– Исәнмесез. Мин Руслан. Мин – наркоман, һәм мин көн саен елыйм. Менә хәзер җыелыш алдыннан да еладым әле. Мин үземнең бу хәлгә ничек төшүемне аңламыйм һәм аекларны кыралмыйм. Алар азапланмый. Сез һәм менә бу җыелышлар – минем өчен бердәнбер таяныч. Кабат куллана башламас өчен йөрим мин монда...

Тып-тын бүлмәдә бу сүзләр ишетелми диярлек. Әмма шыпырт кына әйтелсәләр дә, алар ачыргаланып кычкыру булып яңгырый. Әйе, биредә өмет туарга тиеш, әмма авыртуга түзеп булмаганда, ничек чыдарга соң? Асылда наркоманнар – бик ялгыз кешеләр. Нормаль – риясыз һәм игелекле – аралашуга кабаттан өйрәнү исә битәрләмәүче һәм акыл өйрәтмәүчеләр арасында җиңелрәк. Алар һәрвакыт янәшә һәм һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер. Әгәр син, түзә алмыйча, кабат тайгак юлга кереп китәсең икән, алар барыбер сиңа акыл өйрәтмәячәк. Биредә яхшы аңлыйлар: һәркемнең сихәтләнүгә үз юлы бар.

– Өйдә, институтта, эштә – мине һәр җирдә башка төрле булырга мәҗбүр итәләр иде, – ди миңа Игорь. – Берләшмәдә исә мине ничек бар, шулай кабул итәләр. Аек тормышның беренче этабында кешене һәр адымда курку сагалый. Эшкә урнашырга куркыта, кызлар белән танышырга куркыта... Шәхсән мин үзем

БЕРАЗ ТАРИХ

Берләшмә 1953 елда оеша. АН тәүге җыелышы АКШта үтә. Бүген Аноним Наркоманнар бөтен дөньяда диярлек – 137 илдә бар. Берләшмә Россиядә 1990 елдан бирле гамәлдә. Казанда АН беренче төркеме 1998 елның 2 мартында оеша. Тәүге җыелышка дүрт кеше килә, бер атнадан тагын бер кеше кушыла. Казандагы Аноним Наркоманнарның максаты да башка бөтен җирдәгечә үк – үз-үзеңә ярдәм итү төркемнәрен оештыру һәм теләсә кайсы наркоманның әфьюн кулланудан туктарга, аны куллану теләген җуярга һәм тормышында яңа юл табарга сәләтле булуына ышаныч уяту.

кая барып бәрелергә дә белмәдем! Җыелышларга йөри башладым, һәм бередә ишеткәннәрем миңа күп сорауларга җавап табарга булышты.

Менә Русланның соравына да җавап табылды. Миңа аны Наил биргән кебек тоелды. Бу озын буйлы, бераз бөкрерәк ир-ат үзенең илле ел гомереннең ун елын – героин коллыгында, аннан соңгы егерме елын чисталыкта үткәргән. Барлык шул «чиста» елларында ул төркемгә йөрүен дәвам итә. Атна саен булмаса да, аена бер һич килми калмый.

– 27 яшьлек улым минем белән сөйләшергә дә теләмәслек ниләр майтарганмын соң мин? – дип аптырый Наил. – Хатыным китте. Дусларым миңа: «Аларны аңларга була!» – ди. Чөнки мин, наркотик кулланганда, мәнсез булганмын. Икенче хатыным ВИЧтан үлде, без аның белән икәү кәефләнә идек. Бер бәйрәмдә аның башына бөтен салатларны каплаганым истә... Үкенәмме мин? Әйе. Әмма алга барырга кирәк. Иң мөһиме, хәзер мин сайлый алам: элеккечә мәнсез булыргамы, әллә инде кешечә яшәргәме. Мин икенчесен сайлыйм. Наркотиклар кулланган чагымда исә минем сайлау мөмкинлегем юк иде... Һәм тагын бер нәрсә. Кайчандыр минем дә бер генә максатым бар иде – бер генә көн булса да түзү. Көн саен җыелышка йөрдем һәм ничек тә кабат героин ятьмәсенә эләкмәү турында баш ваттым. Хәзер максатларым күп. Программа нәтиҗәсендә, беләсезме, нәрсәне аңладым? Менә күз алдына китерегез әле, сазлыкта өч бака аннан ничек тә сикереп чыгу турында хыялланып утыра. Чыгалармы? Юк. Чөнки хыялланалар гына. Бу гына аз, нәрсәдер эшләргә кирәк! Шунлыктан минем бүгенге тормышым – даими эш, хәрәкәт ул.

ДУСЛЫК ХИСЕ

– Мин инде бер, ике ай юынмадым... Иртән уянуга дуңгыз кебек идем – наркотик һәм аракыдан башка күземә бернәрсә дә күренмәде. Башта мин «иткә» (чөнки нормаль кан тамырларым инде унбиш еллап юк иде) наркотик кадыйм, аннары аракы эчәм – һәм барыбер исермим. Балконга төбәлеп уйга талам... Унөченче каттан сикерсәм, беркем дә ярдәм итә алмаячак, мин дә котылырмын, дип уйлаган чакларым күп булды... Үз-үземә кул салу омтылышлары булгалады да, тик ничектер исән калдым...

Санкт-Петербургтан Валентинаның (хәзер ул – химик бәйлелек буенча танылган белгеч) хатирәләре – теләсә кайсы триллердан да куркынычрак. Һәм шулай да, егерме еллык алкоголь-наркотик тәмугыннан соң – шулкадәр үк чиста тормыш. Хатыннар эчкечелеге, бигрәк тә наркоманлык та булса, җиңәрлек афәт түгел, диләр. «Тиле, синең кебекләр исән калмый, шунлыктан, телисеңме-теләмисеңме, син көн саен безнең җыелышка йөрергә тиеш», – дигәннәр аңа ул чакта Россиядә тәүге берләшмәләрнең берсен оештыручылар. Һәм ул биш ел буе көн саен йөри. Көн саен! Һәм могҗиза була!

Валентинаның әлеге илһамландыргыч тарихын күпләр белә. Төрле шәһәрләрдә ул «Аноним Наркоманнар» берләшмәсенең башка форматтагы җыелышлары – спикерлык ярдәмендә таныла: герой дөньяның теләсә кайсы ноктасында булырга мөмкин, трансляция исә скайп буенча бара. Аноним Наркоманнар шул рәвешле үз ватандашлары тәҗрибәсе белән генә түгел, башка илләр бергәлекләре вәкилләре белән дә таныша. Уртак бәла, сәяси чикләре дә, тел каршылыклары да булмаган уртак өметкә әйләнеп, кешеләрне берләштерә. Берләшмәнең иң беренче традициясе шуннан гыйбарәт: «Безнең уртак иминлегебез бар нәрсәдән дә мөһимрәк, һәркемнең сихәтләнүе АН бердәмлегенә бәйле».

– Элегрәк минем янәшәмдәгеләр кайсының күбрәк урлавы яки алдавы белән мактанышa иде, – дип сөйли миңа Игорь. – Хәзер исә мин җыелышларда егет-кызларның намуслы, ихлас чыгышларын тыңлыйм. Бу минем үземә дә кеше булып калырга ярдәм итә. Аноним Наркоманнар миңа үзгәрү мөмкинлеген бүләк итте.

АЛДА БАРУЧЫЛАР

– Бередә беренче утыз көне булган кеше бармы? – дип сорый алып баручы.

– Җиде көн чиста, – ди акрын гына икенче рәттә утырган егет.



Беренче утыз көн – иң авыры. Бу этапта кешегә аеруча таяныч кирәк.

– Гадәттә яңа кешеләр җыелышка барысын да инкарь итү халәтендә килә, – дип сөйли Игорь кебек үк җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр өчен җаваплы хезмәт итүче Светлана. – Аларның күпчелеге бу мизгелгә кадәр нәрсә генә эшләп карамаган инде! Кайберләре хәтта кодлаштыру да үткән, имче әбиләрдә дәваланган... Әмма барыбер наркотикларга кабат әйләнеп кайткан. Алар инде бернәрсәгә дә ышанмый. Әмма менә бередә алар наркотиклар гына түгел, исерткеч тә кулланмаучы кешеләрне күрәләр. Егерме елдан артык аек, чиста булу – яңа кешегә бу мөмкин түгел кебек тоела. Әмма кемнәндер хәленнән килгән бит!

Игорь да кайчандыр барысын да инкарь итүче булган. Дәваланганда, наркотик куллану теләге юкка чыгар, дип өметләнгән. Юкка чыкмаган. Хастаханәдән чыккач беренче уе: «Кайдан табарга инде?!» – булган. АН җыелышына бару коткарган. Залда кеше күп җыелган була, әмма Игорь шулкадәр тилмерә, түзми, торып баса да, үзенең ничек тә наркотик табу турында гына уйлавын сөйләп бирә. Тәнәфестә аның янына бер егет килә.

– Беләсезме, миңа бу хакта хәтта сөйләве дә уңайсыз, әмма миңа ул вакытта бу егет... бәхет сирпи кебек тоелды, – ди Игорь. – Һәм мин үземнең дә шундый була алуыма ышандым. Бер атнадан аңа шалтыратып, үземнең остазым булуын үтендем. Ул миңа үзенә чыннан да файдалы булган киңәшләрне бирде. Һәм минем тормышым үзгәрә башлады. Ә күптән түгел инде мин үзем яңа килүчегә телефонымны бирдем. Аңа сөйләшү бик мөһим.

Шылтырата: «Башка түзә алмыйм», – ди. Мин аны аңлыйм, чөнки беренче вакытта әлеге теләк акылдан шаштырырлык көчле. Ул әле хәзер дә, ничә ел аек яшәгәннән соң да, кайвакыт пәйда була. Мин моны кемгә сөйлим соң? Әти-әнигә түгел бит инде! Һәм менә икәү сөйләшәбез, мин белмим, кем кемгә күбрәк булышадыр әле, чөнки бу сөйләшүләрдән соң минем әллә кайдан гына көчем пәйда була, дөрес юлдан баруыма ышанычым арта.

Берләшмәдә остазларны, образлы һәм төгәл итеп, әйдәп баручылар» дип атыйлар. Алар – тормышын яңадан башлаучылар өчен юл күрсәтүче кебек. Биредә беләләр: ялгыз гына бару бик кыен. Остаз юнәлеш бирә, тәҗрибәсе белән уртаклаша. Дөрес яки ялгыш тәҗрибә юк – һәркемнең үзенеке. Шунлыктан син аны йә рәхмәт белән кабул итәсең, йә мондый тәҗрибәнең сиңа килешмәвен әйтеп, ярдәменнән баш тартасың. «12 адым» программасы белән яшәгән җиде ел эчендә Светлана биш остаз алмаштырган. Бүгенгесе аның чын дустына әйләнгән.

– Бу шулкадәр куәтле таяныч! – ди ул. – Яңа эшкә керергә җыенганда бик нык курыккан идем. «Бернәрсәдән дә курыкма! Барысы да яхшы булыр», – диде ул миңа шул чакта. Һәм мин уйлап куйдым: чыннан да, мин АН җәмәгатьчелек белән бәйләнешләр өчен җаваплы подкомитетта катнашам, берләшмәнең презентацияләрен даими үткәрәм, эш бирүче бер кеше алдында минем үземә-үзем презентация ясарлыгым гына юкмы әллә? Мондый мизгелләр бик файдалы.

Бу кешеләрне югалту – димәк, тагын ялгыз калу яки элекке әшнәләр белән элемтә яңарту, дип саный Светлана. Әлеге җыелышлар һәркем өчен бик кирәк. Шунлыктан ул эштән соң өенә кайтмый, биргә килә. Якыннары әлеге сәгать ярымның аның өчен никадәр әһәмиятле булуын яхшы аңлый. Башкаларга ярдәм итеп, ул үзенә дә файда эшли.

– Яңа кешегә булыша башлаганда, аңа никадәр авыр икәнен тоясың, үз тәҗрибәңне исеңә төшерәсең һәм әлеге халәткә бөтенләй кайтырга теләмәвеңне аңлыйсың, – ди Светлана. – Моны эшләүдән туктыйсың икән, үзеңнең дә башкалар кебек булуың турында иллюзия туа. Кайвакыт бераз кәефләнеп алган коллегаларыма карыйм да, күңел ачасы килеп китә. Әмма җыелышка килеп, бу хакта сөйләгәч, мине андый уйлардан тиз айныталар.

«Аноним Наркоманнар» берләшмәсендә тәүлек буе ярдәм итәргә әзерләр, чөнки кешенең, җыелыш вакытын көтеп җиткермичә, теләсә кайсы вакытта чыдамлыгы бетәргә мөмкин. Әгәр кинәт эч поша башлый икән, берләшмәнең чатына язу да җитә – хәтта төн уртасында да җавап бирүче табылачак.

– Беләсезме, «Ул булдырган – мин дә булдырачакмын» принцибы һәрчак үзенекен эшли, – ди Игорь. – Мин бик озак вакыт институтка керү турында карар кабул итә алмадым, гәрчә гаиләмдә бу хакта гел сүз булса да. Ә менә бервакыт төркемдә кырык яшендә югары уку йортына кергән һәм һөнәр алган кешене күрдем дә, аның хәленнән килгән икән, димәк, мин дә булдырачакмын, дип инандым!

ХАКЫЙКАТЬКӘ ТӨШЕНҮ

– Ходай Тәгаләгә ышаныргамы? Мин моны эшләдем,дип уйлый идем. Әмма кинәт аңлыйм – мине көн саен курку газаплый. Көчле курку. Сез хәзер көләчәксез, әмма мин Ходайны үпкәләтүдән куркам! Мин моның сәбәпләрен эзли башладым һәм шуны аңладым: сәбәбе – минем эгоистлыгым икән – мин Ходайны үпкәләтүдән шүрлим, чөнки ул минем теләкләремне үтәми башлар дип куркам. Менә нәрсәгә барып җиттем – Ходайны алдарга җыена башладым!

Виталийның бу сүзләре минем өчен ачыш булды. Аноним Наркоманнар җыелышына җыенганда, биредә мәхлукларны, мескеннәрне күрермен дип уйлаган идем. Башка күренешкә тап булып, гаҗәпкә калдым. Бүлмәдә төрле яшьтәге, төрле дәрәҗәдәге, төрле белемле кешеләр утыра, әмма аларның барысын да бер нәрсә – аңлау, төшенү, хакыйкатьнең асылына җитү теләге берләштерә.

– Беләсезме, бала чагымда мине алдадылар, – дип көтмәгәндә ачылып китә Илдар. – Миңа кәнфит бирделәр дә, «Иң мөһиме, синең бәхетле булуың», – диделәр. Һәм мин һәрдаим әлеге бәхет тойгысын эзләдем! Кәнфиттән, уенчыклардан, төрле матдәләрдән табарга тырыштым... Һәм менә әле күптән түгел генә, ниһаять, аңладым: миңа бит бәхетле булу мәҗбүри түгел! Ул хыялдагы бәхетне эзләргә кирәкми, бары тик яшәргә генә кирәк, чөнки тормыш һәрвакыт матур. Үземнең ачышымны кем белән булса да бүлешүемә мин шат. Рәхмәт сезгә – сез миндә ниндидер чын кыйммәтләргә ышаныч тудырасыз.

Менә бу яшәү мәгънәсен эзләүләр – үзеңне камилләштерү нәтиҗәсе. Аноним Наркоманнар ышана: «12 адым» аңны үзгәртергә сәләтле. Чыннан да, программа нигезендә намуслылык принциплары ята – башкалар алдында да, үз-үзең каршында да. Һәм тагын игелеклелек белән ярдәмчеллек принциплары да – болары инде наркотиклар кулланганда гына юкка чыккан, бер кеше дә әшәке булып тумый бит.

Аноним Наркоманнар программасының уникенче адымы – хезмәт итү. Күпләр аңа барып җитә һәм хезмәт итә, остаз булып, башкаларга булыша башлый. Хәлләре тагын начарая икән – кабат беренче адымны ясыйлар. Чөнки, «Бу юлдан барганда, без бернәрсәдән дә курыкмыйбыз», – ди алар.

Казандагы «Аноним Наркоманнар» берләшмәсе җыелышлары тәртибен **www.na-kzn.ru** сайтында табып була

Мәгълүмат линиясе телефоны
(843) 239-26-62 (10-00 дән 22-00 гә кадәр)

Материалда геройларының исемнәре үзгәртеп бирелде.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

ТАССРда **НИ ӨЧЕН** «торгынлык чорында» яшәүләрен сизмәгәннәр

«Татарстан» **КАЙЧАН** Халыклар дуслыгы орденына лаек булган

Фикрәт Табиевны **НИЧЕК** Әфганстанга илче итеп билгеләгәннәр

Тәтешлеләр 1978 елда **НИЧЕК** балаларны коткарганнар

Алла Пугачевага Казан туны **НИГӘ** ошамаган

ПОБЕДА! 1945–2020

Сугыш ветераннары... Әйе, алар көннән-көн сирәгәя. Шулай да бар әле, безнең бәхеткә, зур сөенечкә, дип тә өстәргә кирәк.

Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршыларга җыенганда, без аларны барларга, бер мәлгә булса да, ул елларны күз алдына китерергә тырыштык. Юк, бу өлкәннәр өчен генә түгел, бу, иң беренче чиратта, безнең үзебез өчен мөһим.

Алар кичергән фаҗигане ваемлау бүгенге тормышыбызның кадерен белү, шөкер итү өчен кирәк...

«ИСӘН КАЛУ – ЗУР БӘХЕТ!»

Автор: Руфия Фазылова

Әлки районы Түбән Әлки авылында яшәүче Хазим Фәхретдинов унтугыз яшендә аяксыз кала. Бу хакта ишеткәч:
– Кисәк кенә сәламәтлеген югалткан кешеләр: «Яшисем килми башлады», – дип әйтә. Сезнең дә шулай булмадымы? – дип сорадым. Хазим абый аптырап:
–Соң, исән калгач, ничек инде үләсең килсен! – диде...

«ПРОТЕЗ БЕЛӘН БУЛСА ДА ЙӨРЕРМЕН»

Хазим Фәхретдинов Әлки районының Түбән Әлки авылында яши. Өч ел элек кызы Кәрибә үзенә алып килгән. Бабай исә туксан ике яшенә кадәр туган нигезендә – Югары Әлкидә гомер иткән. Түбәтәйле, бик сөйкемле бу бабайны бер күрүдән якын иттек.

– Тормыш иптәшем үлде, – диде Кәрибә апа. – Әти дә ялгыз калды. Картаякартая өлкән кешегә тәрбия күбрәк кирәк бит, шуңа да хәзер бергә яшибез.

– Әй, аның Түбән Әлкие дә миңа үз авылым кебек. Колхоз ике авылга бер иде. Шуңа күрә Түбән Әлкине көненә әллә ничә әйләндем, – дип сүзгә кушылды Хазим ага.

Бабай янына килеп утырып, аның сугышта ниләр кичкәне белән кызыксынам. Тән ярасы төзәлсә дә, җан ярасы калгандыр, дип, Хазим абыйга сак кына сораулар бирәм. Ә ул, күрше авыл малайлары белән кызлар өчен сугышып кайткан диярсең, исе дә китмичә, сөйли дә сөйли...

– Армиягә мине 1942 елның август аенда алдылар. Башта җиде ай Суслонгерда булдык. Анда урман кистек. Нарат агачы ташып йөреп, җилкәләрчи иткә чыккан иде. Иң күп күргән михнәт шунда булды. Тәүлегенә бер ипи бирделәр. Аны өч кешегә бүлешеп ашадык. Иртә белән – беребезнекен, төш җиткәч – икенчебезнекен, кичкә – өченчебезнекен. Шулай иткәч, тамак туйган кебек була... Физик яктан көчсезрәк солдатлар үлеп бетеп барды. Ачлык, салкын, шуның өстенә бет. Бетне тәннән учлап кына алып ата идек.

Яшь солдат бу тәмугтан яз башында котыла. Аны фронтка – Украинага, Харьков янына алып китәләр.

– Мин пулеметчы идем, – диде Хазим бабай. – «Максим» пулеметын сөйрәп көненә ничә чакрымнар йөргәнмендер. Мондый хезмәткә көчле егетләрне генә сайлап алдылар. Аны бит йөртергә дә кирәк, сугыш коралының авырлыгы 4 пот та 400 грамм.

Хазим Фәхретдинов ике тапкыр яралана. Беренчесендә, кырда мина шартлап, иңбашы җәрәхәтләнә. Мина кыйпылчыклары әле шактый еллар тәнендә «яши». Икенчесендә исә... аяксыз кала.

– 1943 елның 15 августы иде ул. Кырдан шуышып барганда аяк минага тиеп китте, шуннан шартлау булды, – дип искә алды ул фаҗигане ветеран. – Бүтәнен хәтерләмим. Аңга килгәндә госпитальдә ята идем. «Аягыңны кистек», – диделәр. Карасам, аякның тездән аскы өлеше юк. «Ярар, баш исән булгач, протез белән булса да йөрермен», – дидем.

Тик унтугыз яшьлек солдатның уйлары рас килми: киселгән аякта гангрена башлана. Тугыз ай дәвамында әллә ничә тапкыр операция ясыйлар. Нәтиҗәдә, аягын төбеннән үк кисәләр.

– 1944 елның 4 апрелендә өйгә әйләнеп кайттым, – диде сугыш ветераны. – Иң шатланганым – аяк төзәлде. Син, сеңлем, бая үлем турында сорадың. Госпитальдә ятканда гангренадан күпме солдат җан бирде. Шуларга карап ятып, яшәүнең иң кыйммәтле нәрсә икәнен аңлыйсың. Иң мөһиме – йөрәк тибү...

САГЫНУНЫ БАСАР ӨЧЕН...

Фронттан кайткан яшь солдатны колхозга бригадир итеп билгелиләр. Авылның иң үткен малайларыннан саналган Хазимны тирә-якта барысы да белә. Егетнең аяксыз булуына җитәкчелекнең исе китми.

Фото: Лилиана Вәлитова

Хазим Фәхретдинов Әлки районының Түбән Әлки авылында яши. Өч ел элек кызы Кәрибә үзенә алып килгән.

– Ә мин аяклы кешеләрдән дә җитезрәк идем, – диде сугыш ветераны. – Махсус таякларым ярдәмендә ат арбасына җәлт кенә менәм дә утырам. Басу-кырларны көненә әллә ничә тапкыр урап кайта идем. Тегесен барларга, монысын китерергә, дигәндәй.

Эшкә чумган булса да, яшьлек үзенекен итә: егет кичләрен кызлар янына йөри. Фронтта булган вакыйгаларны сөйләп, яшьләрне көлдерә. Үзе күрше кызы Әсмабикәне күзли, янәсе болай гына, күз-колак була.

– Әсмабикәне мин бик кечкенәдән беләм, – дип, шул чакларны искә алды Хазим ага. – Ул миннән өч яшькә кече. Һич истән чыкмый: эти белән Әсмабикәләр йортына башак сорарга бардык. Өйдә ак чәчле, зур күзле бер кыз мүкәләп йөри. Курчак кебек матур кызга карап: «Әти, алып кайтыйк әле үзебезгә», – дидем. «Вакыты җиткәч, алып кайтырбыз», – диде эти. Тәки миңа насыйп булды бит!

Бу очракта да Хазим агага үткенлеге ярдәм итә. Ни өчен дигәндә, аздан гына яраткан кызыннан колак какмый кала ул.

– Әсмабикәнең әти-әнисе иртә үлде, – диде ветеран. – Ул аннары безнең күршегә – туганнары янына килде. Урамнан узган саен күзәтә идем үзен. Минем карашны тоеп, елмаеп куя. Берсендә шулай эштән кайттым, күршеләр тыз-быз килә.

– Әсмабикәне урлаганнар, – диләр.

Күрше урам егете икән. Тиз генә ат арбасына утырдым да киттем тегеләргә. «Тиз булыгыз, чыгарыгыз Әсмабикәне. Юкса, сез мине беләсез!» – дидем. Озак та тормады, елап беткән күрше кызым килеп чыкты. Кычкырмасын дип, авызына чүпрәк тыгып куйган булганнар. Шул атнада ук никах укыттык. 1947 ел иде ул.

Тик ир белән хатын ундүрт ел гына бергә яшәп кала. 1961 елны, җиденче баласын тапканда, Әсмабикәсе вафат була. Берсеннән-берсе кечкенә алты бала белән ир тол кала.

– Иң олы балага – унике, кечесенә ике яшь ярым иде, – ди Хазим ага. – Тормышта күпне күргән булсам да, хатынымны югалткач, бөтенләй аптырап калдым. Алга таба ничек яшәргә?..

Әлеге фаҗига авыл кешеләре өчен дә авыр хәл була. Бер аяксыз, алты балалы иргә күпләр ярдәм итәргә тели. «Сиңа өйләнергә кирәк, әнә фәлән авылда тол хатын бар», – дип киңәш бирә башлыйлар. Ир эндәшми. Шул авыр минутларында ул кулына гармун ала. Бер тапкыр да әлеге уен коралында уйнап карамаган Хазим санаулы көннәр эчендә гармунда уйнарга өйрәнә...

«ҮГИ ӘНИ КИЛГӘЧ...»

Хатынының ел ашына тол ир өйләнә. Дөресрәге, аларны димлиләр. Язмышмы, очраклы хәл буламы, яшь хатынны Әсмабикәсе яшәгән нигездән ала.

– Мөслимә, икенче хатынымның исеме шундый иде, – диде Хазим ага. – Әсмабикәнең туганнары йортларын саткач, әнисе белән Мөслимә килеп урнашты. Хатыным үлгәч, балаларга күз-колак булырга кереп йөрделәр. Мөслимәгә никах укытырга тәкъдим иткәч, каршы килмәде.

Бабайга икенче хатыны тагын дүрт бала бүләк итә. Үзләре әйтүенчә, тату, матур яшәгәннәр. Ни кызганыч, Мөслимә апа да биш ел элек вафат булган. Ун баланың да икесе бакыйлыкка күчкән инде.

– Безнең әни 104 яшькә кадәр яшәде, – дип сүзен дәвам итте ветеран. – Алла боерса, әни яшенә җитәм әле. Кайчакта балаларга: «Миңа бер әби табыгыз, үземә генә күңелсез», – дип тә әйтәм.

Янәшәдә безне тыңлап торган Кәрибә апага сүз катам:

– Әллә бабайның чынлап та өйләнәсе киләме?

– Шулай дип әйткәли. Әти бик актив кеше бит. Аңа болай өйдә утыру күңелсез. Кыш көне урамга да чыгып йөри алмый. Җәен исә электр коляскасына утырып, кибеткә бара, урамнарны урап кайта. Каршысына берәрсе очраса, тиз генә җибәрми, сөйләштерә. Элек тә шулай иде: колхозда эшләүчеләрне үз янына җыеп, халыкны җырлатты, биетте. Кырыкка җиткәч, гармунда уйнарга өйрәнде бит. Күрәсең, әнине нык сагынган.

Әниләре турында сүз чыккач, Кәрибә ападан сорап куйдым:

– Үги әни белән яшәү авыр булмадымы?

– Юк, булмады. Беренчедән, без алтау идек. Икенчедән, әти бик акыллы иде. Барыбызны да тигез күрде. Мөслимә әниебез бер-бер артлы балалар алып кайтты. Без шуларны карап, бергә уйнап, бер оя булып үстек. Үз әниемне бик яхшы хәтерләмим, ул үлгәндә миңа дүрт яшь кенә булган. Мөслимә әни соңгы унбиш елда авырды, урын өстендә булды. Туганнарымның барысы да кайтып-китеп йөрде. Әлбәттә, авылда торгач миңа күбрәк элəкте үзен карау.

Сигез туган бүген дә аралашып яши. Хазим бабай Түбән Әлкидә яшәгәч, хәзер бирегә кайталар икән. Оныклар, оныкчыклар – барысы бергә җыелгач, үзе әйтмешли, өйләрендә «Сабантуй хәтле кеше була». Тик Кәрибә апа моны күпсенеп түгел, киресенчә, сөенеп әйтә:

– Балалар кайта, дип, эти кибеттән сумка-сумка әйбер алдыра. Аның гел бер сүзе бар: «Кызым, иң беренче тамак ягын кара. Паласны ашап булмый ул». Хәтерлим, без кечкенә вакытта эти яңа пешкән ипи алып кайта да, аны сындырып, барыбызга да таратып чыга. Үзе безгә карап: «Ашагыз, аша, тамагыгыз тук булсын», – дип сөенә. Алар бит ипигә дә туймаган буын. Шуның өчен ризыкка аерым мөнәсәбәт аңарда – олы хөрмәт.

Хазим ага биш вакыт намазын калдырмый, эштән туктагач, мәчеттә муллалык эшен дә алып барган. Әле дә җомга намазларын калдырмаска тырыша икән.

Саубуллашканда, ветеран:

– Кызым, минем бер хыялым бар, шул турыда яз әле, – диде. – Хөкүмәтебез бер җиңел машина бүләк итмәсме икән. Сугышта катнашканым өчен генә түгел, алдынгы колхозчы да идем бит мин. Алтмыш җиде яшькә кадәр эшләдем. Җәйләрен болыннарга чыгасым килә. Кул астында машинам булса, туган авылыма да барып кайтыр идем... Т

«Екатерина II нең Казанга килүе» картинасы. Ильяс Фәйзуллин рәсеме.

ПАТШАБИКӘ ЕКАТЕРИНА II КАЗАНДА

Автор: Илшат Фәйзрахманов

Татарларда «Әби патша» исеме белән танылган патшабикә Екатерина II нең 1767 елгы Идел буйлап сәяхәте Петр I дән соңгы Россия тарихына бик истәлекле бер вакыйга буларак кереп калган.



ГЕОГРАФИЧЕСКОЕ
ОПИСАНІЕ РѢКИ ВОЛГИ
отъ
ТВЕРИ
до
ДМИТРЕВСКА
для путешествія
ЕЯ ИМПЕРАТОРСКАГО
ВЕЛИЧЕСТВА
по оной рѣкѣ.

При Императорской Академіи Наукъ.

ЮЛГА ӘЗЕРЛЕК

Кышларын патша сарайларында уздырып, зиннәттә яшәргә күнеккән патшабикә галиҗәнапларының Идел буйлап сәяхәтенә әзерлек 1766 елда башлана. Алдан уйланылганча, Екатерина II нең һәм аны озата баручыларның Мәскәүдән Тверьгә, аннары су юлы буйлап Углич – Ярославль – Кострома – Городец – Түбән Новгород – Чебоксар – Казан – Сембер маршруты буенча барып, коры юлдан кире Мәскәүгә әйләнеп кайтулары күздә тотыла. 1766 елда Тверь верфендә 25 ләп елга судносы төзелә башлый. Аларның дүртесе – «Волга», «Ярославль», «Казан» һәм «Тверь» – галералар. 1767 ел башына бу галералар төзелеп бетә. Патшабикә үзе белән 2 меңгә якын хезмәтчене, төрле дәрәҗәдәге офицер-солдатларны ала. Бу кадәр кешене алып барыр өчен 4 галера гына җитми, билгеле. «Углич», «Кострома», Түбән Новгород», «Сембер» кухня суднолары сәяхәтчеләрне азык-төлек, су белән тәэмин итә. «Ржев-Владимиров» госпиталь судносы күпсанлы юлчылар арасында килеп чыккан авыруларны дәвалау өчен тәгаенләнгән була. Шулай ук төп төркемдә граф Захарий Чернышёвның «Лама», граф Григорий Орловның «Севастьяновка» шәхси судноларыда бара. Алардан кала, башка кечерәк суднолар да күп була. Соңгыларында кубесенчә флот, артиллерия, адмиралтейство солдатлары һәм офицерлары йөзә. Граф Иван Чернышёв бөтен флотилия белән командалык итә.

МӘСКӘҮДӘН – КАЗАНГА

Патшабикә Екатерина II элегрәк тә сәяхәтләр оештырган (Ростов, Ярославль, Балтыйк буена), әмма Идел буйлап сәяхәт аның өчен зур вакыйгага әйләнә. 28 апрельдә Екатерина II күпсанлы ярдәмчеләре белән Мәскәүдән Тверьгә юлга кузгала. Елга буйлап сәяхәт иске календарь исәбе буенча 1767 елның 2 (13) маенда Тверьдә башланып, 5 (16) июньдә Сембер шәһәрендә тәгәлләнә. Тверьдән чыгып китеп, елга буендагы зур шәһәрләрдә берәр-икешәр көнлек тукталышлар белән баралар.

Екатерина II нең Казанга килүе, Петр I нең Казанда булуы кебек үк, май аена туры килә. Нәкъ 45 ел элек 1722 елның 27 маенда Петр I Казанга килеп төшсә, Екатерина II майның 26 сында кичен килеп җитә. Императрицаны туплардан салют атып сәламлиләр. Чиркәү чаңнары, литаврлар, торбалар тавышы астында флотилия Казансу елгасы буйлап үтеп кереп, Казан Кремле янындагы пристаньга килеп туктый. Казан губернаторы Андрей Никитич Квашнин-Самарин аны Чебоксарда ук каршылап, Казанга алып килә. Патшабикәне Казанда беренчеләрдән булып Оренбург губернасы губернаторы князь Абрам Артемьевич Путятин, шәһәр хуҗалары, офицерлар, дворяннар, сәүдәгәрләр каршы ала.

Патшабикәнең Түбән Новгородтагы ямьсез биналарны күреп кәефе кырылган була, ләкин Казан аңарда бөтенләй башка тәэсирләр калдыра. Екатерина II: «Шәһәр һәрьяклап зур патшалыкның башкаласы була ала», – дип язып та калдыра. Чыннан да, аны каршы алу өчен Казан алдан ук нык лап әзерләнә: йортларны як-тырталар, ике триумфаль капка төзелә. Императрицага очраганнар барысы да аны күреп шатлануын белдерә. «Моннан тиз генә китү мөмкин түгел, игътибарга лаек объектлар шулкадәр

«Тверь» галерасының агачка уеп ясалган бизәкләре.

күп, 10 ел буе яңа идеяләр тупларга була», – дип яза патшабикә. Аның үзен бик бай, зиннәтле сәүдәгәр йортына урнаштыралар. Губернатор йортында зур бәйрәм оештырыла. Гомумән алганда, патшабикәне Казанда биш көн кунак итәләр. Ул Казанда күп кенә кешеләрне кабул итә: чиновникларны, дворяннар, руханилар һәм сәүдәгәрләрне, Адмиралтейство офицерларын, гимназия укытучыларын. Шулай ук Татар бистәсендә яшәүчеләр белән очраша, аларның мәчет төзелешенә рөхсәт бирү турындагы гозерләрен кире какмый, җирле халык белән аңлашып эшләсеннәр өчен, дәүләт чиновникларының кайберләренә татар телен махсус өйрәтүне тәкъдим итә.

«ТВЕРЬ» ГАЛЕРАСЫ

Патшабикә сәяхәт иткән «Тверь» галерасы декоратив детальләре, матур бизәкләре белән аерылып торган. Галераның ян-яклары алтын йөгертеп эшләнелгән Нептун, тритон һәм башка мифик персонажларның фигуралары белән бизәлгән, арткы өлешендә император йорты гербы һәм императрица вензеле ясалган булган. Биредә капитан каютасы, патшабикә һәм аның яраннарының зиннәтләп эшләнгән каюталары урнашкан була, бигрәк тә Екатеринаның йокы бүлмәсе һәм аш бүлмәсенең бизәлеше матурлыгы белән аерылып тора. Судноның алгы өлешендә – ике рубка һәм ике якорь урнашкан, судно кыңгыравы да алгы өлештә декоратив аркага элеп куелган. Салют тупларын урнаштыру өчен урыннар ясалган. Палубадан түбәндә – трюмда ишкәк ишүчеләр һәм галера экипажы өчен урыннар билгеләнгән. 13 пар ишкәк галераны хәрәкәткә китергән. Җил уңае булганда галера ике мачтага күтәртелә торган җилкәннәр ярдәмендә йөзгән.

БОЛГАРДА ТУКТАЛЫШ

1 июньдә Казаннан чыгып китәләр. Патшабикә Петр I үрнәгендә Болгар шәһәрчегендә тукталап, биредәге хәрабәләрне карыйлар. Екатерина II, Болгарның җирле мөселман халкы өчен изге урын булуын ассызыклап, мондагы җимерекләрнең кайчандыр бик тә яхшы таш плитәләрдән салынган биналар булганлыгын әйтеп китә. Петр I нең Болгарны сакларга кирәклеге турындагы указларына да карамыйча, Казан архиерее Лука Конашевичның, чиркәү, монастырь, кладовой өчен дип, күп кенә борынгы биналарның ташларын алдыртуына, шуның нәтиҗәсендә корылмаларның тагын да ныграк җимерелүенә кәефе кырыла. Болгарда күргәннәре тәэсирендә Екатерина II «Болгарлар һәм халисләр турында» дигән язмаларын калдыра. Флотилия белән Сембер шәһәренә барып җиткәч, сәяхәтне дәвам итмичә, коры юл белән Мәскәүгә борылалар.

СӘЯХӘТТӘН АЛГАН ТӘЭСИРЛӘР

Гомумән алганда, патшабикә сәяхәттән шактый уңай тәэсирләр ала: «Бөтен Идел буендагы халык бик бай һәм тук, барысы да ипи ашый, берәү дә зарланмый, авырлык кичерми... Урман кырыйларында бар җирдә кыргый чияләр һәм розалар, ә урманнарда имән белән юкә үсә, җир каккара, андый җир башка урыннарда бакчаларда, түтәлләрдә дә юк. Бер сүз белән әйткәндә, бу кешеләр Алланың рәхмәтендә; мондагы кебек балыкны минем беркайда да ашаганым юк, барысы да хөр яши; мин белмим, мондагы кешеләргә нәрсә җитмәскә мөмкин, бар да бар».

Кышкы сарайда үткәргән озын-озак кышлардан соң патшабикәнең ил буйлап йөреп кайтуы, бер яктан чыгымлы булса, икенче яктан караганда, урыннардагы хәлләрне үз күзләре белән күреп ваемлау, һәрхәлдә, төрле канцелярия докладлары, губернатор отчетлары буенча фикер йөртеп кенә ил белән идарә итүгә караганда дөресрәк кебек тоела. Дөрес, Екатерина II гә матур фасадларны гына күрсәтергә тырышалар, әмма чынбарлыктагы күп кенә кимчелекләрне барыбер яшереп бетерә алмыйлар.

Екатерина II үзе сәяхәт иткән «Тверь» галерасын һәм тагын өч галераны Сембердән Казанга озата. Анда Адмиралтейство ихтыяҗларына кулланырга дигән махсус указ чыгара. Инде бераз соңрак, 1780 нче елларда, искерә башлаган бу галералар белән нишләргә дигән сүз чыккач, аларны ремонтлап, Казан адмиралтействосында махсус сарайларда саклауга куялар. 1804 елда, тузганлыкларын сәбәп итеп, өч галераны сүтәләр, Император Александр I указы нигезендә Екатерина II сәяхәт иткән «Тверь» галерасын гына сарайда мәңгелеккә саклар өчен калдыралар. Шулай ук монда Павел I нең көймәсе (ялик) саклана. Билгеле булганча, «Тверь» галерасы ялик белән бергә 1956 елгы янгында юкка чыга.

Патшаларга үтенеч (челобитная) калдыру төрле сословие вәкилләре өчен гадәти хәл саналган. Бигрәк тә шундый сәяхәт итеп кайткан вакытларда якынтирәдәге крестьяннар, шәһәр вәкилләре үзләренең гозерләрен патшаларга турыдан-туры җиткерергә тырышканнар. Екатерина II юлда йөргән вакытта барлыгы 600 дән артык шундый үтенеч кәгазен кабул итә. Аларның эчтәлеге илдәге түбән катламнар һәм идарә итүче катламнар арасында каршылыкларның көчәюе турында сөйли. Патшабикәнең күңелле тәэсирләргә бай сәяхәте Россиядә якын киләчәктә нинди дер тетрәнүләр, халык күтәрелешләре көтелмәс, дип уйларга нигез бирә. Әмма бу тынлык давыл алдыннан була торган тынлык кына була.



ИСКЕ РӘҖӘП: БӘЙСЕЗ ХАЛЫК...

Һәр районның атаклы авылы була. Андый җиргә барганда җиңел дә, кыен да. Ни өчен җиңел – данлыклы авыл турында газета-журналларда күп тапкырлар язылган була, димәк, кабатланмаска кирәк. Спас районының Иске Рәҗәп авылында «тапталмаган тема»ларны эзләдек.

Автор:
Руфия Фазылова

Авыл җирлеге башлыгы, безгә күрсәтү максатыннан, микрофон каршысына килеп игълан ясап алды.

«ХӘЕРЛЕ КӨН, ХӨРМӘТЛЕ АВЫЛДАШЛАР!»

Иске Рәҗәпкә килгәч тә, беренче эш итеп, авыл җирлеге идарәсенә юл тоттык. Ярты гасырдан артык бер тапкыр да ремонт күрмәгән әлеге бина, тыйнак кына әйткәндә, безне аптырашта калдырды. Шундый зур авылның үзәге мондый булырга тиеш түгел кебек. Безнең ни уйлаганыбыз йөзгә язылды, ахры, кул биреп күрешүгә, Иске Рәҗәп авылы җирлеге башлыгы Мансур Нугаев әйтеп куйды:

– Быел бу бинага капиталь ремонт ясалырга тиеш. Бу көнгә кадәр безгә чират җитмәде...

Буяулары кубып, тәрәзә рамнары каралып беткән бинада авыл китапханәсе дә урнашкан икән. Фельдшер-акушерлык пункты да биредә булган. Узган ел дәүләт программасы нигезендә, аерым ФАП эшләп куйганнар.

– Әгәр бу бинадан чыгып китсәк, ул ташландык хәлгә киләчәк. Монда иркен, рәхәт. Әле бит безнең авылның радио үзәге дә шушында, – дип дәвам итте җирлек башлыгы.

Иске Рәҗәпкә килгәнче үк, авылның үз радиосы барлыгын ишеттек. Бу турыда ныклабрак сораштык:

– Авылга радио элемтәсе совет чорында ук килгән, – диде Мансур Нугаев. – Ике ел элек авыл буенча барлык чыбыкларны яңага алыштырдык. Ни өчен дигәндә, чыбыклар бик искергән, ят тавышлар да керә иде.

– Ә нинди акчага алыштырдыгыз? – дим.

– Үзсалым акчасына. Без кеше башыннан 1 мең сум җыябыз, 5 мең сум булып кайта бит. Мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырмаска кирәк. Әлеге программа кысаларында соңгы елларда шактый эш эшләнде: юллар каралды,

Фото: Лилиана Вәлитова

башка бөтен кирәк-яраклар шул акчага кайтып кала.

Татар тотып карамыйча ышанмый бит, безгә радионың ничек эшләве кызык тоелды. Тәртибе болай икән: авыл радиосы тәүлек әйләнәсендә FM ешлыгында эшли, җирле халык «Болгар» радиосын тыңлый. Бары аерым көннәрдә, кирәк очракларда, ешлыкка «үзләренеке» кереп ала. Авыл җирлеге башлыгы, безгә күрсәтү максатыннан, микрофон каршысына килде дә: «Хөрмәтле авылдашлар, үзсалым акчасын җыю дәвам итә. Зинһар өчен, бу эшне озакка сузмыйк. Әле бирмәүчеләр шактый. Барыгызга да матур көннәр, сәламәтлек теләп калам», – дип, тиз генә игълан ясап алды.

Зур бәйрәмнәр уңаеннан, юбилярларны да шулай котлыйлар икән. Белдерү, игълан ясарга кирәк булганда да җитәкчеләр микрофон каршысына килә.

Авыл җирлеге идарәсе белән янәшә торган мәктәпкә дә кердек. Белем учагы зурлыгы белән әллә кайдан күзгә ташлана. Биредә илле бала укый. Урта мәктәп статусы әлегә сакланган. Игътибарны иң җәлеп иткәне – монда һәр нәрсә үз урынында. Каршыда – хоккей тартмасы, янда – ферма. Ферма дигәч, сорау туарга мөмкин. Баксаң, Иске Рәҗәп авылы мәктәбендә бүген дә хезмәт белән тәрбияләүне алга сөрәләр. Сарыклар, атлары бар. Берничә гектар җир дә – мәктәп карамагында. Яз башланугa, балалар җирдә казына. Дөрес, малларның аерым караучысы бар. Бер кызык факт турында ишеттек: совет чорында, чөгендернең бер гектарыннан 550 центнер югары уңыш алган өчен, мәктәпкә «Москвич» машинасы бүләк иткәннәр. Хәер, әле 2013–2014 уку елында да ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы аларга «МТЗ-82» тракторы биргән.

– Безнең мәктәп Спас районында татар телендә белем бирә торган бердәнбер мәктәп, – дип каршы алды безне директор Илнур Фәйзиев. – Мактанып әйтү булмасын, мәктәпнең абруе зур. Ул элек тә шулай булган. Безнең максат – шушы абруйны төшермәү.

«Иске Рәҗәп мәктәбе мине кеше итте», – дип сөйләде безгә Зиннәт Гыйззәтуллин.

«МИНЕ МӘКТӘП КЕШЕ ИТТЕ»

Мәктәптә авылның хөрмәтле кешесе – Зиннәт ага Гыйззәтуллин белән таныштык. 95 яшен тутырса да, һаман яраткан эш урынында ул. Тарих укытучысыннан музей җитәкчесенә әйләнгән. (Мәктәп эчендә бик бай экспонатлы, авыл тарихы музее бар. Аны ике ел элек яңартып, заманча итеп ясаганнар). Тормышының иң кадерле вакыйгалары да мәктәп белән бәйле икән. Ветеран укытучы алар турында бәйнә-бәйнә сөйләде:

– 1924 елның 7 ноябрендә Әлки районының Апак авылында туганмын. Әти берсеннән берсе кечкенә дүрт баласын калдырып үлеп китә. Аннан әни туган авылына – Иске Рәҗәпкә күченә. Бәхетсезлеккә, әни дә озак тормый – 1932 елны ул да дөнья куя. Апаны үз янында калдырып, без өч ир туганны бабай Димитровград шәһәренә балалар йортына җибәрә. (Иске Рәҗәп Ульяновск өлкәсенә терәлеп үк тора. – **Авт.**) Ни өчен дигәндә, ашарга юк, бабай карт, авыру була. Тик без анда озак яшәмәдек – авылга качып кайттык. Уку елы башлангач, безне Казанга – яңадан балалар йортына җибәрделәр. Әле дә истә – бөтен барлыгым белән чит җирдә, ят кешеләр арасында яшәргә теләмәдем.

Кыскасы, кечкенә Зиннәт теләгенә ирешә, ураy юллар аша Иске Рәҗәпкә кайта, бер туганнарында яши башлый. Бабасы инде үлгән була. Тамак туйдырыр өчен, ул көн саен иртән торып хәер сорашырга чыгып китә.

– Тамак ач булса да, укуга кызыксынуым зур иде, – дип дәвам итте Зиннәт ага. – Бу урында мин Иске Рәҗәп мәктәбе укытучылары турында әйтәсем килә: алар мине кеше итте. Ашату, эчертүдән башлап, өс-башка кадәр карадылар. Иске Рәҗәп урта мәктәбенә бөтен тирә-як татар авылларыннан килеп укыдылар. Тулай торагы да бар иде. Урта классларга күчкәч, мин дә шунда яшәдем. 1941 елның маенда җиде классны бары тик «5» билгеләренә генә

Мәктәп зурлыгы белән әллә кайдан күзгә ташлана.

«Яңа техникадан канәгать без», – ди Зыятдиновлар.

тәмамладым. Май аенда миңа мәктәп җитәкчелеге китапханә мөдире вазыйфасын тәкъдим итте. Сөенгәннәрем! Һич онытмыйм: йөз сум хезмәт хакы һәм ун кило он бирделәр...

Сугыш башлангач та, ятим бала китапханәче булып эшли, хезмәт хакы ала. Дөрес, унынчыны тәмамларга өлгерми, унсигез яшь тулгач, аны армиягә чакыралар.

– Уку елын тәмамламасак та, безгә аттестатларны приказ нигезендә бирделәр, – диде Зиннәт ага. – 1943 елның ноябрь азагы иде. Әле яшь, ныгымаганнар, дип, Ерак Көнчыгышка җибәрделәр. Хасан күле янына эләктек. Казармаларда түгел, казып ясалган кечкенә генә землянкаларда яшәдек.

Бишкә генә укыган малай биредә дә үзен яхшы яктан гына күрсәтә – берничә сугыш коралы белән идарә итәргә өйрәнә ул. Шул рәвешле абруй казана. Сугыш беткәч тә, яшь солдатларны өйрәтү белән шөгыльләнә. Хәрби хезмәтен тутырып кайтканда, капитан дәрәҗәсе бирәләр. Туган ягына әйләнеп кайткач, яшь капитан үзе өчен хәл итә – укытучы булачак. Читтән торып КДПИның тарих факультетына укырга керә. Һәм йөрәк кушуы буенча Иске Рәҗәбенә кайтып китә.

– Ул вакытта мине төрле җирләргә чакырдылар, – диде ветеран укытучы. – Әмма мин барысыннан да баш тарттым. Ни өчен дигәндә, әйткән сүзем бар иде: «Әгәр кеше булсам, шушы мәктәпкә кайтып, гади авыл балаларына белем бирер идем. Иске Рәҗәп мәктәбе мине кеше итте. Бурычымны кайтарачакмын...»

Зиннәт ага әнә шулай гомер буена «бурычын» кайтара.

ТРАКТОР ЯСАУНЫҢ НИЕ БАР?

Иске Рәҗәптә кечкенә трактор ясау «мода»да. Берсе артыннан берсе күреп, узышып ясый башлаганнар. Өч ай элек кенә «конвейердан төшкән» тракторны күрергә киттек. Аның хуҗасы, төгәлрәк әйтсәм, тудыручысы, инженер да, эретеп ябыштыручы да түгел, ә гади механизатор – Рафаэль Зыятдинов икән.

– Кул хезмәте кермәсен дип башлаган эшем иде, – диде хуҗа кеше. – Яз көне җир эшкәртермен дим. Җәй көне арбасы бар, печән ташырга әйбәт булыр...

– Хәзер авылларда күпләрнең мотоблоклары бар. Сез аны шуңа охшатып ясадыгызмы? – дим.

– Әйе, охшаган инде. Моторы да шундый ук көчәнешле. Тик мотоблокка караганда моның белән эшлисе җиңелрәк, җайлырак дип күрәм.

Әйткәнемчә, Рафаэль абый механизатор. Күп еллар дәвамында ул колхозда «К-700» тракторын йөрткән. Лаеклы ялга чыккач, үзенә әнә шундый «дус» тапкан.

– Мондый трактор ясау өчен күпме вакыт кирәк булды? – дим.

– Өч ай эчендә ясадым. Эретеп ябыштыру җайланмаларын күптән сатып алган идем. Хәзер бит кибеттә барысы да бар, болгарка, башкасы дисеңме. Тормыш иткәндә аларсыз булмый.

– Эшләтеп күрсәтегез әле, – дигәч, хуҗа кеше тракторы янына килде. Күз ачып йомганчы кабызды. Һәм егетләр җитезлеге белән техниканың утыргычына менеп утырды да кар эттерә башлады.

Трактор тавышына ишектән сөйкемле генә бер апа елмаеп чыкты: Рафаэль абыйның тормыш иптәше Рамилә апа икән. Ир белән хатын кырык дүрт ел бергә яшиләр. Өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Балалары башлы-күзле булган.

– Карт белән карчык инде хәзер, – диде хуҗабикә. – Агылый белән тагылый кебек, шулай бер-беребезнең артыннан калмыйбыз.

– Яңа техникадан канәгатьме сез? – дим.

– Әйе, әйбәт кенә эшләп торсын инде. Үзебез исән-сау булыйк. Картая-картая физик эш эшләү авырлаша бит.

– Бәясе күпмегә төште? – дим, хатынкызның акчаны санарга яратуын исәпкә алып...

– Моторын 15 меңгә сатып алды, тимер-томырларның да күбесе акчага алынган. Шул 30 мең сумнарга баскандыр.

«БЕЗ ФЕРМЕР ТҮГЕЛ»

Авыл җирлеге башлыгы авылның иң тырыш гаиләсенә алып керде. Гөлнара һәм Алмаз Гатауллиннар күп итеп мал-туар асрый. Хуҗалыкта баш саны егермедән дә ким булмый, ди. Атлар, сыерлар, үгезләр – барысы да бар.

– Бүгенге көндә савым сыерлары бишәү, – диде гаилә башлыгы. – Әле бозаулыйсы сөтлебикәләребез дә бар.

– Кем сава? – дим.

Хуҗа кеше, елмаеп, хатынына ишарәләде.

– Үзем савам һәм бер дә авырсынмыйм. Кышын кул белән, җәй көне аппарат белән савам, – диде Гөлнара ханым.

Бу урында шуны әйтим, ир белән хатын икесе дә рәсми рәвештә эшли: Гөлнара – балалар бакчасы мөдире, ә Алмаз җылылык үзәге операторы.

«Бездә берәү дә эшсез тормый», – диләр Гөлнара һәм Алмаз Гатауллиннар.

– Ничек барысына да өлгерәсез? – дим.

– Өлгерәбез. Әниебез белән яшибез. Өй эшләре күбрәк анарда. Малларны ир-егетләр карый. Әле кечкенә улыбыз да яныбызда, сигезенчедә укый. Иртән чыкмый инде, ә мәктәптән кайткач, ике сәгатьләп маллар янында була. Бездә берәү дә эшсез тормый.

Наилә Билалова белән Сәҗидә Вилданова – күршеләр. Көн саен шулай йөрергә чыгалар.

– Шулай, шулай, – дип сүзгә кушылды янәшәбездә торган авыл җирлеге башлыгы Мансур Нугаев. – Бик тырыш гаилә. Балалары үсеп, шәһәргә киткәндә, машина, фатирны алып бирәләр...

– Булышабыз инде, фатирның бер өлешен генә түләдек, – диде тыйнак кына хуҗа кеше. – Калганын үзләре булдыра.

– Ә ни өчен фермер булып теркәлмисез? Дәүләттән грантлар алыр идегез, – дим ир белән хатынга.

– Без инде каралты-кураларны яңарттык, ферма төзү өчен дип грант ала алмыйбыз, – диде Алмаз.

– Дөресен генә әйткәндә, аның җаваплылыгы да бар. Болай үзебезчә, тынычлап яшибез, – диде хуҗабикә. – Теләсәк, баш санын бишкә калдырабыз, теләсәк, арттырабыз.

– Бездә рәсми рәвештә теркәлгән фермерлар юк, – диде авыл җирлеге башлыгы. – Югыйсә мал тотучылар бик күп.

– Ник алай? – дип төпченәм.

– Теләмиләр. Бездә халык бәйсез булырга ярата...

Гатауллиннардан чыгып, үзәк урамга таба барганда, юлда ике әбине очраттык. Күз алдыгызга китерегез, таякка таянган ике әби бер-берсенә каршы килә. Очраштылар да, көлешә-көлешә, кул биреештеләр. Бу күренешкә битараф булып узып китә алмадык, туктадык. Гомер буе шушы авылда яшәгән Наилә Билалова белән Сәҗидә Вилданова икән. Берсе фермада, икенчесе фельдшер-акушерлык пунктында эшләгән. Күршеләр. Көн саен шулай очрашалар булып чыкты.

– Көн дә чыкмасаң, бөтенләй аяксыз каласың, кызым. Физзарядка булсын дип йөрибез, – диделәр. Әле елмаеп фотога да төштеләр.

...Кайтырга чыккач, уйлап бардым: ул әбиләрне күрү очраклы булмады шикелле. Тирәнрәк уйлап карасаң, бергә гомер иткән әлеге күршеләр кебек, биредә халык та бер-берсенә ярдәмләшеп яши. Тормышка юмор белән карый беләләр, урау юлларны җиңел генә узалар. Ә бу – иң кыйммәтлесе.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Иске Рәҗәп авылы – Чулман аръягында урнашкан иң борынгы татар авылларының берсе. Аның тирәсендә Болгар һәм Алтын Урда чорына караган берничә авыл урыны һәм шәһәрлек бар. Авыл эчендә – борынгы авыл урыны һәм зират. Зираттагы бер ташта Рәҗәп исеме укыла. Җирле халык авылның килеп чыгышын да Рәҗәп бабай исеме белән бәйли.

Тарихи чыганакларда Рәҗәп авылы башта Бәрән дип бирелә. Танылган эпиграфист һәм этнограф Һарун Йосыпов «Бәрән» атамасын Ибн Фадлан искә алган бәрәнҗәр кабиләләре белән бәйли. Ул Иске Рәҗәпне борынгы болгар кабиләләренең тәүге килеп урнашкан урыны булырга мөмкин, дип тә искәртеп үтә.

Документлардан күренгәнчә, 1675 елда Иске Рәҗәптә мәчет була. Аның даны бөтен тирә-якларга таралган.

Җәмил Мөхәммәтшин,
төбәк тарихын өйрәнүче.

Илдус Габдрахманов, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының игенчелек буенча урынбасары, март аенда 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Реклама

Мәҗит Салихов,
«ТР ДЭДИ» ДАУ башлыгы

Үз эшенең остасы

– Хөрмәтле Илдус Харисович!

Безнең учреждение хезмәткәрләре коллективы һәм үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Шушы истәлекле көнне Сезгә – үз эшенең остасына һәм югары әхлакый принципларга таянып яшәүче кешегә – чиксез соклануымны белдерәм. Республикада игенчелек үсешенә керткән өлешегез һәм бу өлкәдә ирешкән казанышларыгыз Сезгә танылу китерде. Сез язмышыгызны авыл хуҗалыгы белән бәйләгәнсез, гади колхозчыдан ТРның төп министрлыкларының берсендә җиткәче вазыйфасына кадәр юл үткәнсез. ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының игенчелек буенча урынбасары вазыйфасында Сез, кыр хезмәтчәннәренең киләчәге өчен җаваплылыкны үз өстегезгә алып, әлеге тармакта намус белән хезмәт куеп, яңа казанышларга һәм уңай нәтиҗәләргә ирештегез.

Татарстанның агросәнәгать комплексындагы уңышларда да Сезнең өлешегез зур. Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре һәм Россия Агросәнәгать комплексының Мактаулы хезмәткәре дигән исемнәрегез шуны раслый.

Хөрмәтле Илдус Харисович, иң ихлас котлауларымны һәм Татарстан авыл хуҗалыгын үстерү юлында уңышларыгыз тагын да күбрәк булсын дигән ихлас теләкләремне кабул итеп алыгыз! Һәрвакыт яхшы хәбәрләр генә килеп торсын! Сезгә һәм гаиләгезгә бәхет, күңел тынычлыгы һәм ныклы сәламәтлек телим!

Фото «ТР тезелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУнән алынды

Рөстәм Нуриев,
Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

Олы белгеч дигән исеме бар

– Хөрмәтле Илдус Харисович!

Юбилеегыз уңаеннан иң ихлас теләкләремне кабул итегез!

Төрле җаваплы вазыйфаларда узган бай хезмәт юлыгыз, туплаган олы тәҗрибәгез Сезгә югары һөнәри осталыкка ия белгеч дигән дан китерде. Сез үзегезгә ышанып тапшырылган һәр эшне бөтен белемегезне, көч-егәрегезне куеп башкарасыз.

Сезнең җаваплы җитәкче һәм тәҗрибәле оештыручы дигән абруйлы исемегез бар. Эшкә тугрылык һәм алга куелган бурычларны нәтиҗәле итеп үтәү өчен даими рәвештә эзләнүчәнлек – әлеге сыйфатлар нәтиҗәсендә Сезне хезмәттәшләрегез дә, җитәкчелек тә ихтирам итә.

Юбилеегыз көнне ихлас күңелдән ныклы сәламәтлек һәм вакыйгаларга бай тормышыгызда иминлек телим!

Эшегездә һәрвакыт уңышлар юлдаш булсын, ә гаилә учагы туганнарыгыз һәм якыннарыгыз җылысыннан балкып торсын!

Сезгә бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман, рух көрлеге телим, башкарган һәр эшегез алга таба да югары бәяләнсен!

Фото Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетыннан алынды

Вәгыйзь Минһаҗев,
ТР буенча «Россельхозцентр» ФДБ учреждениесе филиалы җитәкчесе

Талантлы җитәкче, чын һөнәр остасы

– Хөрмәтле Илдус Харисович!

Үзебезнең хезмәт коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Бүген Сезнең өчен истәлекле көн. Мондый көнне юбилярның казанышларын барлап, аңа мактау сүзләре әйтәләр. Ә алар Сездә бихисап. Талантлы җитәкче, чын һөнәр остасы, ышанычлы иптәш һәм сизгер күңелле дус – хезмәттәшләрегез һәм кул астында эшләүче хезмәткәрләрегез Сезне шундый итеп белә. Сез агросәнәгать комплексы белгечләре арасында югары квалификацияле һөнәр остасы абруена ия, моны ТРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре дигән исемегез дә дәлилли. Принципларга тугрылык максатчанлык кебек сыйфатларыгыз һәркемгә мәгълүм. Сез кыр хезмәтчәннәре өчен җаваплылыкны үз кулыгызга алып, тармакта намус белән эшләп, яңа казанышларга, күркәм нәтиҗәләргә ирешәсез. Аграр өлкәдә туплаган олы тәҗрибәгә, стратегик планлаштыру осталыгына, теоретик һәм практик белемнәргә өстәлгән оештыру сәләтегез Сезгә Татарстанда һәм аннан читтә абруй яуларга мөмкинлек бирде.

Сезнең белән озак еллар таныш булуыма шатмын һәм республика халкы иминлеге хакына бер командада эшләргә һәрвакыт әзер. ТР буенча «Россельхозцентр» Федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалы министрлык белән даими рәвештә эшлекле элемтәдә тора һәм тыгыз хезмәттәшлек итә. Без Сезгә хезмәтегез һәм безнең башлангычларга теләктәшлек итүегез өчен ихлас рәхмәтлебез.

Хөрмәтле Илдус Харисович! Юбилеегыз көнендә Сезгә җаваплы вазыйфагызда зур уңышлар телим! Бәхет, шатлык һәм ныклы сәламәтлек юлдаш булсын!

Фото «Россельхозцентр» ФДБ учреждениесеннән алынды

Николай Курчаткин,
«Авангард» ҖЧҖ нең генераль директоры

Һәр көне – туган республика иминлеге өчен

– Хөрмәтле Илдус Харисович!

Безнең предприятиенең бердәм коллективы хезмәткәрләре һәм үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм!

Сезгә республиканың авыл хуҗалыгын үстерү буенча алып барган эшчәнлегегез, кешелеклелегегез, фермерлар һәм агрофирма җитәкчеләре арасында яулаган абруегыз өчен олы хөрмәтемне белдерәсем килә. Сез туган республикагыз иминлеге хакына дистәләрчә еллар дәвамында көн саен армый-талмый хезмәт куясыз: Кукмара муниципаль районы хакимиятеннән Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы структурасына эшкә күчү, анда игенчелек юнәлешен җитәкләү. Аграр өлкәдә тупланган олы тәҗрибә, туган җиргә мәхәббәт, һөнәри осталык һәм хезмәт сөючәнлек кебек сыйфатларыгыз нәтиҗәсендә Сез авыл хуҗалыгы буенча еракка карап эш итә белән торган белгеч дигән абруй казандыгыз.

Сез агросәнәгать комплексы системасын камилләштерү, агрохуҗалыкларның матди-техник базасын модернизацияләү, уңыш алуның ысулларын яңарту буенча актив эш алып барасыз, игенчеләрнең һәм авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең эшен яхшырту өчен шартлар тудырасыз, чәчү һәм урып-җыю кампанияләре кысаларында Татарстан авыл хуҗалыгы предприятиеләренә олы ярдәм күрсәтәсез.

Хөрмәтле Илдус Харисович! Шушы истәлекле көнне Сезгә җаваплы вазыйфагызда зур уңышлар телим! Һәр көнегез нәтиҗәле узсын, ә ниятләрегез җиңеллек белән тормышка ашсын!

Бәхет, уңыш, гармония, иминлек һәм ныклы сәламәтлек Сезгә һәм якыннарыгызга!

Фото «Авангард» ҖЧҖ нең алынды

Рузилә Һадиуллина,
«Яшь көч» Агрофирмасы»
ЖЧҖ директоры

Тәҗрибәле һөнәр остасы һәм оештыручы

– Хөрмәтле Илдус Харисович!

Юбилей көнендә Сез озак еллар дәвамында авыл хуҗалыгы үсеше хакына куйган хезмәтегез һәм аны үстерүгә керткән өлешегез өчен бик күп рәхмәт сүзләре ишетерсез. «Яшь көч» агрофирмасы коллективы исеменнән дә котлауларыбызны һәм изге теләкләребезне кабул итеп алыгыз!

Шушы үтә дә әһәмиятле тармакта үз эшенә бирелеп, актуаль проблемаларны масштаблы рәвештә күрә белеп эшли торган кешеләр булуы шатландыра. Озак еллар дәвамында Сез авыл кешеләренең эш шартларын яхшырту өчен тырышасыз, авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең өметышанычлары белән урыннарда кызыксынып барасыз. Сез – үз һөнәренең тәҗрибәле остасы һәм яхшы оештыручы, үз вакытында колхоз белән дә җитәкчелек иткән кеше.

Мин авыл хуҗалыгында шактый күптәннән эшләгән кеше буларак, республиканың яңа тарихында бу өлкәнең ничек итеп үзгәрүен һәм камилләшүен күреп беләм. Без министрлыкның да, турыдан-туры Сезнең дә ярдәмне тоеп торабыз. Бу бик мөһим, чөнки авыл кешеләре заман куйган бурычларны ялгызы гына үтәп чыга алмый. Министрлыкның эшли белгән һәм эшләргә теләге булган, терлек асрап, кырларда яхшы уңыш алып яшәгән алдынгы хуҗалыкларга ярдәм күрсәтеп торуы да зур әһәмияткә ия. Сүз продукция җитештерү турында гына түгел, традицияләрне саклап, җиргә кайгыртучан һәм сакчыл мөнәсәбәт, җир кешеләренең абруе турында да бар.

Бик күп мәсьәләләрне хәл иткәндә, аңлавыгыз һәм ярдәм итүегез өчен рәхмәт. Сезгә эшегездә дә, гаиләгездә дә сәламәтлек, тынычлык, иминлек телим! Эшегездә ирешкән уңышларыгызга дусларыгызның теләктәшлеге дә өстәлеп торсын!

Фото «Яшь көч» Агрофирмасы» ЖЧҖнән алынды

Барис Гафуров,
«Цильна» ЖЧҖ директоры

Җаны-тәне белән агроном

– Хөрмәтле Илдус Харисович!

Безнең авыл хуҗалыгы предприятиесенең бердәм коллективы хезмәткәрләре һәм үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Шушы истәлекле көнне Сезгә Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы үсешенә зур өлеш керткән һәм муниципаль районнардагы игенчеләргә һәрвакыт ярдәм күрсәткәнегез өчен рәхмәт сүзләре җиткерәсе килә. Һөнәрегез буенча да, җан таләбе буенча да агроном Сез. Хезмәт юлыгызны туган Кукмара районы кырларында башлап, эш сөючән булуыгыз һәм кешелеклелек сыйфатларыгыз нәтиҗәсендә зур җитәкче дәрәҗәсенә ирешкәнсез.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының игенчелек буенча урынбасары вазыйфасында сез уңдырышлы авыл хуҗалыгы җирләрен нәтиҗәле файдалануны оештыру буенча үтә дә әһәмиятле эш башкарасыз. Сезнең дәүләт һәм халык алдындагы казанышларыгыз югары бәяләнгән: Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре һәм Россия Агросәнәгать комплексының мактаулы хезмәткәре.

Сезнең бай хезмәт тәҗрибәгез, югары һөнәри осталык һәм оештыру сәләтегез һәм олы йөрәкле булуыгыз күпләргә мәгълүм. Без Сезгә озак еллар дәвамындагы хезмәтегез һәм республиканың агросәнәгать хезмәткәрләре алдында торган проблемаларны тиз арада хәл итүегез өчен рәхмәтле. «Цильна», һәрвакытта да бердәм команда булып, уңышка йөз тотып эшли.

Хөрмәтле Илдус Харисович, Сезгә һөнәри эшчәнлегегездә зур уңышлар, уңай тәэссоратлар һәм ныклы сәламәтлек телибез!

Фото «Цильна» ЖЧҖнән алынды

Реклама

www.protatarstan.ru
РУС | ТАТ
Подписка!
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Монда «Татарстан» булды
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
КАМАЗ тарихы музее
Ил язмышын билгеләгән бөек төзелеш
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
20 февраля 2020
Район-шәһәрләргә Татарстан Республикасының иң югары дәүләт бүләге тапшырыла алачак
18 февраля 2020
Журналистика өлкәсендә «Бәллүр каләм» премиясенә гаризалар кабул ителә башлады
17 февраля 2020
Татарстанның алты балалар бакчасы ата-аналарга бушлай консультация үзәкләре оештырган
15 февраля 2020
мәңгелек
Бакый Урманче музее
Бакый Урманче: сыннарга җан өрүче
04.02.2020
«Туган җирдә үскән арыш ипиен бүтән ашамабыз дигән идек...»
Сугыш чоры балалары... Алар күргән нужа, газапны кәгазь битенә генә язып бетереп булмыйдыр. Шулай да...
03.02.2020
Түбән Майна: тарихлы халык
Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, диләр. Аксубай районының Түбән Майна авылына баргач, әлеге гыйбарәнең асылын тирәнрәк аңлый башладым. Күңелдә майналыларга карата ихтирам
29.01.2020
игелекле
Реклама 16+

100 СУМГА НӘРСӘ АЛЫРГА БУЛА?

...хәзерге вакытта:

- велосипед тәгәрмәче камерасы (таба алсагыз)
- яисә базарда 300 грамм сыер ите
- яисә 3 арыш ипие
- яисә 3 мәртәбә трамвайда йөреп килергә

РФ буенча уртача хезмәт хакы (2019 елның июль ае мәгълүматы)
46 509 сум

М. Горькийның татар халкына тәбрикнамәсе

«Татар республикасы халкына ихлас сәлам!

Хезмәтчел татар халкының рус эшче халкы белән татулыкта һәм бергәләшеп үз тормышын ирекле төзү хокукына ия булган заманга кадәр яши алуыма мин бик шат!

Яшәсен милләтләр бердәмлегенә комачаулап торган киртәләрне җимереп ташлаучылар!

Милләт – бер телдә сөйләшүче кешеләрнең табигый берлеге. Халыкны берләштерүнең әлеге формасы баштарак үзенә тиңдәш берлекләр өстеннән хакимлек итүгә омтылуны күздә тотмаган. XIX гасырга кадәр халыклар әшәке «милләтчелек» чире белән авырмаган – аларга ирексезләп «алманлаштыру», «руслаштыру», ягъни полякларны – немец, татарларны рус ясау омтылышы хас булмаган.

Милли санашмаучанлык XIX гасырга кадәр дә булган үзе, ул чакта аны Ходай Тәгаләгә салым түләүче мөселман һәм христианнарның санын арттырырга теләүче төрле дин әһелләре кузгаткан, әмма хезмәт халкының күпчелегенә милләтчелек ят күренеш булган. Чиркәү әһелләре бик аз санлы эшче һәм крестьянда гына башка дин, башка тел, башка көнкүреш кешеләренә карата дошманлык тудырган, тулаем алганда исә төрле диндәге һәм төрле телдәге хезмәт халкы бер-берсе белән бик тату яшәгән. Хезмәт халкы үзе кебек үк сәяси хокуксыз һәм изелгән башка халыкларга бернинди сәяси һәм мәдәни коллык теләмәгән.

Әлеге кешелексез, кабахәт, антимәдәни бурыч Европа һәм Россия капиталистларының бурычы булган, чөнки бу ерткыч һәм паразитлар өчен теләсә кайсы кеше бары тик физик көч, «арзан эшче кул» сыйфатында гына хаҗәт булган.

Октябрь революциясе һәм эшчеләр сыйныфының кешелек каршындагы иң бөек казанышларыннан берсе – һәр милләтнең үзбилгеләнүенә, милли үсеш ирегенә хокукын катгый тану. Эшчеләр сыйныфы хезмәт дөньясына алып килгән интернационал идеясе икътисадый һәм мәдәни тормышның яңа шартларын гына түгел, яңа кешелекне тудырачак.

Татарлар республикасы үзенең ун еллыгын бәйрәм итә. Иманым камил, тарихның хезмәт халкы энергиясе тудырган бу баласы баһадир булып үсеп җитәчәк.

Мин балачактан татар халкы турында белгән һәрнәрсә – аларның аек акыллы, чиста күңелле, хезмәт сөючән, максатка ирешүдә үҗәтлек белән күңел йомшаклыгын куша алучы халык икәнен белү миндә бу ышанычны арттыра гына. Татар республикасының мәдәни үсеше турында белгәннәрем минем ышанычымны янә бер мәртәбә ныгыта төшә.

Яшәсен мин яраткан татар халкының совет социалистик республикасы!

20/V - 30 г. Sorrento». **М. Горький.**

«Коммунист Татарии» № 3.

70 нче елларда Совет Татарстаны ни белән янып яшәгән? Бу вакытта нинди әһәмиятле вакыйгалар булган һәм нинди күренекле кешеләр гомер кичергән? Кайсы вакыйгалар турында бер тарих дәреслегендә дә мәгълүмат таба алмассың? Бу сорауларга «Татарстан» журналы җавап бирә. Тулырак мәгълүмат – 100.tatarstan.ru сайтында.

«А» ПУНКТЫННАН «К» ПУНКТЫНА БЕРЕНЧЕ ЭЛЕКТР ПОЕЗДЫ НИЧЕК СӘФӘР ЧЫКТЫ?

1972 елның 1 февралендә Казан вокзалыннан беренче электр поезды кузгала.

Озатучыларның һәм каршы алучыларның шатлыксөенеченә чик булмагандыр. Шаһитлар искә алганча, беренче электр поездының, бик ерак булмаса да, шулай да беренче сәфәренә хәерле юл теләргә бөтен Казан халкы чыга. Күпләрнең күзләре яшьләнә. «Җаваплы партия хезмәткәрләре» һәм ире белән бергә әлеге рейска эләгү бәхете тәтегән Әнисә Зәки кызы Заһидуллина истәлекләре буенча, соңгы станция булган Арчада электричканың беренче пассажирларын «сугыш геройларын каршылагандай» хөрмәтләп каршы алалар.

Бу шатлыклы вакыйганың репетициясе бер ай алдан башлана. 1 гыйнварда машинист Шәмиев яңа ЭР1-55 электр поездында Арча – Казан участогында так сандагы электрлаштырылган юлны тикшереп үтә. Ә кире юнәлештә, Казан – Арча участогында, ЭР1-58 электр поездында җөп сандагы электрлаштырылган юлны тикшереп чыгу эшен машинист Власов башкара.

Беренче электр поездының төп «пассажиры» Ленин портреты һәм аның пәйгамбәрләрчә алдан күрүчәнлек белән әйтелгән сүзләре була: «Коммунизм – ул Совет власте һәм бөтен илне электрлаштыру!»

ӘФГАНСТАН ИЛЧЕСЕ «ЯШЬЛӘР ҮЗӘГЕ» БАССЕЙНЫНДА АЗДАН ГЫНА БАТЫП ҮЛМИ КАЛА

Татарстан комсомолларының ирекле ярдәме белән төзелгән «Яшьләр үзәге» бинасы 1977 елның 31 гыйнварында тантаналы рәвештә ачыла һәм шуннан соң озак вакыт үтми, әлеге вакыйга була.

Шушы тантанадан соң, Декабристлар урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан бинада 80 нче еллардагы Казан яшьләренең төрле кызыксынуларга бәйле рәвештә бүленгән бик кызыклы тормышы башланып китә.

«Кино дуслары клубы» үз сафларына җиде меңгә якын кешене җыя. Казанлылар белән очрашуга илнең иң танылган актёрлары – Алла Демидова, Николай Караченцов, Илья Авербах, Андрей Тарковский, Владимир Высоцкий, Никита Михалков, Станислав Говорухин бик теләп килә. Яшьләр үзәгенең «Үзешчән җыр клубы»н СССРның иң танылган бардлары – Александр Розенбаум, Татьяна һәм Сергей Никитиннар, Юрий Визбор, Александр Городницкий, Владимир Высоцкий, Александр Дольский, Юлий Ким үз итә һәм клуб кичәләренә еш килеп йөри.

Һәр клубны үз президенты җитәкли: «Үзешчән җыр клубы»нда – Владимир Муравьёв, «Джаз-клуб»та – Игорь Зисер. «Кино дуслары клубы»н исә президентының фамилиясе белән – «Казанның Копосов клубы» дип атап йөртәләр. Роберт Копосов клуб абонементы системасын кертә, ул абонемент өчен республиканың иң яхшы комсомоллары үзара ярыша, хәтта аңа ия булыр өчен, дефицит товарлар да тәкъдим иткән очраклар була...

Комсомоллар Яшьләр үзәгендә рухи яктан үсү белән бергә, буш вакытларын да сәламәтлек өчен файдалы итеп уздыра – бассейнда йөзә, спорт секцияләрендә, теннис кортында шөгыльләнә...

Яшьләр үзәге кунакханәсе ул вакытта Казанда иң дәрәҗәлесе санала. Анда Идел буе зонасы Комсомол мәктәбендә укучылар, дипломатлар, артистлар һәм хәтта космонавтлар да яшәп ала.

– СССРда Әфганстан илчесен ничек кабул иткәннәрен әле дә хәтерлим, Хәбиб Мангал исемле иде ул, – дип искә ала Яшьләр үзәгенең элеккеге директоры Зөфәр Бохараев «Казанские истории» битләрендә. – ТАССР Министрлар Советы рәисе урынбасары Мансур Хәсәнович Хәсәнов, шылтырып, илче өчен сауна белән бассейн әзерләвемне сорады. Мунчада тирләп-пешеп чабынгач, илче бассейнда коенырга ниятләде. Бассейнның сай ягыннан керде ул, чупырдый башлады. Кинәт Мансур Хәсәнович: «Аңа нидер булган бугай!» – ди. Ни күрим, Мангал әфәнде тирән якка китеп барган, бата башлаган. Балконнан туп-туры суга сикереп, илчене тартып чыгарырга туры килде. Бактың исә, ул йөзә белми икән. «Син беркемгә дә әйтә күрмә инде!» – дип үтенде Хәсәнов.

ЭЛЕК «ИКЕЛЕ КАПЧЫКЛАРЫ»Н НИЧЕК АКЫЛГА УТЫРТКАННАР?

Узган гасырның 70 нче елларында, дөньяда әле «Гарри Поттер» булмаган вакытта, совет балаларының яраткан китаплары – «Вася Куролесов маҗаралары» (1971), «Ак төлке көчеге» («Недопесок») (1975) һәм «Урланган биш монах» (1977) дөнья күрә. Аларны искиткеч талантлы балалар язучысы – Юрий Коваль язган. Аның әсәрләрен сөючеләр «бәрәңге эте»нең ничек көлгәнен дә, Наполеон Өченче кушаматлы ак төлке көчегенең ник төньякка барырга омтылганын да, томанның йөрәге кайда икәнлеген дә, пеләш һәм мыеклы кешеләрдән ни өчен куркырга кирәклеген дә белә иде. Песиләр патшабикәсе «Шамайка»-ны һәм «Чик сакчылары эте Алый»ны СССРның бөтен бала-чагасы ярата. Совет заманындагы гадел һәм шаяртырга яраткан тикшерүчеләрнең тулы бер буыны үз һөнәрләрен балалар өчен язылган детективлар – «Вася Куролесов маҗаралары» һәм «Урланган биш монах» повесте тәэсирендә сайлаган.





Ә Ковальнең әдиплек эшчәнлеге Татарстанда, Лаеш районының Емельяново авылында башлана, анда Ленин исемендәге Мәскәү дәүләт педагогика институтын тәмамлаган яшь егетне юллама белән җибәрәләр. Емельяновода ул укытучылар җитешмәгән барлык фәннәрне укыта.

Иҗат итүгә омтылышы әүвәл диктантларга күчә – мөгаллим укучыларга аларны, аның үз сүзе белән әйткәндә, «хулиганнарча» шигъри формада яздыра:

На полу сидела мыШЬ.
Вдруг вбегает грозный муЖ
И, схватив огромный ноЖ,
К мыШИ он ползёт, как УЖ.

Мондый шигырьләр ярдәмендә Емельяново кызлары һәм малайлары рус телендәге «ж-ш»ларны язу кагыйдәсен «яхшы» һәм «бик яхшы» билгесенә үзләштерә. Емельяново мәктәбен оптимальләштерү җилләре сөреп екканчы, юк-юк дигәндә дә, укытуның «Коваль ысуллары»н куллангалый торган булалар.

Практикасын узгач, Юрий Иосифович Мәскәүгә кайта һәм Татарстан белән бәйле берничә хикәя яза. Үз әсәрләренең күп кенә геройларына ул Емельяноводагы исем-фамилияләрне бирә – Маня Клеткин, Коля Калинин…

– Гомумән, Мәскәү кешесе булса да, ул бик гади иде. Масаймады, кыланмады, – дип сөйли танылган хезмәттәше турында Анна Федоровна Семенова – Емельяновоның лаеклы ялдагы бер укытучысы. – 1961 елда пединституттан соң Юрий Ковальне безнең мәктәпкә билгелиләр һәм ризалаша. Үзебезнең казанныкылар да килә иде, тик аларга я монысы, я тегесе ошамый. Китәләр дә баралар. Ә ул китмәде,эшләде: рус теле дә, әдәбияты да, география дә, тарих та, җыр да укытты. Авыл мәктәбендә укытучылар беркайчан да җитми иде.

Коваль Емельяново мәктәбендә нибары бер ел гына эшләсә дә, җирле халык аны үзләренең гап-гади авылдашы кебек искә ала. Салага еш кына язучының туганнары, «Коваль дәвамчылары» җәмгыяте вәкилләре килә, аның китапларын алып киләләр, балаларга тараталар, җирле медпунктта «Коваль укулары» да оештыралар.

Емельяновоның инде күптән өлкәнәйгән «укучылары» Коваль вакытында мәктәп директорының да нинди булганын хәтерләмидер, әмма Юрий Иосифович «Ак төлке көчеге» повестенда мәктәп директорын ничегрәк тасвирласа, нәкъ менә шундый булгандыр дип күзаллыйлар:

«Директорга бигрәк тә «икеле капчыклары» күп мәшәкать тудырды. Өченче тәнәфестә директор үз кабинетында шул «икеле капчыклары» өчен чын җыелыш уздырды.

«Икеле капчыклары» китап шкафы янына тезелеп бастылар. Беренче минутта директор алар каршында йөргәләп кенә торды.

Акбурга буялып беткән «икеле капчыклары», аптырап, кая барып бәрелергә белмәгән кыяфәттә торалар, бу килешкилбәтләре белән алар штукатур-малярларны хәтерләтте.

– Ә сез, күгәрченкәйләрем, мәктәбебезне кайчанга кадәр шулай оятка калдырырга җыенасыз? Сез, мөгаен, мине ихахай-михахай килеп утырыр дип уйлыйсыздыр? Ялгышасыз! Мин сездән чын кешеләр ясаячакмын! Менә шушында, шушы кабинетта, сез моннан соң «яхшы» һәм «канәгатьләнерлек» билгеләренә укырга вәгъдә бирәчәксез.

...Ул сүзнең туры мәгънәсендә аларның күңелләрен сукалап, акыл-белем орлыклары чәчте. «Икеле капчыклары» казлар кебек муеннарын сузып торды, директорның сүзләреннән соң аларның колак очларына, чәч бөртекләренә кадәр кызарды. «Икеле капчыклары»на элекке вакытта алар кебек ялкау укучыларны нишләтүләре турында хикәят аеруча көчле тәэсир итте. Кайбер «икеле капчыклары» үкси-үкси елады.

Малай-шалайны туйганчы ачуланып, директор һәркемнең арт сабагын аерым-аерым укытты һәм шуннан соң гына сыйныфларга таралышырга рөхсәт бирде…»

БУЫННАР

Бик тиздән Татарстан Республикасы төзелүгә 100 ел тулачак. Түгәрәк һәм мөһим юбилей – гасыр гына түгел, тулы бер тарихи дәвер! Шул ук 2020 елда 100 еллыгын билгеләп үтәчәк «Татарстан» журналы уртак юбилей хөрмәтенә «Буыннар» проектын эшли. Без анда Татарстаныбыз тарихында эз калдырган шәхесләр, вакыйгалар, күренешләр турында сөйлибез. Бүген без 70 нче еллар буынын – күп кенә күркәм эшләр һәм күрсәткечләр буенча илдә беренче булганнарны искә төшерербез. Бу саныбыз – беренче миллиард тонна Татарстан нефтен табучылар, Түбән Камада беренче шиннарны һәм Яр Чаллыда беренче «КАМАЗ» авыр йөк машиналарын чыгаручылар, беренче Казан электричкасын юлга озатучылар һәм Түбән Кама ГЭСының беренче гидроагрегатын эшләтеп җибәрүчеләр, «Майский» теплица комбинатында беренче кыяр-помидор уңышын җыеп алучылар һәм беренче Ми-14 вертолёт-амфибиясен җитештерүчеләр – торгынлыкны сизмәгән дә «торгынлык» буыны турында...

Фото ТР Милли музееннан алынды

«Татарстан» журналының махсус проекты

1970 нче еллар

ТОРГЫНЛЫКНЫ СИЗМӘГӘН «ТОРГЫНЛЫК» БУЫНЫ

70 нче елларда совет Татариясе ничек яшәгән? ТАССР башкаласында кунакханәләрне һәм җәяүлеләр өчен җир асты кичүләрен кем төзегән? Татар язучылары эшчеләр сыйныфы турында илдә иң яхшы әсәрләрен ничек язган? Ми-14 вертолет-амфибияләре кайда җыелган?

1НЧЕ ТАРИХ
70 НЧЕ ЕЛЛАР БУЫНЫНА СӘЛАМ СҮЗЕ
Максим Горький татарларны ни өчен яраткан

2 НЧЕ ТАРИХ
ЕМЕЛЬЯНОВО АВЫЛЫ УКЫТУЧЫСЫ
Юрий Коваль кайчан Татариядә укытучы булып эшләгән

3 НЧЕ ТАРИХ
ХЕЗМӘТ ХАЛКЫНА КОММУНИСТИК ТӘРБИЯ БИРҮ
«Татарстан коммунисты» нәрсә өчен Халыклар дуслыгы орденына лаек булган

4 НЧЕ ТАРИХ
70 НЧЕ ЕЛЛАРДА ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЛӘР
92 нче бензин күпме торган

5 НЧЕ ТАРИХ
ЗУР ЭШЛӘР ӨЧЕН КЕЧКЕНӘ ЖУРНАЛ
«Агитатор блокноты» кемнәр өчен басылган

6 НЧЫ ТАРИХ
ХӘРБИ ЧОР ИЛЧЕСЕ
Фикрәт Табиев җиде ел Әфганстанда ничек хезмәт иткән

7 НЧЕ ТАРИХ
1978 ЕЛГЫ САЛКЫННАР
Тәтешлеләр Казахстаннан килгән чаңгычыларны ничек коткарган

8 НЧЕ ТАРИХ
70 НЧЕ ЕЛЛАР АФИШАСЫ
Алла Пугачевага Казан туныннан ни өчен баш тарткан

ХРОНОГРАФ

1970 нче еллар

Әлмәттән Яр Чаллыга автозавод төзелешенә килгән комсомол-яшьләр төзүчеләр бригадасы. 1970 ел.

Фото ТР Милли музееннан алынды

1970

- Татарстанда нефть табу күләме бер елга 100 миллион тоннага җитте. Бу нефть табуның илдәге иң югары күрсәткече була.
- Шагыйрь Сибгат Хәкимгә В. И. Ленин турындагы шигырьләре һәм поэмалары өчен РСФСР Дәүләт премиясе тапшырылды
- Казанда «Татарстан» кунакханәсе ачылды
- Куйбышев мәйданында башкаладагы беренче җир асты кичүе барлыкка килде
- Казан киностудиясе «Татария. Год 1970-й» дигән беренче киң форматлы документаль фильм төшерде

1971

- Татарстанда нефтьнең беренче миллиард тоннасы табылды
- Казанда ТЭЦ-3 нең беренче чираты сафка бастырылды. Станцияне СССРның Европа өлешендәге бердәм энергосистемасына ялгадылар

1972

- Казан тимер юл вокзалыннан беренче электр поезды юлга чыкты

1973

- Түбән Кама Шин заводы беренче продукциясен чыгарды
- Казан вертолёт заводында Ми-14 вертолёт-амфибияләрен җыя башладылар

1974

- Яшел Үзән районының «Майский» теплица комбинатында помидор һәм кыярларның беренче уңышы җыелды

1975

- Татарстанда нефть табуның максималь дәрәҗәсенә ирешелде: аның күләме 103,7 миллион тоннага җитте

1976

- КАМАЗның төп конвейерыннан беренче авыр йөк автомобиле төште

1977

- Татарстан башкаласында Яшьләр үзәге ачылды
- Сара Садыйковага ТАССРның халык артисткасы исеме бирелде

1978

- КДУның фәнни-тикшеренү химия институты директоры Борис Арбузовка һәм СССР ФА әгъза-корреспонденты, СССР ФАның Казан филиалы – Органик һәм физик химия институты директоры Аркадий Пудовикка «Фән һәм техника өлкәсендә Ленин премиясе» тапшырылды

1979

- Казанда миллионынчы кеше туды
- «Казан-2» аэропорты – Халыкара «Казан» аэропорты ачылды
- Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен куючылар – пьеса авторы Туфан Миңнуллинга, баш рольне башкарган Шәүкәт Биктимеровка, режиссёр Марсель Сәлимҗановка театр сәнгате өлкәсендә К. Станиславский исемендәге РСФСР премиясе тапшырылды
- «Вечерняя Казань» газетасының беренче саны чыкты
- Казан дәүләт университеты Ленин ордены белән бүләкләнде
- Түбән Кама ГЭСының беренче гидроагрегаты сафка бастырылды, сусаклагычның тирәнлеге 62 метрга җитте. Чулман һәм аның кушылдыклары, Иж елгасы үзәнлекләрендә 78 мең гектар мәйдандагы җирләр су астында калды. Сусаклагыч өчен Татарстан (91,4 мең гектар), Башкортостан, Удмуртия, Пермь өлкәсе территорияләреннән 173 мең гектар җир алынды

«ТАТАРСТАН»* ЖУРНАЛЫ НӘРСӘ ӨЧЕН ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ ОРДЕНЫНА ЛАЕК БУЛГАН?

«Марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалауга керткән өлеше, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү, аларны хуҗалык һәм мәдәни төзелеш бурычларын үтәүгә оештыру буенча алып барган эше өчен».

* 1977 елда «Татарстан» журналы «Татарстан коммунисты» дип аталган.



Подлежит опубликованию в "Ведомостях", газетах "Правда", "Известия" и местной печати

PSRS AUGSTĀKĀS PADOMES PREZIDIJA DEKRĒTS
СССР ЖОГОРКУ СОВЕТИНИН ПРЕЗИДИУМУНУН УКАЗЫ
УКАЗИ ПРЕЗИДИУМИ СОВЕТИ ОЛИИ СССР
СССР ЕКАРЫ СОВЕТИНИҢ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ
NSV LIIDU ÜLEMNÕUKOGU PRESIIDIUMI SEADLUS
…TARYBOS PREZIDIUMO ĮSAKAS

УКАЗ
ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР

О награждении журнала "Коммунист Татарии" ("Татарстан коммунисты") орденом Дружбы народов

За заслуги в пропаганде марксизма-ленинизма, плодотворную работу по коммунистическому воспитанию трудящихся, мобилизации их на выполнение задач хозяйственного и культурного строительства наградить ЖУРНАЛ "КОММУНИСТ ТАТАРИИ" ("ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ") орденом ДРУЖБЫ НАРОДОВ.

Председатель Президиума Верховного Совета СССР (Л.Брежнев)

Секретарь Президиума Верховного Совета СССР (М.Георгадзе)

Москва, Кремль.
3 августа 1977 г.
№ 6096-IX.



Оформить 3 августа 1977 г.

РЕЗУЛЬТАТЫ ГОЛОСОВАНИЯ
ПРОЕКТА УКАЗА ПРЕЗИДИУМА ВЕРХОВНОГО СОВЕТА СССР

О награждении журнала "Коммунист Татарии" ("Татарстан коммунисты") орденом Дружбы народов

Голосование проведено I-2.VIII- 1977 г.

…в М. А.	болен	Гиталов А. В.	–
…енко А. Ф.	за	Гришин В. В.	в отпуске
…ков И. Е.	Полянов	Злобин Н. А.	–
…анов Н. М.	за	Конотоп В. И.	за
…еков С. Б.	в командировке	Кунаев Д. А.	за
…вили П. Г.	за	Машеров П. М.	за
…ов К. А.	за	Николаева-Терешкова В. В.	в отпуске
…кскас А. С.	за	Новоселова Н. А.	–
…енко К. Ф.	в отпуске	Пухова З. П.	–
…манис П. Я.	за	Рашидов Ш. Р.	за
…атов Т.	за	Романов Г. В.	в отпуске
…ов М.	за	Смирнов Г. Н.	–
…ев А.	в отпуске	Табеев Ф. А.	в отпуске
…ер А. П.	в командировке	Тынель Л. Г.	–
…оболевский И. И.	–	Цецегов С. С.	за
…атов Р. Г.	–	Шакиров М. З.	за
		Щербицкий В. В.	в отпуске

Зав. Протокольно-контрольным сектором

Зак. 2165.

Фото: Ната Смирнова

ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ ЙОРТЫНЫҢ БАРЛЫК ДИАСПОРАЛАРЫ ДА «ТАТАРСТАН» БЕЛӘН ДУС

Ирек Шәрипов, Халыклар дуслыгы йорты директоры:

– Халыклар дуслыгы ордены – үтә дә мөһим бүләк. Ул СССРның 50 еллыгын билгеләп үткән 1972 елда – социалистик милләтләр һәм халыклар арасындагы дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгытудагы казанышлар, ССР Союзының һәм союздаш республикаларның икътисадый, социаль-сәяси һәм мәдәни үсешенә керткән өлеше өчен бүләкләү максатында булдырыла.

Мин тарихтан беләм: аның белән дуслыкны ныгытуга өлеш керткән кешеләр генә түгел, оешмалар да бүләкләнгән. Мәсәлән, 1978 елда Ленинград циркы, шулай ук СССР халык биюләре ансамбле, Мәскәүнең «Ромэн» чегән театры… Димитровград, Ялта, Киев шәһәрләре… Хәтта массакүләм мәгълүмат чаралары да. Мәсәлән, «Литературная газета», «Вокруг света» журналы, «Пионерская правда» газетасы шушы орден белән бүләкләнгән. Әмма болар барысы да федераль матбугат чаралары. Ә инде безнең үз журналыбыз «Татарстан»ның да 1977 елда шушы бүләккә – Халыклар дуслыгы орденына лаек булуын белү минем өчен аеруча күңелле булды.

Ул чакта мин бу журналның укучысы түгел идем әле, аның исеме дә башка – «Татарстан коммунисты» булган. Хәзер «Татарстан»ны мин генә түгел, Халыклар дуслыгы йортындагы диаспораның барлык вәкилләре – руслар да, татарлар да, грузиннар да, үзбәкләр дә, ингушлар да, украиннар да, кореецлар да… укый. 37 диаспора, 37 тел, 37 дуслар берлеге! Кем әйтмешли, чын дуслык өчен киртәләр юк – тел дә, территорияләр дә, милләт төрлелеге дә дуслыкка комачауламый.

70 НЧЕ ЕЛЛАР ВИТРИНАСЫ: НӘРСӘГӘ НИНДИ БӘЯ

АЗЫК-ТӨЛЕК

- Шикәр комы, 1 нче сорт, кг
  78 тиен
- Сыер мае (талонга), кг
  3 сум 20 тиен
- Үлчәп сатыла торган сөт, л
  24 тиен
- Ит (базарда), кг
  5 сум
- Ит (кибеттә) талонга,
  1 сум 90 тиен
- Тоз, кг
  7 тиен
- «Янтарь» йомшак сыры
  48 тиен
- «Новый» йомшак сырогы
  14 тиен
- Кара карлыган, кг
  2 сум–2 сум 50 тиен (җәйге чорда, базарда)
- «Подмосковный» күмәче
  16 тиен
- «Орловский» икмәге
  16 тиен
- Пирожное (кайнатып пешерелгән)
  22 тиен
- Ресторанда комплекслы төшке аш
  1 сум
- Мәктәп ашханәсендә бәрәңгеле сумса
  4 тиен
- «Пломбир» туңдырмасы
  19 тиен
- «Экстра» аракысы, 0,5 л
  4 сум 12 тиен
- «Сибирская» аракысы, 45 градуслы
  4 сум 42 тиен
- Җирле җиләк-җимеш шәрабы (Түбән Ослан)
  1 сум 02 тиен
- Балык консервасы «Томат соусындагы фрикаделькалар»
  48 тиен
- Үлчәп сатыла торган квас, 0,5 л
  6 тиен
- Лимонад яки спиртлы эчемлек шешәсе (тапшырып була)
  12 тиен

ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЛӘР

- Мунча (гомуми бүлек)
  16 тиен
- Киногa билет
  25-50 тиен
- Трамвай билеты
  3 тиен
- Троллейбус билеты
  5 тиен
- Мәскәүгә самолет билеты
  19 сум
- Казаннан Грузиягә, Әрмәнстанга туристик путевка, 15 көн (ташламалы, бәянең 70 процентын профсоюз түли)
  38 сум
- «Жигули» автомобиле (сатуда юк)
  5620 сум
- «Урал» велосипеды
  49 сум
- Ирләрнең чәчен алдыру
  20 тиен
- Бензин А-72, л
  70 тиен
- Бензин АИ-92, л
  95 тиен
- Дәүләт акча-әйбер лотерея билеты
  30 тиен
- «Весна-305» кассеталы магнитофоны
  195 сум
- «Рубин-205 Д» телевизоры, диагональ 61 см
  415 сум

70 НЧЕ ЕЛЛАР УРТАСЫНДА ИЛДӘГЕ УРТАЧА ХЕЗМӘТ ХАКЫ *149 сумны* ТӘШКИЛ ИТКӘН

СТУДЕНТЛАРНЫҢ СТИПЕНДИЯСЕ (ӨСТӘМӘЛӘРДӘН ТЫШ) – *40 сум*



Яшьләр үзәге рестораны,Казан ш.

Фото ТР Милли музееннан алынды

ЗУР ЭШЛӘР ӨЧЕН
КЕЧКЕНӘ ЖУРНАЛ

«Агитатор блокноты» дигән кечкенә генә массакүләм мәгълүмат чарасының чәчәк атуы һәм, димәк, иң зур тиражы 70 нче елларга туры килде. ТАССРда аның рус һәм татар телләрендә басыла торган гомуми тиражы 33 500 дән 50 000 экземплярга кадәр тәшкил итте.

ММЧнең бу төре совет заманында төрле «соуслар» белән чыга – «Полевой блокнот агитатора», «Блокнот агитатора Красной армии», «Блокнот агитатора Вооружённых сил»… Кечкенә генә брошюра айга ике тапкыр сугышка кадәр дә, сугыш вакытында да, сугыштан соң да, узган гасырның 90 нчы елларына кадәр даими чыгып торган.

«Блокнот агитатора» КПССның Омск, Пенза, Куйбышев, Ленинград өлкә комитетлары, Украина, Белоруссия, Үзбәкстан КП ҮК һәм СССРның башка республикалары һәм шәһәрләренең пропаганда һәм агитация бүлекләре тарафыннан чыгарылган. КПССның Татарстан өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге дә бу эштән читтә калмаган, агитаторлар һәм пропагандистларга ярдәм йөзеннән партия тәкъдим иткән агитация материалларын бастырган. Алар әңгәмә һәм докладлар өчен тема булып торган, төрле коллективларның производство җыелышларында, комсомол оешмаларында, мәктәпләрдә укылган. Алар аша «Татариядә авыл хуҗалыгының ничек үскәнен», «партиянең XXIV съездының күргәзмә агитациясе нинди булырга тиешлеген», «тулай тораклар шәһәре Чаллы халкын ничек бердәм коллективка туплап булуын», һәм шулай ук «халыкара аренада Пекинның нинди адымнар ясавын» белергә мөмкин булган…

ТАССРның партия тормышындагы «кечкенә тарихлар» 4 тиен торган һәм барлык җитәкче хезмәткәрләр һәм гади совет коммунистлары өчен мәҗбүри «уку әсбабы» саналган.

1970 нче еллар

ТАССРДА ТУГАННАР

Композитор Давид Тухманов 1972 елда Владимир Харитонов шигыренә музыка иҗат итә һәм... «Мой адрес – Советский Союз» дигән бу җыр совет чорының рәсми рәвештә танылмаган гимнына әверелә.

«СССРда туганнар», димәк, «Татарстанда туганнар» да, аны яттан белә һәм элеккечә үк дәрт вә энтузиазм белән җырлый. Әлеге җыр юллары соңрак «торгынлык чоры» дигән сәяси клишега әвереләчәк вакытның фотографияләренә тәңгәл килеп, аларны тулыландырып тора. Бу чорда яшәгән һәм анда яшәгәннәрен әле белмәгән кешеләр шул «торгынлык тормышларын» якты эшләре, кыю казанышлары һәм җырдагы юллар белән билгеләгән:

Я там, где ребята толковые,
Я там, где плакаты «Вперед!»,
Где песни рабочие, новые,
Страна трудовая поёт.

Карагыз да, үзебезнең хезмәт батырлыкларын, шат йөзләребезне, безнең данлы, әмма һич тә торгынлыкта булмаган үткәннәребезне искә төшерегез.

Заботится сердце, сердце волнуется,
Почтовый пакуется груз…
Мой адрес не дом и не улица,
Мой адрес – Советский Союз!

Фото: Е. Фрумин

Казан. Муса Җәлил һәйкәле. 1970 ел.

«Түбән Кама Нефтехим» җитештерү берләшмәсе. 1970 ел.

Әлмәттән Яр Чаллыга автозавод төзелешенә килгән комсомол-яшьләр төзүчеләр бригадасы. 1970 ел.

Фотоларны ТР Милли музее тәкъдим итте

Елхово АТХ хезмәткәрләре «Нефтьче» колхозына бәрәңге җыюда булышалар. 1970 ел.

«Камгэсэнергострой» берләшмәсе хезмәткәрләре. 1970 ел.

Чистай халык театры агитбригадасы авылларда чыгышлар ясап йөри. 1971 ел.

Пионерлар парады. 1972 ел.



Камал театры сәхнәсендә – «Мылтыклы кеше» спектакле. 1976 ел.



Камил Исхаков тантаналы пленумда чыгыш ясый. 1978 елның октябре.

КХТИның иң яхшы группасы – ВЛКСМның 60 еллыгын лаеклы каршы алу буенча ярышта җиңүче. 1978 ел.

Дәүләт музее фәнни хезмәткәре авыл кешеләренә лекция укый. 1978 елның июне.


Шагыйрь Сибгат Хәким һәм язучы Рафаэль Мостафин (1991–1998 елларда «Татарстан» журналының баш мөхәррире). 1979 ел.

1970 нче еллар

1979 ел.

70 НЧЕ ЕЛЛАРДАГЫ ТУЙ МОДАСЫ

Казанның Идел буе ЗАГСында яшь парларның никахы узган еллардагы кияү-кәләшләр карашы астында теркәлә. Диварларда – үткән гасырның 60 нчы, 70 нче, 80 нче, 90 нчы елларындагы туй фотосурәтләре. Әлеге оригиналь күргәзмә «Туй киемнәре модасы» дип атала.

-70 нче елларны башкаларыннан мин туй модасы буенча аера алам. Ул үзенчәлекле иде. Бәлки, үзем шул чакта кияүгә чыкканга шулай тоеладыр, – дип сөйли Ирина Сергеевна Семушина. Ул бүген ЗАГСка иң гүзәл кәләшнең туганы буларак килгән һәм, безнең кебек үк, туй модасы фотокүргәзмәсен мавыгып карый. – Мин ательеда кием тегү остасы булып эшләдем һәм теләсә нинди күлмәкне уйлап табып тегә ала идем. 70 нче елларда бик кыска – мини туй күлмәкләре тектем, аларны кигән Казан кәләшләре искиткеч нәфис күренә иде. Аннары никахлашучылар һичшиксез Горький паркындагы Билгесез солдат монументы янында фотога төшәргә тиеш. Мин үземә дә шундый күлмәк тектем – һәм зур хата ясадым, чөнки кәләш үзенә туй күлмәген тегәргә тиеш түгел – начар фал, гаилә таркалачак. Шулай булды да. Әмма ул күлмәгемне барыбер горурланып һәм сагынып искә алам – бик килешә иде ул миңа. Кызганыч, фотоларны сакламадым, аерылышкач, ертып ташладым, саклыйсы булган икән. Менә бу күргәзмәдә алар бик урынлы булыр иде.

Фотоларны яңадан Александр Ефремов төшерде

1969 ел.

1971 ел.

1976 ел.

1979 ел.

1970 нче еллар

ХӘРБИ ЧОР ИЛЧЕСЕ

1979 елның 22 ноябре. Әфганстанда СССРның яңа илчесе Фикрәт Табиев ӘДР президенты Хафизулла Әмингә ышаныч грамотасы тапшыра. Советлар Союзының «дусты» бәхетле: Мәскәү, Табиевка кадәр булган илчене чакыртып алып, аныңча эшләде. Әмма Әмин дә бу вакыйгалардан соң бер ай чамасы гына яшәп кала. Фикрәт Табиевка Әфганстанда җиде ел илче булып торырга һәм әфган җирендә барган күп кенә фаҗигале вакыйгаларның шаһиты, турыдан-туры катнашучысы булырга туры килә...

Автор:
Әскәр Сабиров

Әфганлылар белән очрашуда. Уртада: Фикрәт Табиев һәм Әфганстан Министрлар советы рәисе Кештбанд.

Сугыш барган илдә илче булып эшләү ничек булган соң? Кайчак яу кырында ут астында йөргән сугышычынықыннан да болайрактыр. Сугышта барысы да аңлаешлы: алда – дошман, янәшәңдә – үзеңнекеләр. Ә дипломатия кырында? Безнекеләр Әминнең сараен штурм белән алганнан соң, «Правда» газетасында халык өчен версия пәйда була: «Ачулы халык ташкыны Әминне, иярченнәре белән бергә, гадел халык суды каршына бастырды һәм җәзасын бирде...» Олы сәясәттә еш кына беренче карашка бик гади тоелган карарлар артында да күпбаскычлы комбинацияләр тора.

Фикрәт Табиевны Әфганстанга илче итеп билгеләү дә шул комбинацияләрнең бер өлеше булгандыр, мөгаен. Чыннан да дипломатларны алыштыру Советлар Союзында Әфганстан президенты Хафизулла Әминнең шәхси үтенечен исәпкә алгандай итеп эшләнә. Берничә ай эчендә Әмин Мәскәүгә совет илчесе Александр Пузанов өстеннән җиде шикаять юлларга өлгерә. Әфганстан президенты совет илчесен оппозициягә хәерхаһлылыкта гаепли, илче революция эшенә һәр яктан зыян китерә, дип ышандырырга тырыша.

Чынлыкта шактый катлаулы хәлдә калган Хафизуллага Иске мәйданда беркем дә ярдәм итәргә ашыкмый. Элеккеге илченең эшчәнлеге нәтиҗәле булмауны танып һәм аны кире илгә кайтарып, Мәскәү, һичшиксез, әфган президентының уяулыгын киметергә ниятли.

КАБУЛГА – ДАВЫЛ АЛДЫННАН

Сугыш исе килгән, ил эчендә әйдәп баручы партияләр һәм төркемнәр арасында каршылыклар сүз белән генә чикләнмисе мәгълүм булган дәүләтләргә (искә төшерик, 1979 нчы елның сентябрендә Әмин, хакимияткә килү өчен, Нур Мөхәммәд Таракины юкка чыгара) илче булып китәргә атлыгып торучыларны профессионал дипломатлар арасында табу шактый четерекле эш була, әлбәттә. Ул чакта да тәвәккәллек таләп ителгән әлеге вазыйфадан берничә кандидат баш тартканнан соң, Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән Фикрәт Табиев кандидатурасына тукталалар.

Әфганстанга алдынгы автоном республиканың алдынгы җитәкчесен илче итеп җибәрүне КПССның төп идеологы Михаил Суслов тәкъдим итә. Дөрес, Әфганстан партия-хуҗалык идарәсе буенча тупланган тәҗрибәне шунда ук дипломатиягә алыштыру җиңел булган илләр исемлегенә керми. Дипломатик тәҗрибә Табиевта бөтенләй булмый. Әмма КПСС ҮКнда, ихтимал, тиздән бу илдә дипломат теленең беренче рольләр биләмәячәген белгәннәрдер. Икенче яктан караганда, провинциядән килгән дипломатның шиксез өстенлекләре бар. Табиев татар, мөселман – димәк, аңа җирле җитәкчелек, халык белән уртак тел табу җиңелрәк булачак.

Фикрәт Табиев өчен партия дисциплинасы – буш сүзләр генә түгел. Карьера амбицияләре дә тиешле югарылыкта. Нәтиҗә бер: мондый тәкъдимнән баш тартмыйлар. Кремльдә, күрәсең, нәкъ менә шуңа исәп тотканнардыр.

Соңрак Фикрәт Әхмәтҗанович болай дип искә ала: «Без Суслов белән Леонид Ильич Брежнев янына кердек.

– Менә, иптәш Табиев ризалыгын бирде, – дип хәбәр итте Михаил Андреевич.

– Бик яхшы! – дип елмайды Леонид Ильич. – Фикрәттә мин беркайчан да шикләнмәдем».

Яңа вазыйфага керешер өчен Табиевның күпме вакыты була соң? Алдагы вакыйгалар күрсәткәнчә, бөтенләй булмый. Яңа илче үзенең Кабулдагы резиденциясендә чемоданнарын бушатканга бер атна да үтәргә өлгерми, КПСС ҮК Политбюросы ул вакытта Әфганстан хакименә туры мәгънәсендә үтергеч характеристика бирелгән документ кабул итә. Документта болай диелә: Әмин «...хакимлек итүне

СССР илчесе Фикрәт Табиев әфганлылар арасында.

ярата, шәфкатьсезлегә һәм мәкерлелегә белән аерылып тора, Әфганстан халык-демократик партиясенең оешканлык ягыннан йомшаклыгы һәм идея ягыннан көчсез булуы шартларында, үзенең шәхси хакимиятен саклап калу өчен, аның сәяси режим юнәлешен үзгәртергә омтылуы куркынычын сызып ташларга ярамый. СССР белән мөнәсәбәтләрдә Әминнең ихлас булмавы һәм икейөзлелегә торган саен ныграк ачыла бара».

Әмин сараен штурмлауга бер айдан да әзрәк вакыт калган була.

ДЕГЕТ МИЧКӘСЕНДӘГЕ ДИПЛОМАТИЯ

Хафизулла Әмин яңа совет илчесенең үзенә ошавын яшерә алмый. Кабулга ияләшергә дә өлгерми, ул әфган президентына күптәннән көтелгән хәбәрне җиткерә: СССРда аның Әфганстанга совет гаскәрләренең чикле контингентын кертүне сораган үтенече канәгатьләндерелә. Үзе Таракины юкка чыгарган кебек, оппозициянең дә шулай ук эшләвеннән курыккан Әмин моңа кадәр Мәскәүгә бертуктаусыз мондый адымның кирәклеген раслый торган үтенечләр юллый һәм әлегә кадәр нәтиҗәсе булмый. Элеккеге илче вакытында, Хафизулла фикере буенча, барысы да матур сүзләргә генә кайтып калган, ә яңасы килгәч, яхшы якка үзгәрешләр күзгә күренеп тора. Ләкин вәгъдә ителгән гаскәрләрне кертү кайчан башланыр соң? Фикрәт Табиев бу мәсьәләдә дә төгәл. Ул Әфганстан президентына гаскәрләрне кертү 25 декабрьдә үк башланырга мөмкин, дип хәбәр итә. Әмин шатлыгын яшерә алмый: аның хыялы тормышка аша кебек.

Ә Мәскәүнең, үз чиратында, шулай ук планнары чынга аша башлый. Кабулга яңа илченең килүе Әфганстан президентының уяулыгын киметте – бу күзгә күренеп тора. Фикрәт Табиев белән Хафизулла Әмин беренче көннәрдән үк бер-берсе белән нормаль мөнәсәбәтләр урнаштыра. Алай гына да түгел, күпмедер вакыт үткәннән соң, әфган президенты Табиевка чиксез ышаныч күрсәтә башлый. Моңа бер очрак ярдәм итә. Бервакыт төшке аштан соң Әмин үзен кинәт кенә начар хис итә башлый. Үзен агулаганнар дип курыккан Әмин, коты очып, совет илчесенә хәбәр итеп өлгерә. Табиев тиз генә үзенең табибын президент янына җибәрә. Табиб, чыннан да, җитди агулануны раслый һәм Хафизулланың гомерен саклап кала…

Соңрак ачыклана: әфган президентын агулауны махсус хезмәтләр оештыра, гаять яшерен рәвештә әзерләнгән әлеге операция, аның детальләре турында совет илчесенә хәбәр итеп тормыйлар. Әгәр белгән булса, ихтимал, безнең гаскәрләргә гомерләрен куркыныч астына куеп, президент сараен штурмларга кирәкмәс тә булган булыр иде…

Әмма әлегә сәясәтчеләр, дипломатлар, киңәшчеләр Политбюро документында язылган күрсәтмәләрне тормышка ашыра: «Югарыда аталганнарны исәпкә алып һәм таләп ителгәннәрдән чыгып, Әфганстанда контрреволюциянең җиңүен яисә Әминнең көнбатышка сәяси юнәлеш алуын булдырмас өчен, түбәндәге линия буенча эшләү максатка ярашлы дип табыла: Әмин белән, аңа ышанмавыбызны һәм аның белән эш йөртергә теләмәвебезне аңларга сәбәпләр калдырмаслык итеп, актив хезмәттәшлекне дәвам итәргә. СССРга карата дустанә мөнәсәбәт күрсәткән һәм «Апрель революциясе» язмышы өчен борчылган затлар белән әңгәмәләр вакытында хәзерге көндә Әфганстанда барган хәлләрне хуплыйбыз дигән тәэсир калдырмаслык итеп сөйләшергә һәм мондый затларны читкә этәрмәскә…»

ШӘҺӘРДӘ НИНДИ АТЫШЛАР БАРА?

Әмин сараен штурмлау турында Фикрәт Табиев бәрелешнең иң кызган вакытында гына белә, дип сөйлиләр: әфган лидерын юкка чыгару буенча оештырылган операциянең яшеренлеге моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә югары була. Операция белән җитәкчелек иткән Вадим Кирпиченко (СССР Дәүләт куркынычсызлык комитетында легаль булмаган разведка эшен алып барган суперяшерен «С» идарәсе белән җитәкчелек итә) болай дип искә ала: «Беренче ату тавышлары ишетелүгә һәм илчелек территориясенә яралыларны ташый башлауга, илче Фикрәт Әхмәтҗанович Табиев дулый башлады.

Илченең хатыны Динә Мөхәммәтовна Табиева Әфганстан дин эшлекләләре арасында.

Әфганстан президенты Нәҗибулла СССР илчесе Фикрәт Табиевта кунакта.

Миңа шалтыратты һәм усал тавыш белән шәһәрдә нәрсә барганлыгын аңлатуны таләп итте. Мин сугыш бара, хакимият «парчамистларга» күчә һәм сөйләшеп торырга вакытым юк, дидем. Вазгыять турында тулырак иртән хәбәр итәрбез, дип кистердем...»

Күп нәрсә яшеренлек пәрдәсе белән өретелгән, бер операциянең детальләрен – КГБ гына, икенчесенекен хәрби киңәшчеләр генә белгән шартларда илче өчен үз вазыйфаларын башкару ни дәрәҗәдә катлаулы булуын күз алдына китереп була. Әлбәттә, сугыш барган, әмма шул ук вакытта меңләгән ватандашың – укытучылар, төзүчеләр, табиблар һ.б.лар эшләгән илдә дипломатия кагыйдәләрен саклап эш итү – гаять катлаулы.

Әйтергә кирәк, Фикрәт Табиевның сайлау мөмкинлеге була. Иң җиңеле – үз резиденциясендә ышанычлы сак астында утырып тору, ил буенча хәрәкәт итүләрне минимумга калдыру. Ләкин илче бөтенләй башка юлны сайлый. Провинцияләр буйлап еш йөри. Хакимлек итүче партия һәм оппозиция вәкилләре, руханилар, хәтта каршы торучы якларның кыр командирлары белән дә очраша. Һәм соңрак үзенең истәлекләрендә сөйләгәнчә, һәр әфган кешесенә гади генә фикерне җиткерергә тырыша: Советлар Союзы әфган халкына яманлык теләми, яңа тормыш төзергә булыша һәм булышачак. Гаскәрләр ни өчен кирәк? Алар реакцион көчләрне тыеп тору өчен кирәк, һич кенә дә бүтән максатларда түгел...

Совет илчесе китергән дәлилләр кайвакыт чыннан да тәэсирле була. Саланг тау сырты аша үтә торган юл, Гераттан Кандагарга кадәрге автотрасса, Әфганстанга 250 мең гектар сугарылган җирләрне кире кайтарган мелиорация эшләре, гидроэлектростанцияләр, хастаханәләр – болар барысы да совет белгечләре катнашында башкарылган эшләр. Гади халык моны белә һәм күрә. Шулай ук башка бер генә илнең дә Әфганстанда бер генә нәрсә дә төземәгәнен дә яхшы аңлый...

ГОРБАЧЕВКА ХАТ

Шулай да рухи лидерлар һәм офицерлар арасында совет илчесе казанган ихтирам аңа иминлекне гарантияли алмый. Көнбатышка йөз тоткан көчләргә Табиевның гамәлләре, мөгаен, моҗәхитләргә каршы армия тарафыннан кылынган операцияләрдән дә кимрәк зыян китермәгәндер. Табигый ки, мондый вазгыятьтә уңайсыз илчедән котылу юлын эзләгәннәр дә җитәрлек була.

– Илчелек капкасыннан чыгып киткәндә мин беркайчан да кире исән кайтукайтмавымны белми идем, – дип искә төшерә Фикрәт Әхмәтҗанович күп еллар үткәннән соң. – Кабулда адым саен үлем сагалап тора. Хәтта хатыным белән Михаил Горбачевка хат та яздык: безне үтерсәләр, балаларыбызга күз-колак булырга, ярдәмнән ташламаска үтенеп. Хат илчелектәге сейфка яшерелгән иде, бәхеткә, кирәге чыкмады.

Гаҗәп, шул ук вакытта Табиев сугыш барган Әфганстан буенча сәфәрләре яисә сөйләшүләр барышында килеп туган нинди дер гадәттән тыш хәлләр турында беркайчан да сөйләми. Киресенчә, гел шуңа басым ясый: «совет илчесе» исеме үзенә күрә сак грамотасы – илчегә кагылмыйлар. Күрәсең, бу очракта «проблемалы» илдә экстерн рәвешендә үзләштерелгән профессиональ дипломатия алымнары сизелгәндер. Табиев четерекле якларны дипломатларча җайлап җибәрергә, начар яклар турында күп сөйләмәскә тырышкандыр.

Шул ук вакытта 1980 елдан 1981 елның августына кадәр илче сагына кергән Александр Лисичкин (Кавказ аръягы чиге округы офицерларыннан һәм прапорщикларыннан торган махсус билгеләнештәге подразделениедә хезмәт иткән) төрле хәлләр булуы турында искә ала:

СССР илчесе Фикрәт Табиев кунакларны кабул итә.

Динә Табиева, Фикрәт Әхмәтҗанович һәм Әфганстан җитәкчесе Бабрак Кармаль.

Иң югары дәрәҗәдәге очрашу.

– Без аның тормышын сакларга, иминлеген тәэмин итәргә тиеш идек. Кая да булса чыгар алдыннан маршрутны тикшерәбез, чөнки минага, снайпер пулясына яисә мөҗәхитләр капкынына эләгү мөмкинлеге зур. Илче машинасына берничә мәртәбә аттылар да. Провинциягә барырга туры килгәндә, икенче машина бирәләр – кораллы өстәмә сак өчен. Бервакыт «кызган» әфганлылар төркеменә тап булдык – ниндидер җыен бара иде. Алар илче утырган «Мерседес»ны уратып алдылар, мин дә шул машинада идем, автомобильне әйләндереп каплар өчен, селкетә башладылар. Үзләре: «Аллаһу әкбәр!» дип кычкыра. Һавага берничә мәртәбә атарга, кисәтергә туры килде. Автомат тавышын ишеткәч, читкә таралыштылар.

Ул вакытта Әфганстанда булган барлык ватандашларыбызның – дипломатмы алар, эшчеме, хәрбиләрме яисә гражданлык белгечләреме – барысының да тормышына куркыныч яный иде. Әфганстандагы бөтен киңәшчеләргә, хәтта укытучы белән табибларга да корал бирелүе очраклы хәл түгел, өстәвенә, алар сак белән дә тәэмин ителәләр иде. Шулай ук совет илчесенә карата Әфганстандагы кайбер террористик төркемнәр каршына төгәл максат куелуы да билгеле факт: Табиевны әсирлеккә алырга һәм совет хөкүмәтеннән аның гомере өчен акча сорарга. Дипломатны һәм аның позициясен хөрмәт иткән мөҗәхитләрнең башлыклары әлеге планнарны тормышка ашырырга комачаулаган, дип тә сөйлиләр.

Әфганстан Демократик Республикасында эшләү дәверендә Фикрәт Табиев 30 килограммга ябыга.

«КАТГЫЙ ЯШЕРЕН» ГРИФЫ

Табиев көн саен диярлек тормышын куркыныч астына куя. Шул ук вакытта ватандашларының гомерләрен саклап калу өчен булдыра алганның барысын да кыла. Әфганстанда төзүче булып эшләгән Виталий Гафаров бу илдә булганда үзендә һәрвакыт куркыныч тойгысы яшәвен искә ала. Эш шуңа җитә ки, ул илчелеккә киңәш сорап бара.

– Табиев минем Казаннан икәнемне белгәч, болай диде: «Улым, син нәрсә, үзебездә эш тапмадыңмы? Үлеп калганчы, кайтып кит моннан. Бу безнең җир түгел!» Аның киңәшен тыңламаган булсам, язмышым ничек булыр иде, гомумән исән булыр идемме икән, белмим…

Иосиф Кобзон белән булган очракны да искә алыйк. Табиевның ватандашларына карата кайгыртучанлыгы концерт белән килгән җырчының чыгышын чак кына өзми. СССР илчесе Әфганстанга килергә тәвәккәлләгән артистка сугышчылар каршында чыгыш ясарга рөхсәт итми.

«Иптәшләр, бу ничек була соң инде? – дип, ризасызлыгын белдерә ул чакта Иосиф Давидович. – Мин монда артистлар төркеме белән килдем, без үзебезнең сугышчы-интернационалистлар каршында чыгыш ясарга, аларның сугышчан рухын күтәрергә әзер. Әйдәгез, эшлик инде…» Фикрәт Әхмәтҗанович каршы төшә: «ҮК Политбюросы рөхсәтеннән башка ярамый. Куркыныч! Ә сезне үтерсәләр, Иосиф? Без халыкка ни дип әйтербез?»

Ул вакытта Кобзонның абруе үз ролен үти. Табиев ризалыгын бирә, әмма хәрбиләргә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә сак күрсәтелүен таләп иткән күрсәтмә бирә.

Дипломатия хезмәтенең катгый таләпләре, кагыйдә буларак, иң мөһим эпизодларны кадрлар артында калдырырга мәҗбүр итә. Дипломатик кабул итү кичәләре, матбугат конференцияләре, имзаланган документлар – болар барысы да күз алдында. Куркыныч һәм көтелмәгән каршылыклар тулы көндәлек эш – анысы турында азлар гына белә. Әфганстанда СССР илчесе эшчәнлегенең күп кенә сәхифәләре бүгенге көнгә кадәр «катгый яшерен» грифы белән саклана.

Хәер, аның белән бергә, иңне-иңгә куеп эшләгән кешеләрнең хәтере, истәлекләре калган. Әфганстанда Табиев алып барган дипломатлык эшенә иң кыска һәм тирән бәяне, мөгаен, күптән түгел генә бакыйлыкка күчкән милләттәшебез, Россия Хәрби фәннәр академиясенең элеккеге президенты Мәхмүт Гәрәев биргәндер: «Фикрәт Әхмәтҗановичның Әфганстанда СССРның Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илче буларак эшчәнлеге турында болай дип әйтә алам: ул вакытта Әфганстанда вазгыять бик авыр иде, төрле катлаулы хәлләр туа килде, ләкин Табиев һәрвакытта да алардан чыгу җаен таба алды».

Башка объектив критерийлар да бар: Фикрәт Табиев – бер ил җирендә башкарган хезмәте өчен ике орден алган СССРның бердәнбер илчесе. Ике Ленин ордены. Аның Әфганстандагы җиде еллык хезмәтенә дәүләт шундый бәя бирә.

Әлеге сугышта илебезнең чын югалтуларын белгән Фикрәт Табиев исә соңгы көннәренә кадәр Әфганстанны үзенең җан ярасы дип атый.

1970 нче еллар

1978: САЛКЫН АФӘТЕ

Автор: Алсу Троицкая

Табигать торышын теркәп баручы елъязмалар бүгенге көндә 140 еллык мәгълүматны үз эченә ала. Татарстан территориясендәге иң көчле салкыннар да әлеге елъязмага кереп калды. Республиканың күпчелек районнарында 1979 елга аяк басканда термометр баганасы 48 градус салкынны күрсәтә!

Фото: Александр Ефремов



1978 елның 30 декабреннан 31 декабрена каршы төндә шулкадәр салкын була ки, Татарстандагы бакчаларда барлык агачлар да өшеп бетә, иманнәрнең күбесенә салкын суга – алар буйга ярыла. Агачларның ярылу тавышы мылтыктан аткан тавышны хәтерләтә. Еллар узган саен иманнәрдәге тирән яралар төзәлә, алай да кәүсәләрнең тышкы ягында эре җыерчыклардай чыгып тора торган җәрәхәт эзләре кала, алар агачның буеннан буена сузылган. Урманчылар әлеге салкын эзләрен «морозобоина» дип атый.

Ул вакыттагы салкыннар турында искә төшергәндә генә дә тәннәр чемердәп китә. Табигать ясаган «Яңа ел бүләге» онытырлык булмый шул.

Газ үткәргечләрдәге аварияләр, җылылык трассаларында шартлаган торбалар, трамвайдан коелган буяу кисәкчекләре, эшләүдән «баш тарткан» тормоз... Техника чыдамый, кешеләр туңа-өши...

ЛЕНИН ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП...

30 декабрьдә Идел ярына утынга дип төшкән җирендә авыл тракторчысы ташландык урманчы йорты янында ике малайны күреп ала. Тәрәзәләре дә ватык күренә. Җиңелчә киенгән, чаңгычы костюмы кигән, өшегән яшүсмерләр үзләре турында сөйли. Тракторчы бу хәл турында Тәтеш районы милиция бүлегенә хәбәр итәргә ашыга. 1978 елның 29 декабре иртәсендә Татариягә Казахстан ССР Павлодар мәктәбеннән бер төркем 7–10 нчы класс укучысы килгән була. Укытучы апалары җитәкчелегендә алар Тәтештән Казанга кадәр 120 чакрым юлны чаңгыда үтәргә уйлый – Ленин эзләре буйлап походка чыгалар. Балалар Идел буйлап Тәтештән Кама Тамагы ягына юл тоталар.

«КАРА НОКТАЛАР»НЫ» КОТКАРУ

Юлга чыкканда барысы да тәртиптә кебек тоела. Кышкы көн гадәттәгедән аерылып тормый, әмма көннең икенче яртысында көчле җил куба, суыта, балалар берәм-берәм туңа башлый. Алар өчен борчылган укытучы иң үткен малайларны Тәтешкә ярдәм сорарга җибәрә.

– Ул көнне яшүсмерләр Тәтешкә барып җитә алмыйлар, урманчы йортына юлыгалар, тәрәзәне ватып, шунда кереп төн үткәрәләр. Ә иртәнге якта безнең бүлеккә шалтыраттылар: Иделдә Казахстаннан килгән укучылар төркеме бәлагә юлыккан, – дип искә ала 1978 елда Тәтеш районы эчке эшләр бүлегендә участок инспекторы булып эшләгән **Александр Шлячков**. – Коллегам Евгений Торгашов белән балаларга җылы киемнәр алдык та, эш өчен бирелгән «Буран»га утырып, Идел яры буйлап калганнарны эзләргә киттек. Тагын да салкынайта төште, 20 градуслар булгандыр, мөгаен. Кар бик күп, җитмәсә, елгада боз өстенә су чыгып, аны кар каплаган урыннар да шактый. Атлавың була, шундый күпкатлы «пирогка» басасың, аягың мизгел эчендә юешләнеп өлгерә. Карыйм, караңгы төшә башлады. Женя, дим, Долгая Полянага кадәр җитик тә, мөгаен, кире борылырбыз, мәгънә юк. Алга карасак, кар эчендә бер кара нокта күренә. Балыкчымы, кем? Килеп җитсәк, салкыннан бөрешкән бер малай утыра – чаңгысы юк, үзе чаңгы ботинкалары кигән. Безне күрүгә, елап җибәрде: «Абый, коткарыгыз, абый...», – ди. Кулына бияләй кидертмәкче булабыз – бармаклары тураймый... Елга буйлап тагын берничә «нокта» таптык. Табуын таптык, алга таба нишләргә? Беренче малайны «Буран»га утыртып ярга таба алып киттек. Ә яр – текә, кар чанасында менеп булмый. Без килеп җиткән Долгая Поляна яры янында чокыр бар, анда, ни дисәң дә, җил юк, дип уйладык. Табылганнарның барысын да шунда ташырга булдык. Корыган куаклар, утын җыеп, чокырда учак ягып җибәрдек. Женя яр буенда калды, мин елга буйлап, берәмтекләп, балаларны җыйдым...

СОҢГЫ РЕЙС

Ничә рейс ясаганын Шлячков хәтерләми инде. Ике егет үз аякларында китәләр, аларны Монастырский авылы балыкчылары табып ала. Соңгылары итеп елгадан чокырга укытучыны һәм Марина исемле кызны алып кайталар.

– Маринаның хәле беткән, йокы капчыгында ята. Ыңгыраша, ул вакытта әле исән иде. Укытучысы елый: «Иң көчле кыз, иң мәрхәмәтлесе. Бөтен кешегә булышты, бөтенесен тартып чыгарды, ә үзенең хәле

Хәтта быелгы җылы, карсыз кышта да балыкчылар сукмагы буйлап Иделгә таба төшү җиңел түгел. Ә күтәрелергә? 1978 елның 30 декабре көнендәге һәм төнендәге коточкыч салкында каткан-өшегән балаларга ничек авыр булуын күз алдына китерүе дә кыен.

бетте». Яхшы күңелле Марина Благодатская шул чокырда мәңгелеккә күзләрен йома…

КҮТӘРЕЛЕП БУЛМЫЙ

Учак янына тезелешеп утырган балалар, салкын «кайтканда»гы көчле авыртуга түзә алмыйча кычкыралар, елыйлар.

Соңгы рейс вакытында Александр Иванович яр буенда ике шәүлә күреп ала. Аларны эзлиләр, дип куана. Әйе, нәкъ шулай булып чыга да. Милиция башлыгы Эдуард Трофимов һәм авыл фельдшеры Ирина Шмагина икән. Болар чокырга төшә. Ул арада температура 40 градуска кадәр төшә. Нишләргә? Өскә кадәр күтәрелергә балаларның хәле юк, монда булган кешеләр Иделнең уң яры нинди текә икәнлеген беләләр. Төнгә калу исә – катып-өшеп үлү дигән сүз. Бер генә юл кала – ничек тә булса өскә менәргә. Һәм Шлячков тауга менеп китә:

– Билдән кар. Төн. Караңгы. Бернәрсә күренми. Менеп җиттем. Ике трактор тора, фаралары яна, гөрелтеләре ишетелә, димәк, сүндерелмәгән. Аллага шөкер, дим. Тракторларга кадәр өч метрлап ара калды дигәндә генә, алар, кинәт борылып, Долгая Поляна ягына киттеләр. Гаҗизләктән нишләргә белмичә, кар өстенә авам, әзрәк хәл алгач, тагын күтәрелеп, туп-туры, кар өемнәреп ерып, алар артыннан үрмәлим. Үрмәләп барып җитәм, менә алар, җаннарым, Долгая Полянадагы бер өй янында торалар. Өйгә атылып керәм, тракторчыны күрермен, тизрәк ярга барырга кирәк, диярмен… Су да эчеп алырмын, тамагым шулкадәр кипте… Кулыма чүмечне алуым булды, тракторларның гөрелдәү тавышлары ишетелде – ярга таба китеп бардылар. Бетте, дим…

Участковый алар артыннан бар көченә йөгерә, кычкыра. Ишетмиләр. Тагын туптуры – кар өемнәре аша йөгерә, кирегә – ярга таба. Ниһаять, куып тота ул тракторларны, Александр Артемьев кабинасына кереп утыра. Балаларның кайда калганнарын аңлата. Тракторчы икеләнеп тормый:

– Әйе, төшәргә текә урын, төшсәк, менә алмаска мөмкинбез. Ләкин башка юл юк. Минем белән барасыңмы?

– Әлбәттә, – дим.

– Бер 100 грамм тотабызмы? – Артемьев аракысын чыгара. Кырык градуслы эчемлек койка – холодецны хәтерләтә. Көчкә стакан төбен капларлык аракы агызып алалар, сало белән йотып җибәрәләр дә юлга кузгалалар.

– Трактор янтая, Саша, төшеп, трактор чылбырын чистарта, урынына куя. Шулай әкренләп төшеп җитә алдык, – дип искә төшерә участковый.

КОТЫЛУ

Алар белән бергә икенче тракторда Монастыркий авылындагы 74 нче СПТУда производство мастеры булып эшләгән **Александр Тимарин** да ярга төшә:

– Көндез мин группа белән остаханәдә шөгыльләндем. Шулвакыт авылда чаң тавышы ишеттем. Бездә янгын яисә тагын берәр шундый гадәттән тыш вакыйгага булганда гына чаң кагалар. Ул көнне училище директоры Николай Чабурин һәм физрук Александр Красненков Иделдә балык тотарга баралар. Алар янына ике малай килеп чыга һәм иптәшләренең нинди бәлагә тарыганнары турында әйтә. Аларны авылга алып кайтарып җиткергәч, чаң кагалар. Шунда ук Тәтешкә дә хәбәр итәләр. Аннан, «Буран»га утырып, участковыйлар чыга, моннан ат белән – участковыебыз Николай Морозкин, тракторларда мин һәм Александр Артемьев балаларны эзләргә юнәлдек. Таудан төшүен төштек, менә алабызмы-юкмы – белмибез. Ләкин салкын бу очракта ярдәм итте – кар суыктан катып килде. Күтәрелгәндә проблема булмады.

БАЙЛАР ЙОРТЫНА КАДӘР

Балаларны Долгая Полянадагы байлар йортына (өяз дворяннары җитәкчесе алпавыт Молоствов утары, хәзерге вакытта – музей. – Ред.) ташый башлыйлар. Чокырга төшәләр – тракторны сүндереп тормыйча, берничә баланы тиз генә кабинага утырталар да өскә күтәреләләр. Барысын да ташып бетерәләр. Ул вакытка инде үлгән Маринаны ат чанасына салалар, чананы тракторга тарттырып өскә алып менәләр. Бик кызганыч була… Бөтен балаларны җыеп бетергәндә, Долгая Полянага инде ашыгыч ярдәм дә, милиция дә, район җитәкчелеге дә, бульдозерлар да килеп җиткән була. Аннан балаларны Тәтеш район хастаханәсенә ташый башлыйлар.

– Ә салкын көчәя генә бара. Күз алдына китерәсезме, коточкыч суыктан имәннәр шартлап сына башлады. Ул чакта без бик каты туңдык. Балалар белән чокырда калган Женя Торгашов баткан – итекләре юешләнгән иде. «Каттым мин, әйдә итекләрне алышып торыйк әле», – ди. Аның итекләре кибетнеке, ә минеке баскан итекләр. Бирдем салып, аннан үземнең аякларны эләктереп алды, төн уртасында өйгә кайткач, ышкып, көчкә җылы керттек аякларга.

Шлячков белән Торгашов та нык туңалар ул салкында. Аларның эш транспортлары – «Буран» аста кала, Монастырскийга тракторда кайталар, хәер, кабина эчендә дә урамнан аз гына җылырак була. Авылда инде Тәтеш автомәктәбеннән җибәрелгән ЗИЛ-157 машинасына күчеп утыралар, үлгән кыз баланы да шул машинага салалар. Иртән аны моргка илтәләр, ә үзләре эшкә чыгалар. Идел буеннан «Буран»ны соңрак алып менәләр.

ФИЛЬМ ТӨШЕРЕРЛЕК СЮЖЕТ

– Әнә тегендә, кыяда, Марина Благодатскаяның исеме язылган такта һәм кеч-

Балаларны коткаргандагы каһарманлыклары өчен Александр Тимаринны һәм фельдшер Ирина Шмагинаны 1979 елда грамота һәм 90 сум акча белән бүләклиләр. Александр Шлячков һәм Евгений Торгашовка Казахстан ССР Югары Советы Президиумы рәхмәт грамоталары җибәрә.

кенә генә һәйкәл тора иде. Дөрес, хәзер инде ул юк, диләр – яр ишелә бара. Барып карый алабыз, – дип тәкъдим итте безгә Александр Тимарин.

Һәм без Долгая Полянага киттек. Хәтта быелгы җылы, карсыз кышта да балыкчылар сукмагы буйлап Иделгә таба төшү җиңел түгел. Ә күтәрелергә? 1978 елның 30 декабре көнендәге һәм төнендәге коточкыч салкында каткан-өшегән балаларга ничек авыр булуын күз алдына китерүе дә кыен. Марина истәлегенә куелган һәйкәл, чыннан да, җимерелгән. Бары тик тимер-бетон багана гына калган...

Исән калган балаларның күбесе Иделдәге фаҗига нәтиҗәсендә колакборыннарның өшетәләр, кайберләренең кул-аяк бармакларын кисәләр, бер малайның хәтта аяк табанын ампутациялиләр... Укытучыны хөкем итәләр. Менә шундый җан өшеткеч вакыйга, курку һәм өмет көрәшкән катастрофа жанрында фильм төшерү өчен сюжет булырлык фаҗига.

Марина истәлегенә куелган һәйкәл күптән җимерелгән. Бары тик тимер-бетон багана гына калган...

КАРСК ДИҢГЕЗЕННӘН КИЛГӘН АРКТИК САЛКЫН

Роза Шәфыйкова, РФ атказанган метеорологы. 1970–2008 нче елларда Татарстанның Табигать торышы фаразлары хезмәтендә синоптик булып эшли, соңрак ТР Гидрометеорология һәм әйләнәтирә мохитне мониторинглау идарәсенең Гидрометеоүзәге Метереологик фаразлар бүлеген җитәкли:

– 1978 елның 30 декабреннән Татарстан территориясенә Карск диңгезеннән Себер антициклоны периферисе буйлап арктик салкыннар үтеп керә. Температура кинәт кенә төшә һәм көндез-төнлә 40 градус тирәсендә сакланып кала. 140 ел дәвамында алып барылган күзәтүләргә караганда, 1978 елның 30 һәм 31 декабрендә температура абсолют минимумга (һаваның иң түбән температурага төшүен шулай дип атыйлар) кадәр җитә. Әлеге күрсәткечләр бүгенге көнгә кадәр һава торышы архивларында рекорд буларак язылган: 30 декабрьдә – 39,4 градус салкын, 31 декабрьдә – 43,9 градус салкын.

1978 елның 31 декабреннән 1979 елның 1 гыйнварына каршы төндә Казань-опорная метеостанциясе термометрлары – 45,3 градусны күрсәтә. Күзәтүләр алып барылган чор эчендә бары тик бер генә мәртәбә – авыр 1942 елның 18–24 гыйнвары көннәрендә генә тагын да салкынрак була, ул чактагы рекордлы суыклар вакытында иң түбән температура 21 гыйнварда теркәлә – 46, 8 градус салкын.

Иң көчле салкыннарны метеорологлар Татарстанның төньяк-көнчыгыш районнарында теркиләр – Әгерҗе метеостанциясендә термометр баганалары безнең яклар өчен башка сыймаслык 51,5 градус салкынны күрсәтә, Алабуга һәм Яр Чаллы метеостанцияләре дә шундыйрак күрсәткечләрне терки.

Түбән Камада җылылык үзәгенең тулы системасы диярлек сафтан чыга. Бикләнстанциясендәге цистерналарда саклан-ган мазут таш кебек катып кила. Мазутны пар белән җылыталар. Мазутны сыегайту өчен мөмкин булган бөтен җирдән солярка ташыйлар. Эстакададагы кешеләр 15–20 минуттан артык эшли алмый – салкын үзәккә үтә.

Челтәр насосы шартлаганнан соң, бина эче пар белән каплана һәм су баса башлый, капшый-капшый гына барып, насосларны ябарга туры килә. Яңа ел табыннары турында онытып, дүрт тәүлек дәвамында ару-талуны белмичә үз эшләрен намус белән башкарган Нефтехим-комбинат авария хезмәте эшчеләренең фидакарьлеге нәтиҗәсендә генә шәһәр һәм барлык предприятиеләр салкыннан исән кала. Шәһәрләр җылылык белән тәэмин ителештә өзеклекләрне сизми дә кала дияргә була.

Республика буенча салкыннан шулай ук Яр Чаллы, Казан, Яшел Үзән, Әлмәт шәһәрләре зыян күрә, андагы микрорайоннарда шулай ук җылылык системасы катып килә. Сәнәгать предприятиеләреннән тыш, салкын бакчалардагы җиләк-җимеш агачларына, парк һәм урманнардагы яшел үсентеләргә «һөҗүм итә».

Тимер юл эше кыенлаша, аэропортларда очышлар туктатыла... Гомумән, Яңа ел төнендә транспорт белән шактый могҗизалар була. Казанда 2нче трамвай Бутлеров урамына күтәрелә алмый, чөнки көпчәк һәм рельслар арасында ышкылу юкка чыга. Тукай урамында салкыннан торбалар шартлый: су трамвай юлларын баса, рельслар боз астында кала...

31 декабрьдә линиягә бер генә «ЛИАЗ» автобусы һәм өч «ГАЗ-24» таксие чыга. Ике сәгатьтән алары да туктап кала, чөнки тормозлар эшләми башлый. Бары тик электротранспорт кына йөри. Җәяүлеләрне күреп, трамвай һәм троллейбуслар туктый, барысын да утырта баралар.

Бәхеткә, Яңа ел мәхшәреннән соң, төнге температура инде 36,6 градус була һәм алдагы көннәрдә әкренләп күтәрелә бара. Т

1970 нче еллар

70нче еллар афишасы

Февраль, 1972 ел

Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры.

ТАМАРА СИНЯВСКАЯ ҺӘМ МӨСЛИМ МОГАМАЕВ

1972 елның әлеге февраль кичендә Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә барган «Царская невеста» спектаклендә Любаша партиясен Тамара Синявская башкара. Спектакль тәмамланганнан соң, артистлар тамашачы каршына баш иярга чыгалар. Шул вакытта кинәт опера театры сәхнәсендә тынлык урнаша... Бер кочак кызыл канәферләр күтәргән Мөслим Могамаев сәхнәгә күтәрелә. «Сөйгәнем өчен йөз канәфер чәчәге», – дип елмая ул, чәчәкләрен Тамара Синявскаяга сузып. Мондый самими романтик мөнәсәбәтләр шаһиты булган Казан тамашачысы залны алкышларга күмә, әмма шаккатмый, чөнки бөтен ил Могамаев белән Синявская арасындагы олы һәм саф мәхәббәт турында ишетеп белә. Сөйгәне хакына җырчы, Чиләбе шәһәрендә планлаштырылган концертын күчереп, Казанга очып килә.

Ә мәхәббәт тарихына килгәндә, мөнәсәбәтләр Синявская Баку филармониясенә гастрольләргә килгәч башланып китә. Нәкъ менә шунда бөтенсоюз «Орфее» һәм күпләгән хатын-кызның кумиры Мөслим Могамаев Тамара Синявская белән очраша да. Аннан ул Зур театрның даими тамашачысына әйләнә, Синявская катнашкан барлык спектакльләрне карый һәм һәрвакыт сөйгәненә чәчәк бәйләме бүләк итә торган була. Мөслим Могамаев башкаруындагы «Мелодия» җыры да әлеге саф хисләр тәэсирендә туа. Тамара Синявская Италиягә, Миландагы «Ла Скала» театрына стажировка үтәргә китә. Мөслим Могамаев ярты ел сөйгәненнән еракта яшәргә мәҗбүр була. Аерылышып торуны бик авыр кичерә. Шул вакытта Пахмутова һәм Добронравов аңа үзләренең яңа җырларын күрсәтәләр. Җыр Могамаевның ул вакыттагы халәтенә шулкадәр туры килә ки, берничә көн эчендә җырчы аны яздырып та өлгерә. Җырның беренче тыңлаучысы, әлбәттә, Синявская була – «Мелодия» җырын ул телефон аша тыңлый. Тамара Синявская һәм Мөслим Могамаев 1974 елда кавышалар. Һәм алар Советлар Союзының иң матур музыкаль гаиләсе саналалар. Ике бөек җырчы бергә 34 ел яши.

АЛЛА ПУГАЧЕВА ҺӘМ «АРЛЕКИНО»

Ул концерт-солянканы Казан яхшы хәтерли. Клавдия Шульженконы тамашачы сәхнәдән озак җибәрмичә тора, ләкин аннан соң Алла Пугачева чыккач, зал алкышларга күмелә. Җырчы Болгариядә эстрада җыры конкурсында «Алтын Орфей» алган беренче хиты «Арлекино» белән чыгыш ясый.

Концерттан соң Алла Пугачеваны филармония директоры аша Казан мех берләшмәсе директоры үз биләмәләренә чакыра – продукциясен күрсәтергә, тунга заказ алырга да өмете була.

Пугачева беренче җавабы белән үк кырт кисә: «Мин фәкыйрьнең фәкыйре. Үземне котыртып йөрүе миңа нигә кирәк?» Тик барыбер ризалаша. Мехкомбинат хезмәткәрләре йолдызны алкышлар белән каршы ала, предприятие буйлап экскурсия үткәрә. Аннан соң күргәзмә залына алып керәләр. Җырчы хозурына төрледән-төрле туннар куелган, бәяләре коточкыч кыйммәт. Кунакка инглиз королевасы өчен әзерләнгән тунны да күрсәтәләр. Тик артистканың күңеленә чәшке койрыкларыннан тегелгән 700 сумлык кыска тун хуш килә.

Пугачеваның үлчәмнәрен алалар һәм якын арада заказны җибәрергә вәгъдә бирәләр. Ләкин тегү эшләре бер елга сузыла...

Ниһаять, эшен бетергәч, Татар филармониясе директоры Марат Таҗетдинов Пугачевага дигән тунны Мәскәүгә алып китә, үзе белән җырчының кызы Кристинага тегелгән мутон тунны кыстырган була.

Алла туннан көлә-көлә баш тарта, бик озак тектегез, хәзер инде мин үземә песец яки кеш тун да сатып ала алам, ди ул. Ә менә балалар тунына ул ихлас сөенә һәм кечкенә Кристина күпмедер вакыт Казан мутонын киеп йөри әле.

Алла Пугачева чираттагы тапкыр Казанга 1978 нче елның маенда килә. Җырчы Спорт сараенда тулы аншлаг белән чыгыш ясый. Бу юлы Пугачева илдә тиңе булмаган йолдыз була инде. Ул «Татарстан» кунакханәсендә туктала: «Кайда монда пианино, күрмим, мин ничек әзерләнергә тиеш?!», – дип кычкыра ул һәм, җырламыйм, дип тә куркыта.

Пианиноны «Мөслим Магомаев номерыннан» алып киләләр – җырчы бүлмәсенә кадәр күтәрү җиде сумга төшә (бер каты-бер сум тора). Шул рәвешле, концертны коткарып калалар. Сүз уңаеннан, җырчының концертына иң кыйммәтле билет бу вакытта 3 сум 50 тиен торган.

1976, 1978 еллар

Спорт сарае

ВЛАДИМИР ВЫСОЦКИЙ ҺӘМ «КАНАТЧИКОВА ДАЧА»

«Әйдәгез, мин сезгә күбрәк җырлыйм, ә сез миңа азрак кул чабыгыз...» Владимир Высоцкийның Казандагы бер концертында әйтелгән бу сүзләрен аның иҗатын яратучылар хәтерендә әле озак саклар. Атна буе барган чыгышлары кебек үк онытылмас алар. 1977 нче елның 12–18 октябре көннәрендә Казан аның җырлары белән яши. Актер ару-талуны белми эшли: көненә биш концерт – ун һәм унике сәгатьтә Яшьләр үзәгендә, унбиш, унсигез һәм егерме бер сәгатьтә – Спорт сараенда. Моннан тыш, КХТИ, Актерлар йорты, Яшел Үзәннең «Родина» мәдәният йорты, Боровое Матюшинода (обком дачасында) «планнан тыш» концертлар...

Чыгышларның шулкадәр тыгыз графигына түзәргә Высоцкийга үзе пешерә торган чәй ярдәм иткән, диләр. «Шестеро молодых» вокаль-инструменталь ансамбле егетләре сөйләгәнчә, чәй рецепты гади булган: чирек стакан – коньяк, өч чирек – нык кара чәй... Ләкин бу дару актерны салкын тиюдән саклап кала алмаган: тамагы авырта башлап, җырчының гастрольләрен куркыныч астына куя.

Шулчак Яшьләр үзәгендә спорт табибы булып эшләгән Юрий Алашеевский ярдәмгә килә. Ул авыруга чын дарулар язып бирә. Физиопроцедуралар да кирәк була, Высоцкий аларны да зур төгәллек белән үти. Казаннан киткәндә ул табибка үзенең фотографиясен имзалап калдыра: «Юре добра и успехов. В. Высоцкий».

Высоцкий үзенең «Письмо в редакцию телепередачи «Очевидное-невероятное» из Канатчиковой дачи» дигән җырын беренче тапкыр Казанда

башкарган, дигән фикер бар. Хәзер инде моны берничек тә тикшереп булмый. Аның каравы, җырның бик уңышлы булуында шик юк! Тамашачылар елый-елый көлә...

Яшел Үзәннең «Родина» мәдәният йортында булган вакыйганы сөйләп китик. Анда Владимир Высоцкий нибары биш кенә җыр башкара һәм тиз генә китеп тә бара, – күрәсең, Казандагы концертка соңга калгандыр. Тамашачыларның ачуы чыга. Зур акчалар түләдек, ә вәгъдә ителгән Высоцкий урынына җирле халык ансамбле чыгышын тыңлаталар, диләр дип шаулашалар... Бер ветеран залдан чыгып китә һәм фойеда машина йөртүчесен көтеп торган Высоцкий белән күзгә-күз очраша. Бабай дипломатияне саклап тормый: «Володя, билет өч сум тора, ә син бер сумга гына җырладың!», – ди. Высоцкий: «Хәзер тагын ике сумлык җырлыйм!» – дип, фойеда торганда ветеран өчен берничә җыр башкара.

Октябрь, 1977 ел

Спорт сарае, Яшьләр үзәге

РЕНАТ ИБРАҺИМОВ һӘМ «БЕЗНЕҢ ШӘҺӘР»

«Татар сандугачы» Ренат Ибраһимовның дан-шөһрәт казанган вакыты. Берничә ай элек кенә җырчыны «Песня-78» Яңа ел тапшыруына чакырып җырлаталар. Шуннан соң бөтен ил аның Магомаевтан бер дә калышмаган бәрхет баритонына гашыйк була. Дөрес, Казан халкы Ибраһимовның җырлау сәләте турында күптән белә – ул инде биш ел буе җирле опера театры солисты булып эшли. Үз «йолдыз»ларыңа карата мөнәсәбәт һәрвакыт шундый битарафрак була бит. Шуңа күрә июль аенда Казан урамнарында җырлап йөрүче Ренат Ибраһимовны күргән якташларыбызның исләре китми, юл читләренә тезелеп, авызларын ачып торучылар да булмый.

Аның каравы, Казан үзәгендә клип төшерү өчен урамнарны да ябарга туры килми. Ибраһимов Ленин урамы буйлап атлап, Казан университетының биек биналарына сокланып җырлый, ә шәһәр халкы ачык һавада оештырылган әлеге концертка әллә ни игътибар да бирми. Тик кайберәүләр генә урамнан ишетелер-ишетелмәс җырлап баручы Ибраһимовны танып ала, ә бу вакытта урамны тутырып каяндыр таныш баритон яңгырый.

Күпләр өчен бу – ачыш була. Советлар илендә «фанера»га ияреп чыгыш ясау кебек әйберләр турында бик азлар гына белгән. Дөрес, бу юлы берәү дә тамашачыны алдаларга уйламый. Шәһәр буйлап атлап баручы микрофонсыз җырчыны башкача клипка төшереп тә булмый бит.

Җәй, 1979 ел

Казан, Ленин урамы, хәзерге Кремль урамы

Ренат Ибраһимовның концертларда «фанера» га ияреп җырлаганы булмый. Ул гына да түгел, Казан тамашачысы бәрхет баритон иясенең Татар опера театрында булган соло концертын хәтерли, ул чакта Ренат Ибраһимов икенче бүлек дәвамында а капелла җырлап, тамашачыларны сокландыра.

...Ә төп рольдә Ренат Ибраһимов җырлаган «Безнең шәһәр» клибы Казанга багышланган беренче видеоклип була, бу чорда әле клиплар гомумән төшерелмәгән. Аны хәзер дә интернет аша карарга мөмкин. Шулай итеп, 1979 нчы елның июлендә Казан урамы буенча атлап баручылар үзләре дә сизмәстән тарихи вакыйгада катнашкан булып чыга.

«ПЕСНЯРЫ» һӘМ КАЗАН КҮЧТӘНӘЧЛӘРЕ

1970 нче еллар башында «Комсомолка» газетасында гаугалы бер язма басылып чыга. Аның геройлары – әле генә танылып килүче «Песняры» вокаль-инструменталь ансамбле музыкантлары Волгоградта концертларын өзә. Чыгышларының җирле телевидение тарафыннан төшерелүен белгәннән соң, алар уйнаудан баш тарта – янәсе, бу хакта килешү булмаган, һәм алар «бушка язылырга теләми». Җәнҗалның бөтен нечкәлекләренә тукталып тормыйбыз, бары шунысын гына әйтик: «Песняры» катнашучыларына бу гауга зыян гына сала – Канны гастрольләре өзелә, һәм күпмедер вакыт төркем бөтенләй беркая да чыкмый. Берничә елдан соң шундый ук хәл аз гына Казанда кабатланмый кала.

Спорт сарае залы шыгрым тулы. Ул вакытта төркем зур популярлык казанган була һәм СССРда гына түгел: чит ил матбугаты ансамбльнең Америка гастрольләрен «Көнбатыш рок-фронтында рус шаукымы» дип атарга да өлгерә. Шуңа күрә «Песняры» концертына әләгү үзе бер могҗиза була.

Концерт мәҗараларсыз гына башланып китә – музыкантлар сәхнәдә уйный, залда тамашачылар утыра. Кайберләренең тезләрендә «Весна» һәм «Электроника» портатив кассеталы магнитофоннары – ул вакытта кумирларның чыгышларын шул рәвешле яздырып алу гадәти хәл саналган. Ләкин профессиональ тавыш яздыруга карата – бөтенләй башка мөнәсәбәт! Вакыйга шаһитлары искә төшергәнчә, концертның яртысыннан соң, җырчылар нидәндер шикләнә башлый. Казанда да кемдер аларның тавыш җиһазларына тоташмаган микән?! Концертны кисәк кенә туктатып, артистлар сәхнәдән чыгып китә.

Казан тамашачылары хатирәләре буенча, көтелмәгән антракт ярты сәгатьтән артык дәвам иткән – тавыш белән эшләүчеләргә проблеманы хәл итү өчен шулкадәр вакыт кирәк була. Хәер, залдагылар таралышырга уйламый. Татарстан башкаласы Волгоградка караганда бәхетлерәк булып чыга – концерт дәвам итә, һәм рәхмәтле тамашачы үз кумирларын әле бик озак сәхнәдән җибәрми. Артистлар әлеге күңелсез хәлгә үпкәләми, өстәвенә, тамашачылар чәчәкләр генә түгел, ә... банка белән тозлы яшелчәләр дә бүләк итә. Шулай итеп, тагын бер гауга булмыйча кала. 70 нче еллар афишасындагы бу факт матбугатка чыгып өлгерми, ә вакыйгага шаһит булучылар истәлекләрендә генә сакланып кала.

Май, 1979 ел

Спорт сарае

1970 нче еллар

100 СУМГА НӘРСӘ АЛЫРГА БУЛА?

...1970 нче елларда:

- ике велосипед
- яисә базарда 20 кг сыер ите
- яисә 601 арыш ипие
- яисә 3333 мәртәбә трамвайда йөреп килергә

РФ буенча уртача хезмәт хакы (1970 нче еллар уртасы мәгълүматлары)
149 сум

1970 нче еллар

«Татарстан» журналы ТАССР юбилейларын һәрвакыт үзенең укучылары, кайвакытта исә язучылары белән дә бергә билгеләп үткән. «Татарстан коммунисты» булган чагында «Татарстан» журналы Максим Горький, Владимир Маяковский, Исаак Бабель, Чыңгыз Айтматов кебек танылган авторлар белән хезмәттәшлектә булган... Татарстан АССР төзелүгә ун ел тулу уңаеннан язучы Максим Горький 1930 елда татар халкына тәбрик хаты язган. А.М. Горькийның Мәскәүдәге архивында саклана торган әлеге котлау хатының фотокүчермәсен 1958 елда Казандагы Горький музее директоры М. Н. Елизарова эшләтеп алган һәм матбугатта бастырган. Шул вакыттан бирле Максим Горький республика халкын «Татарстан коммунисты» битләреннән тагын ике тапкыр – 1958 елда язучының тууына 90 ел тулу датасы билгеләп үтелгәндә һәм 1970 елда ТАССРның 50 еллыгы бәйрәм ителгәндә сәламләгән. «Буыннар» проектын аның 70 нче еллардан килгән тәбрикнамәсеннән башлыйбыз.

М. Горький:

– ЯШӘСЕН МИН ЯРАТКАН ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАСЫ!

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!



ТАТАРСТАН КОММУНИСТЫ

2

1978